Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 11 (1376) 25 март 2022 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga madanizhomga
madani_zhomga

2

Мәктәп балалары белән милли-патриотик юнәлештәге дәресләр, очрашулар үткәрү максаты белән Мари иленең Бәрәңге районы үзәгенә сәфәр кылдык.

12

Рәссам Марат Мингалиев һәм Г.Ибраһимов исемендәге институт тырышлыгы белән Бакый Урманченың графикасына багышланган бик саллы китап дөнья күрде.

19

Россия төбәкләреннән татар эшмәкәрләре киңәш-табыш, тәҗрибә уртаклашу өчен, унынчы тапкыр Татарстан башкаласына җыелды.



Куанычы ташкан Яз сылуның, – Бөреләрнең теле ачыла ла!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов фигуралы шуу буенча олимпия чемпионы Камилә Вәлиевага «Дуслык» ордены тапшырды.
- Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты «365 көн догада» дип исемләнгән китап чыгарды.
- Татарстан Милли китапханәсенең кыш айларында иң популяр булган 10 китап исемлегендә беренче урыннарны Ә.Еникинең «Матурлык» җыентыгы, А.Әхмәтгалиеваның «Кичке таң» һәм С.Сәүбәнованың «Кырау суккан алмагач» китабы алган.
- Чиләбе өлкәсенең Еманжелинск шәһәрендәге тарих-туган якны өйрәнү музеенда татар ашлары остасы Юныс Әхмәтҗановның туган көненә багышланган «Татар халкының мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре» дигән күргәзмә тәкъдим ителде.
- Самара шәһәрендә узган «Мирас» халыкара конкурс-фестивалендә Түбән Камадан «Нардуган» ансамбле, Оренбург өлкәсеннән бию төркеме һәм вокал коллективы, Әстерханнан «Заман» вокал-хореография төркеме һәм башкалар катнашты.
- Түбән Кама шәһәренең Комплекслы музеенда "Ислам нуры" күргәзмәсе ачылды.
- Казанның 171 нче мәктәбендә язучы Зиннур Хөснияр иҗатына багышланган «Очар кошлар юлын эзләр» дигән фәнни-эзләнү конференциясе узды.
- «Россия почтасы» АҖ филиалы – «Татарстан почтасы» предприятиесе директоры итеп Илнур Мәхмүтов билгеләнде.
- 28 мартта Татарстан Язучылар берлегенең Тукай клубында язучы, галим, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 135 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә була.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Ирада ӘЮПОВА, Татарстан Республикасы мәдәният министры:

"Мин китап корты. Буш вакытым булса да, еш кына төнлә дә укыйм, кайчагында берничәсен берьюлы укыйм... Миндә китаплар бик күп. Безгә гаиләбез белән еш күченеп йөрергә туры килде, һәм минем өчен яңа йортта китапханә булу төп шарт иде. Хәзер мәнә тагын күченәбез... Өйдәгеләр миңа: «Без сине китапларың белән бергә чыгарып җибәрәбез!» – диләр. Чөнки күченгән саен китапларны киштәләрдән бушатып, тартмаларга тутыру, яңадан урнаштыру бик мәшәкатьле эш... Мин барысын да аңлыйм, әмма бер генә китабымны да калдырасым килми".

СЫНАМЫШЛАР

25 мартта томан төшсә – җитен, киндер, солы уңа ● Акчарлаклар килгәч, елгада боз кузгала ● Кар барында күк күкрәсә, ашлык уңмас ● Боз тиз эреп бетсә, уңыш яхшы була ● Торналар килгәч, җылыта.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **5 сәгать 33 минутта** чыкты, һәм ул **18 сәгать 07 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **12 сәгать 34 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **33 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **1 апрельдә 13 сәгать 07 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

25 март – Мәдәният һәм сәнгать өлкәсе хезмәткәрләре көне.

28 март – шагыйрь Мидхәт Мәҗит улы Әбделмәновка 80 яшь (1942).

29 март – дәүләт эшлеклесе, Татарстанның беренче Премьер-министры, Татарстанның атказанган төзүчесе Мөхәммәт Галләм улы Сабировның тууына 90 ел (1932–2015).

31 март – Татарстанның халык артисты, татар курчак театрын оештыручыларның берсе, драматург Фуат Гайфулла улы Таһировның тууына 95 ел (1917- 1996).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Мартның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 31 март.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(25 март-1 апрель)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **18 февральдән 29 апрельгә** кадәр бавыр һәм үт куыгы актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны чистарту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген шәгъбән аеның 22 нче көне

МӨСАФИР СӘФӘРДӘН КАЙТТЫ

Мари иленә сәяхәт

Күршебез – Мари илендәге Бәрәңге районында элек тә булган бар, җитәкчеләре белән дә күптән таныш идек. Язның көләч кояшы елмая башлауга күңелләре "җебегәндер", ахры, көтелмәгән рәвештә, мәнә тагын кунакка чакырдылар. Мәктәп балалары белән патриотик юнәлештәге дәресләр үткәрү кирәк, моның өчен без фәкыйрьләрдән дә кулайрак үгет-нәсихәтчеләр табу кыен икән. Мәнә шушы йөкне үтәү өчен, "Безнең мирас" журналы вәкилләре Ләбиб Лерон, Ленар Габидуллин һәм Рәдиф Сәгъди кебек аркадашлар белән яңадан дә Бәрәңге районы үзәгенә килеп төштек. Иң беренче чиратта район башлыгы Әлфит әфәнде Ибраевка рәхмәт, каршы алучы һәм озатып калучы да шәхсән үзе булды.

● Мөсафир егетләр район башлыгы Ә.Ибраев бүлмәсендә.

Әүвәл Бәрәңге районы тарихына күз йөгертү дә артык булмас сыман. Өлкән туганның мәңгелек чире – яу белән килеп, Казан каласын тез астына салганнан соң, "яңа хуҗалар" мәркәз тирәсен 50 чакрым әйләнәдә татар авылларыннан "чистартуга" керешә. Бүгенге Биектау, Әтнә, Арча тирәсендәге авыллар халкы "хуҗалар" чыбыркысыннан, тагын да яманы – мәҗбүри чукындырудан качып, ул заманда куе урманнар арасында яткан марилар җиренә күчәргә мәҗбүр була. 1931 елда совет комиссарлары Бәрәңге районын оештырган чакта анда яшәүчеләрнең 62 процентын татарлар тәшкил итә. Бәрәңге авылының үзендә генә дә 4200 чамасы кеше исәпләнә (ул вакытта республика мәркәзе дип игълан ителгән Йошкар-Оланың үзендә нибары 1200 генә кеше яши, ул 1930 еллар ахырында гына сан ягыннан Бәрәңге белән тиңләшә). Ул елларга кадәр үк Бәрәңге барча Казан арты авылларының данлы базарына әверелгән була инде. Ул төбәктәге татарлар игенчелек кенә түгел, мал асрау, аеруча атлар үстерү, казылык ясау белән дан тота. Өстәвенә, һәммә төбәктәге татарлар шикелле үк, алар киез итек тә баса, йон эшкәртә, шәл бәйли, киндер суга, ат дирбияләре, чана-арба, камыт һәм тәгәрмәчләр белән дә сәүдә итә. Һәр якшәмбе саен үткәрелгән тиңсез базарга Йошкар-Оланың үзеннән генә түгел, Арча, Әтнә, Биектау, Балтач, Кукмара, хәтта ерак Чистай ягыннан да елгыр сәүдәгәрләр олау-олау тауар ташып тора. Чамалыйсыз булыр, тиктормас һәм уңган татарларның мондый өстенлеге озак вакыт дәвам итә алмый. 1937-1938 елларда Бәрәңгенең бер үзеннән генә дә 600 дән артык асыл татар ирләре кулга алына, аларның 102 се атып үтерелә. Аннан соң мәхшәргә тиң сугыш, янә йөзәрләгән татар ирләре чит җирдә баш сала... Бүген районда 14 мең чамасы кеше яши, аның 5 мең ярымы Бәрәңгедә. Халыкның 47 проценты – татар, 43 проценты – мари вәкилләре...

Без Бәрәңгенең үзендәге урта мәктәптә һәм тагын Портянур белән Куян авылларының тугызъеллык мәктәпләрендә булдык. Сугышка чаклы Бәрәңге мәктәбендә шагыйрь Мансур Гаяз укыткан, әмма дистәләгән татар әдипләре шикелле үк аяуда ятып калган. Шушы ук мәктәптә соңыннан Россия Герое дәрәҗәсенә ирешкән Радик Бариев белем алган, әлеге очучы генерал бүген дә хәрби хезмәттә. Бәрәңгедә 731 укучы исәпләнсә, аларның 70 процентка якыны - татар балалары. Портянур мәктәбендәге 66 бала белән Куян авылындагы 94 укучының һәммәсе дә диярлек татар милләтеннән. Дирекцияләр кабул иткән программа буенча атнасына 2 сәгать татар теле керә һәм берәр сәгать татар әдәбияты укытыла. Телевидение һәм социаль челтәрләр канат җәйгән замана чире аларны да урап үтмәгән, тәнәфескә чыгуга байтак бала рус теленә күчә. Ни хикмәттер: арада татарча шигырь язучылар да шактый икән әле...

Куян авылы татар халкына гайрәтле һәм тез чүкмәс каһарман Гайнан Кормашны бүләк иткән. Аның сугышка чаклы язмышы да ачы һәм шаккаткыч. 1938 елда туган авылы мәктәбендә татар теле укытып йөргән егетне, кем яласы буенчадыр, НКВДга чакырып допрослыйлар. Допрос иртәгә дә дәвам итәчәген искәртеп, яшь егетне иреккә җибәрәләр. Бәхетенә, юлда аңа элекке укытучысы очрый. Егет үзенең допростан гына чыгуын ярып салуга, остазы аны арбасына утырта да, 70 чакрымдагы тимер юл станциясенә алып китә. "Гайнан, сине исән калдырмаячаклар. Әнә, төрекмәннәр ягында тимер юл төзелеше бара, ул якта тиз генә эзләп тапмаслар, шул якка кач", – дип фатихасын да бирә. Кормаш әнә шулай итеп, репрессия дигән аждаһа тегермәненнән Урта Азиядә качып кала. Аннары фин сугышы башлану турында хәбәрне ишетүгә үк, үзен фронтка җибәрүләрен сорап, хәрби комиссариатка юнәлә. Егетне разведчиклар әзерли торган курсларга озаталар. Әбөек Ватан сугышы башлангач, Гайнан Кормаш концлагерьдагы әсирләр арасында аңлату алып бару һәм фетнә күзгату өчен дошман арасына җибәрелә. 1942 елда ук ул Абдулла Алиш белән бергәләп тоткыннар лагеренда яшерен оешма төзи. Ел ахырында гына аларга Муса Җәлил дә килеп кушыла. Алар бер-берсен әле сугышка чаклы ук белгән була. Куян авылында укытып йөргән егет шигырьләр язу белән дә мавыга һәм бер мәлне, тәвәккәлләп, аларны Язучылар берлегенә юллый. Шигырьләр ул чакта берлек рәисе булган Муса кулына килеп эләгә. Муса шигырьләрне уңай бәяли һәм Кормашны очрашуга дәшә. Шул очрашуга бару өчен, Кормаш хәтта өр-яңа чалбар да тектерә (авыл мөгаллимнәре әлеге ядкәрне әле хәзер дә тик елмаеп кына искә ала). Инде бер-берсен күреп белгән Җәлил белән Кормаш фашист тоткынлыгында да кулга-кул тотынып эшли. Яшерен оешмага нигез салган Кормаш Җәлилдән дә алда, беренчеләрдән булып, җәллад балтасы астында башын җуя...

Куян мәктәбенең төбәк тарихына һәм Бөек Ватан сугышына багышланган музеенда Гайнан Кормашның аерым почмагы бар, билгеле. Мәктәп диварына Кормашка багышланган мемориал такта да куелган, музейда аның туганнары язып калдырган истәлекләр дә бар. Ни үкенеч, Бәрәңгедә дә, Куян авылында да Кормаш хөрмәтенә куелган бюст кына юк. Куян мәктәбенә ашыгыч ремонт таләп ителә, 60 миллион сум күләмендә яңарту уздыру быел үткәреләчәк гамәлләр исемлегенә кертелгән. Хыял да, теләк тә бер генә – каһарман Гайнан Кормаш рухы, ниһаять һәйкәл булып, туган төбәгенә дә кайтып җитсен иде...

Мәктәпләрдә без үткәргән "патриотик тәрбия"гә күчсәк, телләрен "татар" дип ачкан асыл әдипләр өлкән агай кубызына бии алмый инде. Татар милләтенең җанын "тозлы яра" сыман туктаусыз әрнетеп торучы яралар да җитәрлек. Әнә, нәкъ Җәлил шикелле үк, аның белән янәшә газапланган Кормаш, Симай, Батталлар батырлыгын сыңар орден белән кенә "ямадылар". Фашист Рейхстагына иң беренче булып Җиңү байрагы элгән Гази Заһитовка Герой исемен дә, хәтта инде котылгысыз рәвештә таләп ителгән өченче Дан орденын да бирми алдадылар.

(Дәвамы 5 нче биттә).

ИМАН БАГАНАСЫН КЕМ ТОРГЫЗЫР?

Диннәрнең сәясәт коралы да итеп кулланылуы бүген инде күпләр өчен сер түгел. Әлбәттә, дөнья тотучылар тарафыннан аерым роль бу җәһәттән ислам диненә дә бирелә: мәҗбүри глобальләштерү сәясәтен алга этәрү ниятендә, "халыкара ислам терроризмы" дигән глобаль дошман образы булдырыла, моның өчен, ислам йолалары һәм атрибутлары артына яшеренгән, әмма белеме сай һәм кыйбласы да томанлы булган затлар җәлеп ителә, шул рәвешле мөселман өммәте сәясәт коралы дәрәҗәсенә куела, хак динебезнең илаһи асылы дискредитацияләнә, җәмгыятьтә имансызлыкка юл ачыла. Моңа китергән сәбәпләр дә билгеле: ислам диненең илаһи асылын колачлый алмау һәм җәмгыятьтәге рухи кризис. Билгеле булганча, исламның биш әркәнен (баганасын) үтәүгә керешкәнче, һәр мөэминнең иман китерүе лязем. Ә бу инде, шәһадәт белән бергә, хак динебезнең илаһи асылын акыл белән аңлау, илаһият кануннарын үтәүне яшәү рәвеше итәргә дә әзер булу дигән сүз. Бары шуннан соң гына кеше үз иманын ислам дине йолалары дәрәҗәсендә дә ныгыта ала. Ә бүгенге җаһил чорда ныклы иман баганасын һәр кешенең вөҗүдендә дә торгызу зарур. Аның ысуллары вә серләренә килгәндә, алары инде – теологлар һәм дин әһелләре эше.

Үзем исә, сәясәт белән күпмедер дәрәҗәдә шөгыльләнгән зат буларак, бу язмада хак динебезнең шул ягына кагыла торган мәсьәләләргә дә бераз тукталырга җөрьәт итәм. Бу җәһәттән сүзебезне барлык чорлар өчен дә уртак хакыйкатькә таянып дәвам итик: Җирдә иблис урнаштыра торган тәртипкә илаһи альтернатива булып, Аллаһ кануннарына корылган яшәү рәвеше генә чыга ала. Адәми затның рухи үсешендә (дини эволюциянең китү-кайту циклында) ислам дине рухны соңгы баскычка күтәрү (рәсүли аңга ирештерү) өчен иңдерелгән истә тотсак, ислам яңарышы бүген инде җәмгыяви ихтыяҗга да әверелә. Илаһият кануннары барлык тереклек дөньясы өчен уртак булган кебек, тәүхиди-иҗтиһади ислам да динебезне, төрле уйдырма һәм мөшриклектән арындырып, Рәсүлебез чорындагы сафлыгына кайтару (вакыт-пространство таләпләрен исәпкә алу) аша, илаһи тәгълиматка нигезләнеп формалашкан җәмгыяви күптөрлелек берлеге (гомумкешелек цивилизациясе) итеп үзгәртергә тиеш була. Кешелек дөньясы тирән рухи һәм цивилизацион кризис кичергән хәзерге чорда бу, чыннан да, инсаниятне Аллаһ хозурына кайтаруның бердәнбер юлы, яңа дөньяви тәртипкә илаһи альтернатива булып тора. Аның асылы – Җирдә илаһият кануннары буенча яшәүгә күчү. Ә алар барлык диннәр һәм кавемнәр өчен дә уртак.

Табигый ки, кешеләр аңында һәм яшәү рәвешендә глобаль дәрәҗәдәге мондый илаһи борылыш бер мизгелдә генә була алмый. Уй-ниятләрдә генә түгел, эш-гамәлләрдә дә Аллаһ кануннары буенча яшәүгә күчү өчен әле, мөгаен, буыннар вә чорлар алышынуы да таләп ителер. Әмма бу юнәлештәге эшчәнлек инде бүгеннән үк башланып китәргә тиеш. Чөнки вакыты шундый. Тик моның өчен нәрсә эшләргә соң? Эшне нидән башларга? Әлбәттә, иң элек – рухи вә дини яңарышның җәмгыяви ихтыяҗ булуын шәхси планда да, иҗтимагый аң дәрәҗәсендә дә тану һәм кабул итүдән. Аллаһ кушканча яшәү кешенең яшәү рәвешенә әйләнергә тиеш. Еш кына күпләр моны дини йолаларны үтәү яки тышкы атрибутларны (кием-салым, сакал-мыек һ.б.) үзгәртү дип кенә аңлый. Һич юк. Иң элек кешенең рухи асылы, әхлагы һәм кылган эш-гамәлләре илаһият кануннарына җавап бирүе лязем. Гади нәрсәләрдән башлыйк. Әйтик, иртән теш чистартканда, кранны ябып торудан. Су счетчигы санаганга гына түгел, ә эчә торган суны исраф итәргә ярамаганга күрә. Игелек кылганда да - савап өчен генә түгел, ә кешеләргә ярдәм йөзеннән, Аллаһ ризалыгы өчен.

Аңлашыла ки, рухи вә дини яңарыш мәчет-мәдрәсәләрдән, мәхәлләләрдән, бүтән дини вә иҗтимагый оешмалардан башка гына була алмый. Чөнки бүген иман баганаларын аерым шәхесләр күңелендә генә түгел, җәмгыяви аң дәрәҗәсендә, иман манаралары итеп тә торгызу лязем. Ә алга таба инде илаһият кануннары буенча яшәүнең барлык илләрдә дә дәүләт идеологиясе дәрәҗәсенә күтәрелүе һәм төп законнарына да кертелүе мәслихәт. Шулаен шулайдыр да, тик моның белән кем һәм ни рәвешле шөгыльләнергә тиеш соң? Бу сорауга җавап, Җәнабел Хак тарафыннан яралтылышта ук, китү-кайту циклы рәвешендә тәкъдир кылынган. Әмма андый катлаулы тема аңа аерым да тукталуны таләп итә.

Фоат УРАЗАЙ.

Тел комиссиясе хисап тотты

Татарстан Дәүләт Советында республика Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясенең киңәйтелгән утырышы узды. Анда төрле министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре һәм Казан башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Татарстан халыкларының туган телләрен үстерү өчен шартлар тудыру буенча башкарылган эшләр һәм планнар турында сөйләде.

Утырышны ачып, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов, комиссия татар телен куллану өлкәсен киңәйтү белән актив шөгыльләнүне, туган телдә коммуникатив аралашуны популярлаштыру һәм кешеләргә бу мәсьәләләрнең мөһимлеген аңлатуны дәвам итә, дип билгеләп үтте. «Коронавирус белән бәйле чикләүләргә карамастан, Татарстанда Туган телләр һәм халык бердәмлеге елы кысаларында билгеләнгән чараларның күбесе башкарылды, – дип искәртте ул. – Татар телендә иҗат итүче язучылар арасында әдәби бәйгеләр, татар телендәге күрсәтмә такталарда хаталарны ачыклау буенча конкурс үткәрелде, татар теленең бушлай курслары, сөйләм буенча осталык дәресләре оештырылды. Президент комиссиясенең актив ярдәме белән 100 мәктәп, 100 балалар бакчасы һәм 100 мәдәният учреждениесе татар телен үстерү эшчәнлегенә һәрберсе 500 мең сумлык республика грантлары отты».

Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында туган телләрне өйрәнү, укыту һәм тәрбияләү өчен шартлар тудыру эше турында мәгълүмат бирде. Үз чыгышында ул дәреслекләр һәм методик әсбаплар әзерләү эшенең барышы турында җентекләп сөйләде, шулай ук аларны рөхсәт ителгән укыту әсбапларының федераль реестрына кертү процессында килеп чыга торган кыенлыкларга борчылуын белдерде. «Татарстан китап нәшрияты тарафыннан быел федераль исемлеккә кертү өчен, 5-9 сыйныфларда төп фәннәр буенча 41 әсбап әзерләнә», – дип хәбәр итте министр.

Республиканың милли стратегиясен гамәлгә ашыру кысаларында мәдәни чаралар турында Татарстан мәдәният министры Ирада Әюпова чыгыш ясады. Аның сүзләренә караганда, Татарстанда Туган телләр һәм халык бердәмлеге елында 450 дән артык чара уздырылган. Татарстанның матди булмаган мәдәни мирас реестрына 50 объект кертелгән. «Татарстанның электрон китапханәсе» платформасында татар язучыларының 90 мең китабы цифрлаштырылган һәм урнаштырылган.

Татарстанның яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов яшь кешеләрдә туган телне белү мотивациясенә, татар телен үстерүгә ярдәм итүгә, татар яшьләрендә милли тарихны һәм мәдәниятне өйрәнүгә омтылыш тудыруга юнәлдерелгән ведомство проектлары һәм чаралары турында мәгълүмат бирде. Аның сүзләренә караганда, бөтенроссия татар яшьләре форумы, «Идел» яшьләр лагере, Татар яшьләре көннәре, «Алтын каләм» һәм «Безнең заман» конкурслары матур нәтиҗәләр күрсәтә.

Республика журналистика өлкәсенең татар телен саклау һәм үстерү эшенә керткән өлеше турында Матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр буенча республика агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев сөйләде. Ул милли журналистика өчен профессиональ кадрлар әзерләү системасын камилләштерү кирәклегенә аерым игътибар юнәлтте.

Милли китапханә яңа бинада

Татарстан Милли китапханәсе бер ел элек Пушкин урамындагы иркен йортка күченгән иде. Урнашып озак та үтмәде, китапханә үзенең эшчәнлеген башлап җибәрде, башкача әйтсәк, китап сөючеләргә, студентлар, һ.б.га бердәм уку билетлар белән уңайлы залларда утырып шөгыльләнү, басмаларны яздырып алып өйләренә дә алу мөмкинлеге тудырылды. Бу ел эчендә 36 меңнән артык кеше китапханәнең уку билетына ия булган. Милли китапханәнең матбугат үзәге хәбәр иткәнчә, китап йортына бер елда 565 мең кеше килгән, укучылар тарафыннан кәгазь һәм электрон форматтагы 2,2 миллионнан артык китап яздырып алынган.

Китапханәнең китаплар фонды тулылануы да күңелле. Әйтик, бүләк итеп китергән китаплар белән генә дә тулаем фонд 7 мең китапка арткан. Якынча исәпләүләр белән, яңа китаплар сатып алынмыйча, якынча 120 000 000 сум акча экономияләнгән.

Шул ук вакытта китапханә залларында көн саен төрле очрашулар, лекцияләр, осталык дәресләре, кино караулар, лабораторияләр, фестивальләр, төрле юнәлештәге кичәләр, яңа китапларны тәкъдим итүләр, күргәзмәләр, конференцияләр һ.б. узган. Гомумән алганда, бер ел эчендә китапханәдә 1200 дән артык төрле чаралар үткән һәм 1000 нән артык экскурсия үткәрелгән. Бу вакыйгаларның хатирәләре видеокадрларда һәм фотосурәтләрдә саклана.

Моннан тыш китапханә укучылар бәяләүләре нигезендә ясалган нәтиҗәләрдән күренгәнчә, республикада халыкка хезмәт күрсәтүдә иң яхшы күрсәткечләргә ирешкән. Аның «Ел командасы», «Елның иң яхшы җәмәгать мәйданы» номинацияләрендә җиңеп чыгуын һәм Russian Creative Awards премиясенең «Креаполис» номинациясе финалисты булуын да беләбез. Китапханә уку билеты белән, китап кибетендә һәм каһвәханәдә ташламалардан файдаланырга да мөмкин.

Сөембикә КАШАПОВА.

Театрда – кием остаханәсе

К. Тинчурин театрында татар дизайнеры, модельер Нажия Галимованың иҗади остаханәсе ачылды. Остаханәдә дизайнер киемнәре һәм эшләнмәләре коллекциясе белән танышырга мөмкин.

«Студия театр тамашачылары өчен ачык, аны спектакль алдыннан да, антракт вакытында да карарга була. Тинчурин театры мине кунак буларак чакырды. Кунак булып кына калмам, рәхәтләнеп эшләрмен дип уйлыйм, чөнки бирегә килгән кеше эшләрем белән кызыксына, сораша. Театрдагы остаханә мәгълүмат алмашу мәйданчыгы булсын иде», – диде дизайнер. Остаханә өчен махсус түгәрәк өстәл ясалган. Н. Галимова Тинчурин театрының костюмнар буенча рәссамнарына консультация дә бирәчәк. Дизайнер белән театр костюмерларының беренче уртак эшен режиссер Илгиз Зәйниевнең «Мәдинә» спектаклендә күрергә мөмкин булачак. Спектакльнең премьерасы апрельгә билгеләнгән.

Кичәдә Татарстанның атказанган артисты Илүсә Хуҗина Н. Галимова теккән күлмәктә чыгыш ясады.

1 нче биттә – яз хәбәрчеләре – тал песие. Фото: pixabay.com

15 томлыкта яңалыклар бихисап

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Татарстан китап нәшрияты белән берлектә татар әдәбияты классигы, галим Галимҗан Ибраһимовның 135 еллыгы уңаеннан 15 томлык «Әсәрләре»н бастырып чыгарды.

«Академик басма 12 томлык булыр дип планлаштырылды. Ибраһимов эшләгән, яшәгән чорда 1905-1938 елларда чыккан газета-журналларның барысын барладык, һәр санны тикшердек. Аның матбугатта 125 тән артык яңа мәкаләсе табылды. Күләм артып китү сәбәпле, 12 томлык басмаы 15 том итәргә килештек», – диде «Татар-информ» матбугат очрашуында институтның текстология бүлеге мөдире Эльмера Галимҗанова.

Аның әйтүенчә, әдипнең яңа әсәрләре генә түгел, элекке томлыкларында басылган барлык материаллар да чыганаклар белән яңадан тикшерелгән, кыскартулар, өземтәләр тулыландырылып бастырылган. Барлык мәкаләләр дә кыскартуларсыз урнаштырылган.

«I–V томнарда язучының әдәби әсәрләре (хикәяләр, повестьлар, романнар, драма әсәрләре) урын алды. Биредә «Татар хатыны ниләр күрми» повестеның һәм «Безнең көннәр» романнарының төрле басма вариантлары, совет чорында идеологик кануннарга туры килми дип табылган «Адәмнәр» повестеның да ике варианты кертелде», – диде галимә.

«Әлеге томнарда «Борынгы ислам мәдәнияте» исемле хезмәте, йөздән артык мәкаләсе беренче тапкыр чыкты. 15 томлыкта Г.Ибраһимов әсәрләренә замандашлары тарафыннан язылып, үз чорында газета-журналларда басылган рецензияләр дә урын алды. Әлеге бәяләмәләр укучыга әдипнең әдәби репутациясе формалашу үзенчәлекләрен һәм шул чордагы әдәби хәрәкәтне аңларга ярдәм итә. Элекке томлыкларда «Татар сарыфы», «Татар нәхүе», «Татар имлясы», «Татар телен ничек укытырга?» хезмәтләренең өзекләре генә урнаштырылса, биредә алар тулысынча кертелде», – диде Э.Галимҗанова.

«Академик басманың XV томында 1921, 1929 һәм 1936 елда язган автобиографияләре бар. 119 хаты кертелде. Хатлар стиль ягыннан төрле: рәсми, шәхси, ачык хатлар бар. Барлыгы 237 документ тупланды», – диде матбугат очрашуында институтның текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре Гөлнара Зәйниева. Аның сүзләренчә, һәр материал архив чыганактан алынган һәм хронологик тәртиптә, чыганак теле үзгәртелмичә урнаштырылган. Шулай ук китапта Галимҗан Ибраһимовның иҗатына, тормышына кагылышлы белдерүләр, белешмәләрне дә күрергә мөмкин.

«Аерым урынны моңа кадәр беркайда басылмаган репрессия чоры документлары алып тора. Галимҗан Ибраһимовның исемен аклау процессы турында кырыкка якын документ кертелде. Алар арасында гаепләү белешмәсе, кулга алу карары, ордерлар, төрмәдән-төрмәгә күчерү документлары, эксперт комиссиясе карары, башка шәһәрләргә запрос ясау, җавап хатлары урнаштырылды», – диде галимә.

Сәясәт эшлеклесе буларак, Галимҗан Ибраһимов белән бәйле анкета, стенограмма, беркетмәләр дә урын алган. «Яңа документлар арасында Ибраһимовның 1917 елда Мәскәүдә Беренче Бөтенроссия мөселманнар корылтаенда ясаган чыгышы, Беренче тюркологик корылтайга әзерләнү документлары да бар», – ди Г.Зәйниева.

«1928 елда Казан һәм Мәскәү шәһәрләрендә Галимҗан Ибраһимовның иҗатына 20 ел тулуга багышланган кичәләр уза. Үзе катнаша алмаса да, кичәнең беркетмәсе, тантаналы утырышның стенограммасы сакланган, без аларны урнаштырдык. Ул җитәкләгән Академия үзәгенең утырышы беркетмәләре дә беренче тапкыр дөнья күрде», – дип сөйләде галимә.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Борынгы мәчеткә яңа тормыш

Кукмара районы Мәчкәрә авылында XVIII гасыр азагында салынган мәчетне төзекләндерүгә старт бирелде. Кызыл кирпечтән эшләнгән ике катлы мәһабәт бина татар мәдәнияте архитектурасы һәйкәле булып тора. Ул Җәмигъ мәчете буларак 1791-1793 елларда беренче гильдия сәүдәгәре Габдулла Үтәмешев акчасына төзелгән. Төзелү вакыты һәм архитектурасы буенча ул Казанның Мәрҗани мәчетен хәтерләтә. Аның каршындагы мәдрәсәдә төрле еллар-да Казан, Уфа һәм Нократ губерналарының күп кенә мөселман руханилары дини белем алган.

«Бүген биредә тарихи вакыйга – без мәдәни мирас объектын төзекләндерергә тотынабыз. Бинага 230 ел. Кукмарада мәхәллә төзелү белән, егерме ел дәвамында хәер акчасына мәчетне төзекләндерү буенча берникадәр эш алып барылды. Без бирегә аның бүгенге хәлен күрсәтү өчен махсус җыелдык», – диде Татарстан Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе Иван Гущин.

И.Гущин мәчетнең бары тик хәйрия акчасына төзекләндереләчәген белдерде. Иганәчеләрдән 25 млн сумга якын акча җыелган. Димәк, эшне башлап җибәрү өчен акча табылган. «Бөтенесе ничә сум кирәк булачагын төгәл фаразлавы кыен, чөнки бу – шактый катлаулы объект. Шулай да, кимендә 100 млн сум кирәк булыр дип күзаллана», – диде И.Гущин.

Акча җыю Кукмара районы мөхтәсибәте тарафыннан оештырылачак, ә төзекләндерү эшләре ТР Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты һәм Татарстанның Инвестиция-төзелеш баш идарәсе контроле белән башкарылачак.

Быел бинаның нигезе, диварлары ныгытылачак, гидроизоляция ясалачак. Әлегә ул авария хәлендә. Мәчет территориясен тәртипкә китерү һәм анда тәһарәтханә булдыру да планга кергән. Төзекләндерү эшләрен тулысынча ике ел эчендә башкарып чыгу бурычы куелган.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин бүгенге чарада Мәчкәрә мәчетен гади генә гыйбадәт йорты түгел икәнен, Казан губернасында танылган дин әһелләре белән бәйле булуын әйтте. Аның сүзләренчә, мәчет Галимҗан Баруди, Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтләрендә телгә алына. Шулай ук Мәчкәрә зиратында заманында абруйга ия булган ишаннар җирләнгән.

Татарстан мөфтие республиканың башка авылларында Мәчкәрәдәге кебек зурлыктагы, яки аннан да зуррак борынгы мәчет барлыгын әйтә алмады. «Борынгы мәчетләребез бар, ләкин алар моның кадәр мәһабәт түгел», – диде ул. Камил хәзрәт киләчәктә Мәчкәрә мәчетенә туристлар җәлеп итеп буласына ышаныч белдерде.

Рифат КАЮМОВ.

«Йолдызлык» концерт кына түгел ул

Арча районында «Созвездие-Йолдызлык» XXII ачык республика яшьләр эстрада фестиваленең алтынчы зона этабы гала-концерт белән тәмамланды. Анда Теләче, Саба, Арча, Балтач, Әтнә, Биектау, Кукмара районнарыннан мең ярымнан артык яшь талант иясе катнашты. Мәртәбәле жюри тарафыннан 311 иҗади номер каралды, шуларның 78е алдагы этапка сайлап алынды.

«Бу зона башка үзенчәлекле атмосфера белән аерылып тора. Балалар монда бик ачык, аларның фидакярлеге сизелә. «Созвездие-Йолдызлык»ның үз кабатланмас йөзе бар, һәм, мөгаен, аны нәкъ менә шундый катнашучылар тудырадыр», – дип фикерләре белән уртаклашты Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, җырчы, актриса, Мәскәү Губерна театры труппасы мөдире Алинә Ивах.

Сайлап алу туры кысаларында шулай ук түгәрәк өстәлләр үткәрелде. Комиссия әгъзалары фестивальдә катнашучыларның барлык номинацияләрендә дә катнашучы педагоглар белән очрашты һәм үз тәҗрибәләре белән уртаклашты.

«Түгәрәк өстәл кысаларында безнең төп бурыч – җитешсезлекләрне бетерергә ярдәм итү. Һәм шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, проектта катнашучылар безнең тәләкләребезне ишетә һәм куллана, бу исә гомум башкару дәрәҗәсен дә үстерде», – дип ассызыклады Россия һәм Татарстанның халык артисты, Казан консерваториясе профессоры Зилә Сөнгатуллина.

«Бездән еш кына чыгыш ясаганда иң мөһиме нәрсә дип сорыйлар. Минемчә, вокал яки бию, артистлык харизмасы, костюмнар – теләсә кайсы номерның аерылгысыз өлеше. Әмма монда иң мөһиме – катнашучы тамашачыларга сәхнәдән бүләк итә торган энергия. Аннан башка калганнары мөһим дә түгел», – дип, уңыш серләре белән уртаклашты халыкара һәм бөтенроссия бәйгеләре лауреаты Айдар Сөләйманов. Ул шулай ук соңгы елларда катнашучыларның милли җырлар һәм биюләргә, совет чоры эстрадасына карата кызыксынуы артуын, бу күренеш жюри әгъзаларын аеруча сөендерүен билгеләп үтте.

9-13 апрельдә сайлап алу турлары җиңүчеләре КФУның «УНИКС» мәдәни-спорт комплексы һәм «Созвездие-Йолдызлык» арт-резиденциясендә суперфиналда очрашачак.

● Былтыр көз Дубайның ясалма Bluewaters утравында дөньяда иң биек – 250 метрлы күзәтү тәгәрмәче ачылган. Аны төзү өчен 272 миллион доллар акча тотылган, 11 мең тонна корыч киткән – бу Эйфель манарасыныкыннан ике тапкырга күбрәк. Ain Dubai берьюлы 1750 кешене сыйдыра. 48 кабинасы 19 төрле вариантта җиһазландырылган, бер әйләнеш ясауга 38 минут китә. Биредә елына 3 миллион чамасы кеше кунак булыр, дип фаразлана.

● Ашказанында азыкның нибары 17 проценты гына үзләштерелгәнгә, панда тәүлегенә 10-12 сәгать буе гел нәрсәдер кимерергә һәм көн саен 30 килога якын бамбук үрентесе һәм яфрагын ашап бетерергә мәҗбүр.

Мари иленә сәяхәт

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Севастополь оборонасының соңгы командиры булган Петр Новиков, Чехия белән Моравия җирендә партизаннар берләшмәсе төзеп мең батырлык кылган, хәтта сатлык Власовны әсирлеккә төшергән “кара генерал” Даян Мурзин, нәкъ Шакирҗан Мөхәммәтҗанов шикелле үк, дошман амбразурасын күкрәге белән каплаган Бари Шәвәлиев ... – тагын йөзәрләгән татарга Советлар Союзы Каһарманы дигән исем бирелмәде. Ике тапкыр Герой килеш тә иң тәүге канатлы ракеталарны аларга көйләнгән конуралarга утырып сынаган Әмәтхан Солтан, татарлыгыннан баш тартмаган өчен, өченче һәм дүртенче тапкыр Алтын Йолдыз медален, ә армия генералы Алексей Антонов маршал дәрәҗәсен күрә алмады. Татар уллары менә шулай хәтта өлкән агай өчен кан койган чагында да читкә типкәләнде...

“Тәрбия дәресләрендә” без Кондырча елгасы ярында булган коточкыч яуны да, тарихта булмаган Кулик бәрелешен, хәтта Бөек Җиңү символы булган Рейхстагны да искә алып үттек. Хәер, без әлеге вакыйгаларны бер Бәрәңгедә генә түгел, Татарстан яисә Ижау мәктәпләрендә булган очрашуларда да урап үтми идек. Ни кызганыч, Кондырча, Кулик, хәтта Рейхстаг атамаларын бүгенге мәктәп балалары бөтенләй дә белми. Мондый наданлыкны 2007 елдан бирле Татарстан һәм татар халкы тарихын укытмауга гына кайтарып калдыру да дөрес түгел. Үзәктәге Мәгариф министрлыгына һәм хөкүмәткә үз фикере булган зыялы, сынмас рухлы, укымышлы алмаш кирәкмидер. Бер күзәнәкле амебалар белән идарә итү ансат. Үз балаларыбызны менә шушы пресстан чыгарасы иде. Ә Бәрәңгедә, әнә, татар теле һәм әдәбияты, шулай ук тарих укытучылары да житми. Хәтта революциягә кадәр үк “Мөхәммәдия” мәдрәсәсе белән дан тоткан Казанда да математика, сызым, география, биология, физиканы саф татарча укытырдай мөгаллимнәр әзерли торган сыңар институт та юк...

В.ИМАМОВ.

Автор фотолары.



● Гайнан Кормаш портреты.

● Куян музеенда Гайнанчыларга багышланган стенд.



● Кормашның 1944 елның 25 августында җәзалап үтерелүе турында белешмә.

● Куян мәктәбе диварындагы истәлек тактасы.

● Куян мәктәбе музеендагы татар йорты макеты.

● Портянур мәктәбе укучылары.

● Без Бәрәңге мәктәбендә.

Казан ханлыгы чорында Питрәч төбәгендә илледән артык татар авылы булган. Бүген алардан 23 авыл яшәп килә, әлегә шуларның бер дистәсе генә чын татарлыгын саклаган. XVI-XVIII гасырларда урыслаштыру сәясәте белән монда тагын кырыклап авыл нигезләнә. Бу вакытларда татар авыллары тарихлары юкка чыккан, яндырылган... Менә шундый шартларда Мәүлә Колый кеби абыз-шагыйрьләр шанлы сүзләре белән кешеләр күңеленнән ислам рухын җуйдырмаган. Шагыйрь XVII йөзнең икенче яртысында Россия империясендә патшаларны һәм дворян-алпавытларны куркуга төшергән көчле крестьян кузгалышлары чорында иҗат итә һәм фетнәчеләргә теләктәшлек белдерә.

Хикмәтле шагыйрь Мәүлә

Халык хәтеренә хикмәтле шигырьләре, саллы гамәлләре белән кереп калган Мәүлә (Мәула) Колыйның әсәр-хикмәтләре, шәҗәрәләре табылып тора. Соңгысы 1811елны Әлкәй авылында (хәзерге Азнакай төбәге) күчерелеп, 1982 елда Сарабиккол саласында табыла. Иҗаты исә галим һәм язучылар: Фазыл Туйкин, Хатыйп Миңнегулов, Камил Дәүләтшин, Раиф Мәрданов һ.б. тарафыннан яктыртылып килде.

Ул чорда Идел, Чулман, Агыйдел буендагы төрки-татарлар инде алты-җиде гасыр ислам кануннары белән яши. Явыз Иван куштаннары исә соңгы гасырда туктаусыз дингә, мәчетләргә һөҗүм итеп тора. Максатлары – мөселманнарны христиан диненә күчерү, патшага буйсындыру. Ләкин гайрәтле һәм нәселле кешеләр моны кабул итми, кыю диндарлар мәхәлләләргә туплана. Баскыннар хөкүмәте этлеген дәвам итә: халыктан тимерчелекләрне, тегермәннәрне талап, христиан динендәге кешеләргә бирә. Югыйсә төп халыкның шөгыле иген игү бит һәм аларның тегермән тотарга хокукы бар.

Игенчелек гали эштер, кылыр булсаң...
...Иген иккел, рәхмәт өмет итәр булсаң – ди Мәула Колый «Хикмәтләр» китабында, җиргә береккән фидакарь халкын хөрмәтләп.

Куштаннарның тормыш рәвеше эшләмичә дә тамак туйдыруга корылган. Кызганыч ки, бу баскыннар артында патша тора. Алар – урманлы яклардан җыелган кешеләр, җәнлек-кош атып тукланырга өйрәнгән бәндәләр. Урындагы халык гомер-бакый иген иккән, сәүдә иткән, терлекчелектә көч куйган. Менә шушы мохиттә Мишә елгасы буендагы Чыты авылында бер сабый дөньяга килә. Муллa аңа Бәйрәм-Гали исеме куша, чөнки фанилыкка бала килү үзе бер бәйрәм. Имам тоемлый – бу нарасый Гали калебкә малик (олы җанлы булып), Гали мәкам (зур урын) биләр!

Мәула Колый, ата-анаң белдең микән?
Хошнуд (разый) кыйлып игү дога
алдың микән?

Шигъри юллары аның кечкенәдән ятимлегенә ишарә. Ләкин ул туганнары арасында ялгыз түгел. Ата-ана васыятен үтәр кешеләр бар. Алар нәселе диндар һәм зыялы, Казан ханлыгы чорында гөрләп яшәгән Колай авылыннан. Явыз Иван куштаннары бу якларны камап алгач, Идел, Чулман ярларыннан утыз-кырык чакрымдагы авыллардан татарларны куып, йортларына урыс-мукшыларны урнаштырган. Колай авылы Кулаевога әйләнә, ә Бәйрәмгалинең бабалары сөйләвенчә, алар нәселе Мишә елгасының өске өлешенә күченеп, Чытыда төпләнергә мәҗбүр була.

Ата-ана сүзе кабул булмас димә,
алкышы һәм каргышы килмәс димә.
Аларга кылган дога сиңа булмас димә,
бу хәтердән хәсрәт йотып тормак кирәк.
– ди шагыйрь.

Үсә төшкәч, туганнары Бәйрәмгалинең зирәклеген күреп, мәдрәсәгә укырга урнаштыра. Мәчет-мәдрәсәләрнең, гомумән авыл халкы яшәешенең бик авыр чоры була. Урыс руханилары тирә-юньдә монастырьлар төзергә җирләр талап ала. Чикләрен яклау өчен ныгытмалар төзергә Казан өязендәге авыллардан, һәр өч ихатадан аты-арбасы белән бер ир-атны мәҗбүри хезмәткә тарталар.

«Остазымның исме идер менла Мамай», – ди Бәйрәмгали шәкерт. Кем ул остаз? Дини шәхес 1670-1671 еллардагы Степан Разин җитәкчелегендәге Крәстияннәр кузгалышы аша билгеле. 1670 елның 5 сентябрендә Сембер кирмәнен алгач, Разин үзенең гыйлемле хәрбие Хәсән Айбулатовтан «прелестное письмо» яздырта: «От великого войска, от Степана Тимофеевича. Буди вам ведомо казанским посадским бусурманам и абызам начальным, которые мечеть держат, басурманским веродержцам и которые над бедными сиротами и над вдовами милосердствуют – Икшею мунле, да Мамаю мунле, да Ханышу мурзе, да Москову мурзе и всем абызам, и всем слободским и уездным бусурманам... челобитье.... Слово наше то – для бога, и пророка, и для государя, и для войска быть вам заодно, а буде заодно не будете, и вам бы не пенять после. Бог тому свидетель – ничего вам худого не будет, и мы за вас радеем.» [Чернышев Е.И. стр. 200]. Бу вакытта абыз-мулла Мамай Казан ягы мөселманнарының күренекле вә гыйлемле җитәкчесе булган. Абыз кушаматы дини шәхеснең гыйлемлеген, кыюлыгын күрсәткән. Коръәнне яттан белгәнгә Хафиз исемен йөртеп, халыкны үз артыннан ияртүчеләргә «Абыз» дия башлау гадәте яшәгән.

С.Разин күтәрелеше тармар ителгәч, аның теләктәшләре язмышы аяныч тәмамлана. «Хикмәтләр»дә язуынча, мулла Мамай хаҗ юлында вафат була. Халык язмышы, мәхәлләләр торышы Бәйрәмгали карамагына күчә. Имамга остазының эшен дәвам итәргә васыять кала. Патша шымчыларыннан качып, галим-дәрвиш вазифасын алып, Бәйрәмгали инде Бимкә кушаматы белән бик йөри башлый. Тора-бара Меллагол кол исеме астына яшеренә. Соңлап булса да гаилә корып җибәргән кеше бит ул, нәсел дәвамчыларын сакларга кирәк... Башта кыз балалары туа – нык булсын дип Корыч исеме кушалар. Аннан бер-бер артлы өч малай: Дусай, Әкә, Чикә. Җиңел булмый яшь гаиләгә, тәрбия кылу ана җилкәсенә төшә. Аталары халыкка хезмәт итәргә тиеш, чөнки ул шәех-суфи Мамай мөриде.

Күкрәкдә тәкәбберлек йигачы үсде –
Нәфсе менеп ботагына айак басды.

Мәүлә Колый яшьли үзлектән бөек суфичылар: Әхмәт Ясәви, Сөләйман Бакыргани хезмәтләрен укып, гамәл кылу тәҗрибәләрен өйрәнә. Берсенең иҗатын якын итеп, аны иң күренекле остаз дип атый:

Пиримнең Мәхдүми Әгъзам бабалары
Андинмәдәд телар җиһан падишаһлары.
[История татар. Т.5, с.290].

Шигъри хикмәтләре белән халыкка мөрәҗәгать итеп, авыр шартларда милләтенең рухын күтәрергә тырышып яши. Мөселманнарның чыдамлыгы чиксез түгел, чукындыру сәясәте Мишә буен камап алгач, бер төркем халык 1678 елда Мәүлә Колый җитәкчелегендә Биләр җирләренә күченеп китә, дип яза Раиф Мәрданов. [Безнең Мирас. – №3, 2022].

Яңа җирләрдә шартлар туган яктагы кебек булмаса да, табигате бик күркәм.

Күр галәмни, ни гаҗәп –
Мәгънә тулук бер китап
– дип, дөньяга хозурланырга өнди шагыйрь. Хәтта Биләрнең хәрабәләре дә аңа бик якын, ул мондагы тарих катламнарының көчен сизә. Күченеп килү белән Мәүлә гаиләсе белән Болгарга да бара.

...Мөхиб дуслар, бу хикмәтне әйтмеш
көндә
Сиксән сигез ирди тарих ул көн меңдә.
Әйтелде Шәһри Болгар кәндләрендә,
Гасый, хаҗи Мәула Колый сүзли,
дуслар.

Язмасыннан күренә: ул хаҗ да кылып кайткан. Аңа исән-сау булып, армый-талмый эшләргә кирәк. Чөнки аның халкы алдында изге бурычы – мөселманнарның аңын, гыйлемен камилләштерү. Диндарлар арасында аның исеме билгеле, хикмәтләре халык тарафыннан җылы кабул ителә. Китапчыклары кулдан күчерелеп, төрле тарафларга тарала.

Татарларның яшәешендә «өлкән агаларына» ияреп хәмер белән мавыгу абыз-шагыйрьне бик борчый. Бигрәк тә керәшеннәрдәге аяныч хәлне менә ничек тасвирлый:

Адәмиләр һәр нәрсәдин сусун кылса,
«Ул сусун ашлык, йөзем, балдин булса,
Сусун эчмәклектә ул мәет кыл(ма)са, Ул рәвадыр, андин артык эчә күрмәң. Ләззәт табып, йөнә эчмәк харам улыр, Сусамышта бер эчмәклек хәләль улыр, Мәет сөйгәнгә иземдин газап улыр. Сусун тәйу, мәет улганча эчә күрмәң».

Рухи җитәкчеләрне патша куштаннары тарафыннан кысрыклау һаман көчәя бара. Мәүлә Колыйга Биләр җирләрендә дә озак тукталырга туры килми. Петр патша 1696 елда Азов бәрелешләреннән кайткач, мөселманнарга мәрхәмәтлек күрсәтеп, мәчетләр төзергә рөхсәт бирсә дә, өч-дүрт ел үткәч татарларны янә кысрыкларга тотына. Әлеге патша фәрманы чыккач, Мәүлә Колый 1699 елда Шушма буендагы Иске Иштирәк авылына күченеп китә. Абыз–шагыйрь яше сигезенче дистәгә якынлашканда нигә бу төбәккә барып сыенырга була? Чөнки бу мәхәлләдә Чикә улының оныгы Мөхәммәдшәриф, яшь булса да, былтыр Рабгузыйның «Кыйссасел-әнбия» («Пәйгамбәрләр тарихы») китабының күчермәсен тәмамлаган. Ул дәү бабасыннан бәһа бирү көтә. Икенчедән: Иштирәк авылының исеме Мәүләгә үзенең остазы, мулла Мамай фикердәше Иштирәк абызны искә төшереп тора. Ул С.Разинның көрәштәше (русча: Икшей мунла) булып, Казан төбәге халкын Крәстияннәр кузгалышында катнашырга өндәгән. Мәүлә Колый аның каен тузына татар һәм рус телләрендә язган өндәүләре булганын да хәтерли. Бәлки әле бу авылның нигезләнүе дә шул шәхес белән бәйледер. [Асар. 342 бит].

Иске Иштирәк җирләре күркәм һәм бәрәкәтле: таулар, урманнар арасында ышык вә тыныч урында. Абыз-шагыйрь гомеренең соңгы елларын да догада һәм иҗатта уздыра. Газиз халкына йөздән артык хикмәтләрен, берничә поэмаларын калдырып бакыйлыкка күчә. Нәсел дәвамчысы профессор, тарих фәннәре докторы Әкъдәс Борһанов мәгълүматы буенча шагыйрь унсигезенче гасырның беренче унъеллыгында вафат була.

Үлсә надан, малы-милке гүргә бармас,
Галим үлсә, гыйлемлеге үзеннән калмас.
Гыйлем белгән Хакның рәхмәтеннән
калмас...

Мәүлә исеменең гарәпчәдән – ия, хуҗа («Колын азат итүче хуҗа») мәгънәсе күренекле суфи шагыйрь тормышы фәлсәфәсенә тәңгәл килә. Мәүлә Колый гомерен халкы рухы хөрлегенә, азатлыгына багышлый.

Мирсәй ГАРИФ.
Азнакай.

Йолдызлар яна учакта – Учак бер галәм сыман...

Эдуард МОСТАФИН



* * *

Яралардан тамган каным белән
Ташка яздым.
Каурыемны ташка ташламадым, –
Күпме исемсез каберләр җир буйлап
сибелгән
Исемсез ташлар азмы?
Каурыемны шатлыкларга манып
Җырлар яздым.
Мактап яздым зәңгәр җирем язын.

* * *

Шигырьләрем кай җирләрдә
Шәфәкътай бата икән;
Яңгыр булып ява микән,
Боз булып ята микән?..

* * *

Еллар белән санаганда
Гомер бик кыска.
Әгәр сәгатьләргә салсаң, –
Ул озын кыйсса.
Кылган яхшылыклар белән
Үлчәсәң аны, –
Сыеп бетмәсме гомергә
Күбәләк җаны.

БЕР ҖЫР КИЛӘ

Мостай Кәримгә

Бер җыр килә Юлай даласыннан –
Туп-туп иткән тояк тавышы.
Бер җыр килә – Урал бөркетенең
Кай якларга очып барышы?

Бер җыр килә Урал тауларыннан
Оран сала-сала еракка.
Бер җыр килә таулар йөрәгеннән –
Курай моңы булып йөрәккә.

Җырлар килә...
Таулар гына килми,
Бер урында килеш картая.
Урал тауларына чалма чалып
Өченче көн тоташ кар ява.

* * *

Җир йөрәге туңган микән –
Яз аенда бураннар.
Җылынырга кылган кирәк –
Үксеп ялый курганнар.

Җилләр елый җиргә ятып –
Чәчәк кирәк кочарга.
Каз канатын җиргә җәйгән –
Кояш кирәк очарга.

Язлар кирәк нәфрәтемнән
Мәхәббәткә атларга.
«Ялгышларым, кайтмагыз!» – дип
Язган идем ак карга.

ГАЗАПЛЫ ТӨН

Төннәрен килә дә уята,
Үз көен көйләтә, газаплый.
Карышсаң, ишекне яба да
Өстеңнән җиде кат йозаклый.

Су бирми сусата, ач тота,
Янында нәрсәдер кыштырдый,
Кемнәрдер пышылдый колакка –
Тәгаен, акылдан язудыр.

Һәр әйбер үзенчә ялтырый,
Үзенчә тын ала һәммәсе.
Акрынлап ачыла дөньяның
Тормышның, яшәүнең мәгънәсе.

Теленә килә бу зур җиһан,
Җанлана иң изге ташлары,
Күкләрнең капусы ачыла –
Илаһи бу мизгел!

Күңелдә җыр туа башлады.

* * *

Ач кешенең корсагыдай
бу төн,
Мондый төнгә бөтен нәрсә
үтем;
Моржалардан ургып чыга
төтен,
Йолдызларга булган
бар өметем.
Йотып тора барлык
җан иясен,
Корбан итә бер ир
җариясен;
Белми күктә йолдыз
җан бирәсен,
Урап тота юлчы
дилбегәсен.
Йота бу төн барлык
ялгышларны.
Аты эзли сулы
ялгашларны;
Күтәрерме дөнья
каргышларны?
Төн йотмаса очкан
кургашларны.
Мин дә сыйдым бу төн
карынына –
Басып торам менә
карурманда.
Күңел пакь булуы
зарур монда... –
Ә шулай да ялгыз
авыр монда.

ИНДЕ ЯЛКЫНЫҢ НИШЛӘР?

Күпкә җитәрме ялкының,
Бик иртә дөрләп киттең.
Козгыннар чукый башласа,
Тәнеңдә бармы итең?

Күңелеңдә җитәрлекме
Илһам дигән чималың,
Дан кебек корттан сакларлык
Бармы синең иманың?

Бик-бик борчылып сорыймын:
Бармы синдә ул көчләр?
Кинәт кенә кабындың да...
Инде ялкының нишләр?

ВАН-ГОГ

Сары кояш. Сары яңгыр.
Сары болыт. Сары җир.
Сары урам буйлап атлый
Сары уйлы сары ир.
Бар да сары. Сөю сары,
Тоташтан күз язмыш та.
Сары карлар сарылалар,
Сары икән бу кыш та!
Җитте, җитте, тукта, хыял!
Ялган бит болар, ялган!..
Ван-Гог булып ач күзеңне –
Кып-кызыл кояш янган.

* * *

Аксыл томан йөзә болында,
Болын исе калган толымда;
Салкын чыкта туңган тезләрең,
Үләннәрдә чыклы эзләрең.
Күзләреңә пәрдә тартмаган,
Карашларың дала - яп-ялан;
Салкын гына суга кермәсен,
Төнлә белән суга кермә син.
Томаулата томан төшкәндә,
Тәм югала авыз пешкәндә;
Бигрәк кыска күлмәк кигәнсең,
Йөрәгеңә салкын тимәсен.
Төн болынга чыгып киткәнсең,
Томан гына харап итмәсен.

* * *

Саллар салып маташканбыз –
Кораблар да төзеп булган.
Инештә чыпырдаганбыз –
Диңгездә дә йөзеп булган.

Париж өстендә ап-ак кар,
Буленда ап-ак имән.
Карт аббат та күзен йомып,
Ап-ак җөббәсен кигән.

Өстәлдә сары чәчәкләр,
Сары хәмер савытта.
Данынннан авыз да итми
Бер гөнаһсыз даһи ята
Париж кебек табутта.

* * *

Фил кадәр мәгънә чыгардык
Бер чыпчык хәтле сүздән.
Әйе, дәрья диеп чумдык,
Ә суы булды тездән.

Агач атларда «чапканбыз», –
Чаптар атлар биеп торган.
(Без уйнап йөргән арада
Кошлар яңа оя корган).
Сабый булып кыйланганбыз,
Күптән ирләр икәнбез бит.
Зәңгәр хыял илләреннән
Ташлы ярга җиткәнбез бит,
Җилкәнбез бит.
Балачактан ниләр алдык
Ирләр булып төшкән ярга?
(Теге ярдан монда килеп
Кош күкәен ала карга).
Яланаяк басып барам
Мең ел элек төшкән карга.

* * *

Йолдызлар яна учакта –
Учак бер галәм сыман.
Шул турыда языйм, дисәм,
Юк кәгазь, каләм сынган.
Табыр идең кәгазен дә,
Каләмен очлар идең;
«Учагың янган вакытта

Еракка очма», – дидең.
Сүнмәсен җирдә учагың, –
Яшәүгә терәк икән.
Җаныңны сал шул учакка, –
Халкыңа кирәк икән.
Йолдызлар булмас гомергә
Күктә дә, учакта да.
Бруно булып кала белик
Утта янган чакта да.

* * *

Әйтәсе сүз күңел төбендә,
Дулап алды, ташып бүген дә.
Әйттем Җиргә: Җирем, тарсынма,
Мин чәчәсе орлык бар сиңа.
Ни булырга әзер син, тимер?
Сука булсаң – җиргә җыр килер.

МАТРОСОВЧЫ

(Дәвамы. Башы 10 нчы санда).

Архив документлары белән танышканда, Новороссийскида дүрт кешенең дошман дзоты амбразурасын каплаулары мәгълүм булды. Шуларның өчесе - татар егетләре. Матросовчы якташларыбызның беренчесен - Сәләхетдин Вәлиуллинны - без Самат ага Шакир китабы буенча яхшы беләбез.

Каһарманнарның икенчесе – кызыл флотчы Сәйфулла Йосыпов. Ул – диңгез пехотасында 143 нче аерым батальон разведчигы. Заманында Казан, Уфа, Ленинград шәһәрләрендә эшләгән. Юрий Стрехнинның 1974 елда «Московский рабочий» нәшриятында басылып чыккан «Отряд Бороды» дигән китабында 1943 елның 7 августында һәлак булган матросовчы батыр турында күп кенә кызыклы мәгълүматлар бар.

Ниһаять, өченче каһарман – Мансур Вәлиуллин. Үзенчәлекле шәхес буларак, бу батырга киңрәк тукталыйк.

Мансур Али улы 1915 елда Татарстанда туган. Әти-әнисе үлгәч, аны Бакуга балалар йортына бирәләр. Ул шунда тәрбияләнә, нефтьче булып эшли, шуннан фронтка китә. Бөек Ватан сугышы чорында 318 нче укчы дивизиянең 796 нчы укчы полкы составында сугыша. Өлкән сержант яу кырында күрсәткән каһарманлыклары өчен 1943 елда «Батырлык өчен» медале, бераз соңрак Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. Әлеге бүләккә ул, 1943 елның 15 сентябрендә Новороссийск янында күкрәге белән дошман амбразурасын каплап, иптәшләренә юл ачканы өчен лаек була. Тик герой әлеге орденны үз вакытында ала алмый, аны бик авыр хәлдә госпитальгә озаталар. Шунда сигез ай дәваланып, яңадан сафка баса ул.

Мансур Вәлиуллин – исән калган тугыз матросовчының берсе. Легендар якташыбыз 1988 елга кадәр гаиләсе белән Әлмәт шәһәрендә яшәде. Тыныч хезмәт фронтында да сынатмаган: 1948 елда – «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен», 1952 елда «Хезмәттәге батырлык өчен» медальләренә, 1966 елда «Почет Билгесе» орденына лаек булган. Сугышчан бүләге исә аны шактый еллар үткәч кенә эзләп таба...

КЕМ СИН, КАЙДАН СИН, САША-ШАКИРҖАН?

Инде легендар Александр Матросовның шәхесе турында да сөйләшик.

Соңгы елларда ачыкланганча, әлеге каһарманның биографиясендә дә озак вакытлар дәвамында серле «ак таплар» яшәп килде. Эзтабарлар тырышлыгы нәтиҗәсендә, матбугат битләрендә аның кайда туганлыгы һәм чын исем-фамилиясе хакында яңа мәгълүматлар игълан ителде. Бу өлкәдә башлап йөрүчеләрнең иң тәүгесе – тугандаш Башкортстанда яшәп иҗат итүче талантлы журналист Рәүф Насыйров. Аның «Совет Башкортостаны» газетасының 1988 елгы 228-233 нче саннарында басылган «Син кайдан, Матросов?» һәм шул ук газетаның 1989 елгы 258-260 нчы саннарында дөнья күргән «Мине «Матросов» диеп атагыз...» дигән язмалары, эзләнү-ачышлары бик кызыклы. Әлеге авторның Уфада «Китап» нәшриятында 1994 елда рус телендә дөнья күргән «Откуда ты родом, Матросов?» дигән документаль-тарихи әсәре дә каһарман турында төпле дәлилләрдән тора. Чыннан да, моңарчы А. Матросовка кагылышлы төрле документларда һәм аның хакында язылган китапларда батырның туган җире итеп Украина, Днепропетровск шәһәре күрсәтелде. Әмма бу дөреслеккә һич тә туры килми. И.Легостаевның «Бросок в бессмертие» китабына кереш сүз язган генерал-полковник И. Медников та бу хакта: «Матросовның балачагы турында нинди дә булса дөрес мәгълүматлар сакланмаган», – дип, ачыктан-ачык искәртеп үтә. Тагын бер саллы дәлил: моннан байтак еллар элек «Правда» газетасында Мәскәү язучысы М.Шкадаревичның Днепропетровскига барып, Матросовның туган җирен ачыклау белән шөгыльләнүе турында хәбәр ителгән иде. Әмма анда ул Матросовка кагылышлы берни дә таба алмый.

Мин үзем дә, Подольскидагы Үзәк архивта эшләгән вакытта, А. Матросовны бүләкләүгә кагылышлы документлар белән җентекләп таныштым. Тик аларда да батырның туган җире күрсәтелмәгән иде (33 нче фонд, 682525 нче тасвирлама, 32 нче эш, 305-317 нче битләр).

Ә кайдан, кем соң ул Александр Матросов?

«...Башкортостанның Учалы районындагы Кунакбай авылында туып-үскән ул, – дип яза Р. Насыйров. – Матросовның чын фамилиясе – Мөхәммәтҗанов. Исеме – Шакирьян. Әтисе – Юныс. Әнисе – Мөслимә...»

Ә ничек Мөхәммәтҗанов Матросов булып киткән соң? Аңа да җавап бар. Гражданнар сугышыннан гарипләнеп кайткан, өстәвенә сукыр да булган, әмма бик җор сүзле, шаян табигатьле, хыялга бирелүчән, әкиятләр сөйләргә яратучы Юныс солдат гаиләсендә 1923 елның 5 февралендә туа Шакирьян (татарча исеме Шакирҗан була инде). Әнисе үлгәч, әтисе Фәрхиямал исемле икенче хатынга өйләнә. Яшәү шартлары үтә авыр була, иске генә мунчада көн күрәләр. Ашау-эчү ягы да бик такыр. Аптырагач, Шакирҗан 1934 елда, 11 яшендә, авылны ташлап, читкә китә. Шуннан соңгы тормышы балалар йортларында, хезмәт колониясендә үтә. Казанда да калган аның эзләре...

Үтә фәкыйрьлектә яшәгән туган авылына кире кайтаруларыннан шикләнеп, Шакирҗан үзенең туып-үскән төбәген дә, чын исем-фамилиясен дә үзгәртергә мәҗбүр була. Матрос киеменә гашыйк егет Саша Матросовка әйләнә һәм соңыннан шул исем-фамилия белән бөтен дөньяга танылa...

Тарихта мондый гыйбрәтле мисаллар шактый. Актаныш районының Зөбәер авылында туган атаклы партизан, Советлар Союзы Герое Гатаулла Минаев, мәсәлән, ил күләмендә Николай Орлов буларак билгеле. (Бу хакта Шамил Рәкыйпов «Мәтрүшкәләр һаман хуш исле» дигән кыйссасында бик җентекләп яза.) Саный китсәң, байтак алар – мондый асыл азаматлар!

Башкортстандагы каләмдәшебез Рәүф Насыйровның русча китабында тагын ике кызыклы фактка тап булдым. Аларның беренчесе – Александр Матросов белән Шакирҗан Мөхәммәтҗановның фоторәсемнәрендәге искиткеч охшашлык, тәңгәллек! Бу хакта СССР Юстиция министрлыгының суд медэкспертизалары буенча Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү институтының махсус белешмә дә бирелгән (171 бит).

Икенче факт исә – әлеге каһарманның нинди милләттән булуы турында. Р. Насыйров китабында: «А.Матросов по национальности был башкир или он был похож на башкира», – дип язылган...

Ә менә армия генералы, Россия Федерациясенең Хәрби фәннәр академиясе президенты Мәхмүт Гәрәев 2006 елда Мәскәүдә «Закон и порядок» нәшриятында чыккан «Татары. Воины. Труженики. Патриоты» дигән 396 битле китапның (авторлары М.Хәкимов, М.Сәфәров) кереш өлешендәге язмасында болай дип белдерә: «Александр Матросов (Шакир Мухаметзянов) – сын татарского народа... Его легендарный подвиг во время войны повторило много бойцов. Среди них более десятка воинов татар: Газинур Гафиятуллин, Барый Шавалеев, Абдулла Салимов... Многие из них не удостоены никаких наград...»

Хәзер инде Саша-Шакирҗан тиңдәшсез батырлык үрнәге күрсәткән көнгә дә тукталып үтик.

СССР Оборона Халык Комиссары И. В. Сталинның 269 санлы приказында әлеге дата 1943 елның 23 феврале дип күрсәтелсә дә, ул дөреслеккә туры килми. Александр 27 февральдә һәлак була. А.Матросовны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итүче командирлар әлеге датаны 23 февральгә – Кызыл Армиянең туган көненә күчереп, махсус шулай эшләгән. Бу хакта А. В. Сульдинның «История Великой Отечественной войны. Полная хроника 1418 дней/1418 ночей» дигән 716 битле энциклопедик китабында (М., изд-во «Астрель: Олимп», 2010), 351 нче биттә түбәндәгеләр язылган:

«По официальной версии, рядовой Александр Матвеевич Матросов (1924-1943) в бою за деревню Чернушки в Псковской области в критический момент бросился к немецкому дзоту, откуда строчил пулемет, и закрыл своим телом его амбразуру. На самом деле Матросов совершил свой подвиг 27 февраля, а не 23 февраля (дату изменили в том же 1943 году сознательно, приурочив ее к годовщине Красной Армии)…»

* * *

«Матросовчылар» дигәннән безгә хәзер, искитмәле батырлык үрнәге күрсәтеп тә, исән калган каһарманнарның исем-фамилияләре дә яхшы билгеле. Госпитальләрдә озаклап дәваланганнан соң, терелеп, үз аякларына баскан ватанпәрвәрләрдән казах Сабалак Оразалинов, украин Владимир Майборский, грузин Георгий Майсурадзе, яһүд Товье Раиз, рус егетләре Леонтий Кондратьев, Степан Кочнев, Александр Удодов белән бергә, татар каһарманнары Мансур Вәлиуллин, Әхмәтсафа Мостафин исемнәрен дә зур горурлык хисләре белән искә алабыз.

ДАНЛЫ ИСЕМНӘРЕ – ГЕЛ ИСТӘ!..

Ә хәзер үзебез эзләп тапкан каһарман якташларыбыз һәм милләттәшләребез белән якыннанрак таныштырып үтәбез.

1. Сәмигулла Гарифулла улы КӘРИМУЛЛИН – 21 нче гвардияче укчы дивизиянең 69 нчы гвардияче укчы полкы политругы. 1906 елның 30 (17) июлендә Мамадыш өязендәге Югары Арбаш авылында туган (хәзер бу авыл Кукмара районына керә). 1942 елның 31 мартында Смоленск өлкәсенең Сычевка районындагы Холминка авылы янында безнең сугышчыларны гитлерчыларга каршы атакага күтәрә һәм, коралдашларына җиңү юлауда булышу өчен, дошманның ут өермәсен күкрәгә белән каплый.

2. Әхмәт Готуф улы МӨХӘММӘТОВ – 1941 елның августында Бөгелмә шәһәрендә оешкан 352 нче укчы дивизиянең 1162 нче укчы полкы өлкән сержанты. 1919 елда туган – Ленин комсомолы яшьтәше. 1942 елның 12 июле иртәсендә ул Смоленск өлкәсенең Груздево авылы янында, фашистларның ут позицияләренә сугышчан разведка ясаганда, күкрәге белән дошман дзоты амбразурасын каплый.

3. Александр Матвеевич МАТРОСОВ (чын исеме – Шакирҗан Юныс улы Мөхәммәтҗанов) – 56 нчы гвардияче укчы дивизиянең 254 нче укчы полкы рядовое, автоматчы. 1924 елда (1923 елда дигән мәгълүматлар да бар) Башкортстанның Учалы районындагы Кунакбай авылында туган. 1943 елның 27 февралендә Псков өлкәсенең Великие Луки районындагы Чернушки авылы өчен барган сугышларда һәлак була. Тиңдәшсез батырлыгы өчен, СССР Югары Советы Президиумының 1943 елгы 19 июнь Указы нигезендә, Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исемгә лаек була.

4. Афанасий Леонтьевич ПАНАРИН – 112 нче укчы дивизиянең танкка каршы ата торган артиллерия взводы командиры, лейтенант. 1924 елда Баулы районының Кырым-Сарай авылында туган. 1943 елның 26 мартында Курск өлкәсенең Ефросимово авылын дошманнан азат иткәндә батырларча һәлак була – күкрәгенә танк шартлаткыч граната кысып, дошман дзоты амбразурасына ташлана.

5. Сәйфулла Гайфулла улы ЙОСЫПОВ – диңгез пехотасының 1943 нче аерым батальоны разведчигы, рядовой. 1912 елда Башкортстанның Чишмә районындагы Салих авылында туган. Татар.

● Әхмәтсафа Мостафин.

● Мансур Вәлиуллин.

● Бари Шәвәлиев.

ГЕРОЙЛАР

Заманында Казан, Уфа, Ленинград шәһәрләрендә эшләгән... 1943 елның 7 августында Новороссийск шәһәре янындагы Долгая тавында күкрәге белән дошманның ут өрмәсен каплый. I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

6. Абдулла СӘЛИМОВ (документларда этисенең исеме күрсәтелмәгән) – 248 нче укчы дивизиянең 902 нче укчы полкы рядовое, пулеметчы. 1917 елда Казанда, Восстание урамындагы 23 йортта туган. 1943 елның 19 августында Ростов өлкәсенең Матвеево-Курганск районындагы Петрополье авылы янында һәлак була. Александровка авылына күмелә. I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

7. Сәләхетдин Хәлиулла улы ВӘЛИУЛЛИН – 18 нче армия карамагындагы 255 нче диңгез пехотасы бригадасына караган 142 нче аерым укчы батальонның 2 нче ротасы парторгы, өлкән сержант. 1903 елда Тәтеш районындагы Келәш авылында туган. 1943 елның 15 сентябрендә Новороссийск шәһәре өчен барган сугышта һәлак була. I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

8. Мансур Али улы ВӘЛИУЛЛИН – 318 нче укчы дивизиянең 796 нчы укчы полкы өлкән сержанты, радиостанция начальнигы. 1915 елда Татарстанда туган. Әти-әнисе үлгәч, аны Бакуга балалар йортына җибәрәләр. Ул шунда тәрбияләнә, нефтьче булып эшли, шуннан фронтка китә. 1943 елның 15 сентябрендә Новороссийск янында күкрәге белән дошманның ут өрмәсен каплый. Әмма исән кала – госпитальләрдә 8 ай дәваланып, яңадан сугышчан сафка баса. «Батырлык өчен» медале һәм Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. Сугыштан соң, М. А. Вәлиуллин Әлмәт шәһәрендә яши, 1988 елда шунда вафат була.

9. Әхмәтсафа Мостафа улы МОСТАФИН – 28 нче гвардияче укчы дивизиянең 235 нче укчы полкы рядовое, автоматчы. 1925 елның 1 октябрендә Мамадыш районындагы Арташ авылында туган. 1943 елның 15 октябрендә Псков өлкәсенең Невель районындагы Горушки авылын фашистлардан азат итү өчен барган хәлиткеч сугышлар барышында күкрәге белән дошман дзоты амбразурасын томалый. Әмма ул, каты яраланса да, исән кала – госпитальләрдә 7 ай чамасы дәвалана. Күрсәткән каһарманлыгы өчен Кызыл Йолдыз ордены, сугыштан соң «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкләнә. 1982 елда вафат булып, туган авылында җирләнә.

10. Арсентий Максимович КАРТАШОВ – 69 нчы гвардияче укчы дивизиянең 208 нче гвардияче укчы полкында отделение командиры, сержант, ВЛКСМ әгъзасы, милләте – чуаш. 1925 елда Буа районындагы Әлшәй авылында туган. 1943 елның 5 октябрендә Кировоград өлкәсендә Днепр буендагы Старое Липово авылы янында һәлак була.

11. Кәрим Исхак улы ИСХАКОВ – 69 нчы гвардияче укчы дивизиянең 208 нче гвардияче укчы полкы рядовое, автоматчы. 1912 елда Кызыл юл (хәзерге Арча) районының Шушмабаш авылында туган. 1943 елның 5 октябрендә, чуаш Арсентий Карташов белән бергә, дошманның ут өрмәсен томалап, Кировоград өлкәсенең Старое Липово авылы янында һәлак була.

12. Газинур Гафиятулла улы ГАФИЯТУЛЛИН – 37 нче укчы дивизиягә караган 20 нче укчы полкның отделение командиры, сержант. 1913 елның 14 гыйнварында элеккеге Шөгер (хәзерге Лениногорск) районының Сугышлы авылында туган. 1944 елның 14 гыйнварында Псков өлкәсенең Новосокольники районына караган Овсищи авылын алу өчен барган сугышта һәлак була. СССР Югары Советы Президиумының 1944 елгы 4 июнь Указы нигезендә, аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

13. Котдус Габдрахман улы ГАБДРАХМАНОВ – 58 нче гвардияче укчы дивизиягә караган 175 нче гвардияче укчы полкның рота командиры, өлкән лейтенант. 1908 елда Бондюг эшчеләр поселогында (Менделеевск) туган. 1944 елның 8 февралендә Кировоград өлкәсенең Лелековка авылы янында һәлак була.

14. Әхмәтгали Мөхәммәди улы МӨХӘММӘДИЕВ (Әхмәт Мөхәммәдов) – 299 нчы укчы дивизиянең 960 нчы укчы полкы разведчигы, рядовой. 1923 елның 3 июлендә туган. Нәсел тамырлары Кукмара районындагы Битләнгер авылына һәм Мамадыш районының Югары Ушмы авылына барып тоташа. Сугышка хәтле Донецк өлкәсенең Красноармейск районындагы Димитров шәһәрендә яши, шахтада эшли. 1944 елның 25 феврале төнендә Кировоград өлкәсенең Грузское авылы янында һәлак була. Күрсәткән батырлыклары өчен Ленин ордены һәм III дәрәҗәле Дан ордены белән бүләкләнә.

15. Филипп Николаевич МАЗИЛИН –161 нче ныгытылган районда́гы 13 нче аерым пулемет-артиллерия батальонының 4 нче ротасында пулемет расчеты командиры, өлкән сержант. 1894 елны хәзерге Аксубай районындагы Козловка (Дмитриевка) авылында туган. 1944 елның 1 мартында Белоруссиянең Жлобин районына караган Мормаль авылы янында батырларча һәлак була: командиры – лейтенант Николай Петрович Жуйков белән берлектә, күкрәге белән дошманның ут өрмәсен томалый. СССР Югары Советы Президиумының 1944 елгы 23 июль Указы нигезендә, Ф. Н. Мазилин һәм Н. П. Жуйков Ленин ордены белән бүләкләнә.

16. Бари Гани улы ШӘВӘЛИЕВ – 31 нче гвардияче укчы дивизиягә караган 95 нче гвардияче укчы полкның 5 нче укчы ротасында отделение командиры, гвардия сержанты. 1925 елда Балык Бистәсе районындагы Түбән Тимерлек авылында туган. 1944 елның 23 июнендә Витебск өлкәсенең Орша районындагы Остров Юрьев (Осинторф) пункты өчен барган сугышларда ул, украин егете – гвардия лейтенанты Иван Абрамович Ильченко белән икаүләшеп, дошманның бер үк ут өрмәсен күкрәкләре белән каплыйлар. I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнәләр.

17. Нух Идрис улы ИДРИСОВ – 313 нче укчы дивизиянең 1070 нче укчы полкында автоматчылар взводы командиры, лейтенант. 1918 елның 16 октябрендә элекке Тәкәнеш (хәзерге Кукмара) районындагы Битләнгер (Аксыбы) авылында туган. 1944 елның 27 июлендә Карелиянең Суоярви районында һәлак була. Күрсәткән батырлыгы өчен I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

18. Николай Дмитриевич ЛИПАТОВ – 150 нче укчы дивизиягә караган 973 нче артиллерия полкының 6 нчы батареясе өлкән телефонисты, рядовой. 1916 елны Татарстанның Биектау районындагы Тимошкино авылында туган. 1944 елның 13 августында Польшаның Грабув авылы янында батырларча һәлак була. 1944 елның 26 октябрендә аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Н.Липатовның исеме үзе хезмәт иткән часть сугышчылары исемлегенә мәңгелеккә кертелә.

19. Хафиз Зариф улы ЗАРИПОВ – 3 нче Украина фронтының Николаевск ныгытылган районына караган 10 нчы аерым пулемет-артиллерия полкының пулемет расчеты командиры, гвардия сержанты. 1906 елда Әлки районындагы Баллыкүл авылында туган. 1944 елның 22 августында Одесса өлкәсендә Днестр лиманын кичкәндә һәлак була.

Күрсәткән батырлыклары өчен, Хафиз Зариф улы өч мәртәбә (!) Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә һәм Сугышчан Кызыл Байрак, III дәрәҗә Богдан Хмельницкий, I дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнә.

20. Зариф Закир улы АЛИМОВ – 23 нче танк корпусы карамагындагы 56 нчы мотоукчы бригаданың 3 нче мотоукчы батальонында взвод командиры, лейтенант. 1921 елда Чүпрәле районындагы Яңа Кәкерле авылында туган. 1945 елның 31 гыйнварында Венгрияне фашист-илбасарлардан азат иткәндә, Веленце күле тирәсендәге Петэнд торак пункты янында һәлак була. Ул да, Бөек Ватан сугышы чорының иң беренче каһарманнарыннан саналган Советлар Союзы Герое – танклар ротасы политругы Александр Константинович Панкратов (1917–1941) кебек, күкрәге белән дошман дзоты амбразурасын каплый. 1945 елның 24 мартында З.Алимовка Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

21. Алексей Петрович ИСАЕВ – 180 нче укчы дивизиягә караган 42 нче укчы полкның автоматчылар отделениесе командиры, сержант, рота парторгы. 1906 елны Югары Ослан районындагы Малая авылында туган. 1945 елның 22 гыйнварына каршы төндә Венгриянең башкаласы – Будапешт өчен барган сугышларда һәлак була. 1945 елның 28 апрелендә аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә. А.Исаевның исеме үзе хезмәт иткән часть сугышчылары исемлегенә мәңгелеккә кертелә.

22. Нургали Сәләх улы АКМАЛЕТДИНОВ – 225 нче укчы дивизиянең 115 нче разведка ротасы разведчигы, сержант. 1921 елда Буа районындагы Шәйморза авылында туган. 1945 елның 22 февралендә Германиянең Опельн районындагы Хельсбердорф торак пункты янында һәлак була.

23. Хәбибулла Хәмидулла улы ХӘМИДУЛЛИН – 334 нче укчы дивизиягә караган 112 нче укчы полк старшинасы. 1906 елда Мамадыш өязенә керүче Зур Өске авылында туган. 1945 елның 18 мартында Көнчыгыш Пруссиядә һәлак була (кабере – Калининград өлкәсенең Багратионовск районындагы Корнево авылында).

24. Әсгать Әхмәтхәниф улы ВАФИН – 5 нче армиянең 159 нчы Витебск укчы дивизиясе карамагындагы 597 нче артиллерия полкында разведка командиры. 1924 елның 22 декабрендә Башкортстанның Дәүләкән районындагы Мерәс авылында туган. Милләте – татар. 1945 елның апрелендә Көнчыгыш Пруссиядә барган хәлиткеч көчле сугышлар вакытында күкрәге белән дошманның ут өрмәсен томалый.

25. Әгъмәлетдин Фәттах улы ФӘТТАХОВ – 293 нче укчы дивизиянең 1034 нче полкы автоматчысы, рядовой. 1919 елда Татарстанның Мамадыш районындагы Урта Кирмән авылында туган. 1945 елның 18 августында Маньчжуриядә дошманның мөһим терәк пунктын штурм белән алганда батырларча һәлак була...

Сүз уңаенда шунысын да әйтик: Әгъмәлетдин – 9 балалы ишле гаиләдә иң соңгысы. Бертуганнарыннан 7 абыйсы да Ватан-Ананы саклау өчен барган изге көрәштә гомерләрен бирә...

Каһарман Фәттаховларга һәм аларны тудырып үстергән бөек Ана – тыл батыры Фатыйха апа Әхмәдиева хөрмәтенә республикабызның Мамадыш шәһәре үзәгендәге «Хәтер паркы»нда махсус мемориаль комплекс төзелде...

* * *

1945 елның августында Азия кыйтгасында сугышның соңгы утлы нокталарын күкрәкләре белән томалап, илебез күгендә Җиңү таңын аттырган каһарманнар арасында безнең якташыбызның да булуы күңелләрдә горурлык хисләре уята. Укчы-автоматчы Әгъмәлетдин Фәттахов, Советлар Союзы Маршалы Р.Малиновский җитәкчелегендәге Забайкалье фронты гаскәрләре сафында, дошманның Квантун армиясенә каршы хәлиткеч һөҗүмнәрдә катнаша. Хинган-Мукден операциясе барышында 36 нчы армия сугышчылары японнарның җиңелмәс дип исәпләнгән 6 мең кешелек Хайлар гарнизонын «тез чүкерә». Шул армиянең гади бер сугышчысы Әгъмәлетдин Фәттах улы Фәттахов, украин егете – 24 яшьлек ефрейтор Владимир Прокопьевич Бульба белән бергә, 18 августта дошман дзотының үлем уклары чәчүче амбразурасын күкрәге белән каплап, үлемсезлеккә атлый...

19 августта инде япон гаскәрләре каршылык күрсәтүләрен тулысынча диярлек туктатып, безнекеләргә бирелергә мәҗбүр була... 2 сентябрьдә исә Икенче бөтендөнья сугышына нокта куела – фашистлар Германиясеннән соң, милитаристик Япония дә үзенең җиңелүен таныйк...

Шәһинур МОСТАФИН.
(«Батырлык кайтавазы» китабыннан).

Сабакташыбыз –

Ниһаять, бу елның апрель аенда, XVII гасырда яшәп иҗат иткән, әсәрләре әхлакый пакьлек һәм дини камиллеккә өндәү белән сугарылган шагыйрь һәм фикер иясе Мәүлә Колыйга багышланган төбәкарафәнни укулар оештырыла.

Мәүлә Колый хакында тәүге тапкыр сабакташыбыз Мөхәммәт Садыйк улыннан ишеткән идек. Мөхәммәт безне үз якташы булган М.Колый иҗаты белән генә таныштырып калмады. Аның борынгы әдәбиятыбызны яратуы, белүе чиксез иде...



● Миргасыйм Гаскәров.



● Мөхәммәт Садыйков.

1961 елның 1 сентябре. Без Казан дәүләт педагогика институтының татар теле, әдәбияты һәм тарих факультетына студентлар булып аяк бастык. Группабызда 25 кеше – барыбыз да авылдан чыккан, күбебез – сугыш ятимнәре. Төркемнең яртысы «өлкәннәр», ягъни мәктәптән соң төрле тармакларда 3-4 ел эшләп алырга өлгергәннәр. Әмма бу «Лаеш шулпасы эчкәннәр»нең барысы да чын мәгънәсендә белемгә сусаучылар, аларда укып кеше булу теләге бик көчле иде.

Институтның, бигрәк тә безнең факультетның нинди авыр сәяси шартларда эшләвен без соңрак, үз җилкәбезгә төшкәч аңладык. Партиянең шәхес культын тәнкыйтьләп чыккан XX съезды үткәнгә нибары биш ел вакыт узган. Бу белем йортында шәхес культы заманында нинди гарасат узуын белүчеләрдән курку хисе чыгып бетмәгән чак. Бер гаепсезгә күпме галимнәр, педагоглар юк ителгән бит. Хәзер дә әйтергә кыен, җан елый – кулга алулар план нигезендә башкарылган, хәтта студентлар да бу бәлагә дучар ителгән икән. Мисал өчен, күренекле галим, язучы, журналист Сәлах Атнагулов кулга алынганда, план тутыру өчен ул җитәкләгән группадан тагын 10 студентны да алып киткәннәр. Менә алар: Садыйков Габдрахман, Муратский Хикмәт, Саидов Харис, Сөләйманов Әсхәт, Гыйльми Әхмәт, Хәсәнов Ислам, Кадыйров Хатип, Вәлиуллин (исеме күрсәтелмәгән) һ.б.

Соңрак, институтның без укыган вакыттагы ректоры, олуг затыбыз Йосыф ага Туишевның да (1906-1984) 1938-1939 елларда ул тәмуг утында янып чыкканын белеп тетрәндек без.

1961-1962 уку елының 1 сентябрендә беренче лекцияне безне студент тормышына кертеп җибәргән сөекле остазыбыз Лотфи ага Яфаров (1900-?) укыды. Дүрт ел буе безгә ана телебезнең нечкәлекләрен, кагыйдәләрен өйрәтеп кенә калмады ул, тормышыбызның авырлыгын да белә, хәлебезне сорашып тора иде.

Әдәбият белеменә кереш фәнен укыткан Абдулла Җамалетдин улы Сайганов (1913-1974) безнең өчен кул җитмәслек галим, олы җанлы кеше иде. Әстерханда туып, туган шәһәрендәге С.Киров исемендәге педагогика институтының рус теле һәм әдәбияты факультетын тәмамлаган, Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм 1950 елда ук «Шәриф Камал» иҗаты турында кандидатлык диссертациясен яклаган педагог иде инде.

Абдулла аганың татар һәм рус әдәбиятын, Европа классикларын бердәй белүенә исебез китә иде. Лекция сөйләгәндә мисаллар кирәк булса, Тукай, Такташ шигырьләрен, «Евгений Онегин» поэмасын яттан сөйләп сокландыра. Абдулла ага группабызның Мөхәммәт Садыйков дигән шагыйрен дә ачып бирде. Борынгы, төрки заманнарга ук караган әдәбиятыбыз хакында сөйләшкәндә булды бу хәл. Абдулла ага Мөхәммәтнең шагыйрьлеген тоеп, үткән чорларда иҗат иткән шәхесләребез хакында сораулар бирә башлады. Группадашыбыз сынатмады: әле бер шагыйрьнең, әле икенчесенең яшәгән чоры, иҗатларыннан өзекләр китереп кенә торды.

Бик канәгать калды укытучыбыз. Мондый фикерләшүләр дә еш була башлады. Аннан соң ул Мөхәммәттән: «Кайсы тирәдә яраландың, Будапештның үзендә үкме?» – дип сорады. Без өнсез калдык. Чөнки ул вакытлардагы әдәпәхлак кагыйдәләре егетләр белән бик ачык, «шәбәеп» сөйләшүләрне тыя иде. Бездән өлкәнрәк Мөхәммәтнең дә тормыш юлын белми идек әле. Күбебезнең әтиләре сугышта һәлак булган. Безнең күңелләрдә алар һаман әкияти геройларга тиң батырлар булып яши. Ә хәзер безнең арада, укытучыбыз үзенә тиң санаган, тыйнак кына сугышчы утыра. Тәнәфестә группадашыбыз янына җыелдык. Сораша торгач, Мөхәммәт үзенең армия сафларында хезмәт иткәндә (1956 елның көзендә) Советлар Союзы белән Венгрия Республикасы арасында булган каршылыкларда катнашырга туры килүен әйтеп бирде. Яраланауын, Польшада лазаретта дәваланауын да искә төшерде.

Бу җәһәттән Абдулла ага Сайгановның да фронттаниләр кичергәнен искә алыйм. Абдулла ага институтны тәмамлагач та сугышка алынган, кавалериядә хезмәт иткән. Одесса өчен барган сугышларда каты яраланып, дошман тылында калган. Искиткеч хәл, караңгы төшкәч, аны аты эзләп таба. Ышануы да кыен – бу изге хайван хуҗасын күпме үлек, яралылар арасында табып алган бит. Әкрен генә аваз чыгарып, ничек итсә иткән, ул аны муенына атландыра алган һәм караңгы төндә үзебезнекеләр ягына алып чыккан. Могҗиза!

Абдулла ага дәваланып чыккач, безнең бәхеткә, армиядән азат ителгән булган икән. Хәзер дә онытылмый бит, чын галим булып истә калды.

Ә Мөхәммәтнең безне гаҗәпләндерүләре тагын булды әле. Шулай бер көнне безнең белән очрашуга атаклы шагыйребез Хәсән ага Туфан (1900-1981) килде. Ул 1956 елны гына Гулагтан котылып кайткан иде. Очрашуга бөтен курслардан да студентлар җыелган. Хәсән ага шигырьләрен укыды. Күбесен яттан сөйләде кебек. Лагерьда ниләр күргәннәре турында сүз кузгатмады. Барыбыз да шагыйрьне йотылып тыңладык. Очрашу тәмамлангач карасак, Хәсән ага Мөхәммәтнең иңбашына кулын салган, нидер сөйләшәләр. Бер-берсенә бик якыннар кебек сизелә. Ул чакта да сорашмадык, оялдык.

Бу якынлыкның сәбәбен группадашымның 2014 елда чыккан «Туган як җылысы» исемле китабыннан укып белдем. Анда Мөхәммәтнең «Хәсән Туфан дәү этием Сабит Садыйк улы Садыйков белән бергә Казан төрмәсендә бер камерада утыра... Дәү эти – сәяси корбан, 1889-1942 елларда яшәгән» дигән аңлатмасы бар.

Укыган елларда ук, Мөхәммәт безнең өчен гади сабакташ кына булмады. Без күп мәсьәләләрдә аның белән киңәшә торган булдык. Үзебезне аның каршында тәртипле, тырышрак итеп тә күрсәтәсебез килә иде. Әдәбиятыбызны да ул белгән дәрәҗәдә белә алмадык, шуңа оялган вакытлар еш булды. Оныта алмаган тагын бер хәлне язып китим. Без Казанда төрле урында (мин, мәсәлән, төзелештә хезмәт куйдым, башкалар да «начальник» түгел) эшләсәк тә, эшчеләр арасында милли кимсетүне сизмәдек. Әмма институтта безгә, ягъни татарларга, карашның аерымрак икәнен тоя башладык. Бердән, безне рус теле һәм әдәбияты укытучылары канәгатьләндерми иде. Лекция, семинарлары кызыксыз, «әйдә, ярамаган тагын сезгә» дигән кебегрәк үтә иде. Институтның китапханәсендә бу кимсенү тагын да көчәя төшә. Чөнки программа буенча укырга тиешле китапларны рус милләтеннән булган китапханәчеләр безгә бирми, әмма янәшә рус группасына күз алдыбызда, бер карусыз биреп җибәрәләр. Бу хәл, кабатлана торгач, безне чыгырдан чыгарды. Мөхәммәттән киңәш сорыйбыз. Ул ректор Йосыф ага Туишев янына керергә киңәш итте. Барыбыз да җыелып, ректорга юл тоттык. Нәтиҗәдә китапларны ала башладык. Тырышлыгыбыз белән җиңдек бугай ул чакта.

Кызганыч, укытучылар алмашынмады. Бәлки, әйбәтрәк белгечләр ул вакытта җитешле дә булмагандыр, авыр еллар иде бит. Әмма безнең тырышлыкны

Мәүлә Колый якташы

● **Студент еллар истәлеге.**

белгәч, укытучыларыбызның хөрмәте артты, шуны тойдык.

Әмма безнең «күрәселәр» 5 нче курска җиткәч башланды. Гомергә онытылмаслык булды шул. V курста беренче лекция Лотфи аганыкы булырга тиеш иде. Аудиториядә көтеп утырабыз – Лотфи ага да, аның урынына керергә тиешле укытучы М.З.Зәкиев тә юк. Кемдер кереп: «Лотфи аганы пенсиягә озатканнар», – диде. Барыбыз да хөрмәтле остазыбызның өенә киттек. Лотфи аганың бик авыр, хәсрәтле вакыты иде. Бердәнбер улы фаҗигале төстә вафат булган, кара кайгы кичергән көннәре... Безне күргәч бераз гына җиңелрәк булды микән, остазыбыз безне күрүгә шат иде. Соңрак татар теле һәм әдәбияты кабинетында Лотфи ага белән саубуллашу кичәсе оештырдык, башка педагогларны да чакырдык. Мондый хәлне күргәннәре булмаган, исләре китте. Әмма дәрес вакытында аудиториядән китүебез (укытучы кермәсә дә) зур тәртипсезлек булган икән, безгә моны еш искә төшерделәр.

Гаеп эзләсәң, табып була инде. Педагогика тарихыннан безгә Таһир абый Корбанов керә иде. Әйбәт сөйли, кирәкле фән, тыңлыйбыз. Тик атаклы педагогларны санаганда, ник бер татар исеме аталсын – Песталоцци, Успенский һ.б. инде. Шулай бер тапкыр, лекция беткәч, янына бардым да сорадым: «Ник безгә татар педагогларының исемнәрен әйтмисез, араларында әйтергә ярарлыклары булмаганмы?» Укытучыбыз: «Аларны киләчәктә сезгә белергә язсын», – диде. Әмма бу хакта кемгәдер әйткән, группа җитәкчебез Мәдинә апа Җәләлиева керәп: «Тиешсез сораулар биреп алҗытмагыз, өлкән кеше үзе беләдер», – диде. Бу соравым да ярамаган эш булды, ахры.

Өстәвенә, V курста без бәхетсезләргә «Фәнни коммунизм» фәнен укытырга музыка белгечен билгеләгәннәр икән. Без бу фәннән дәреслекләрне КАИ (авиация институты) студентларыннан алып тордык, өйрәндек. Зачет бирәсе бар бит. Әмма укытучыбыз бу фәнне бөтенләй белми булып чыкты. Хәзер дә аптырыйм –5 нче курс студентлары алдына басарга ничек итеп җөрьәт итте икән бу «педагог» аламасы?

Төркемебездә «отлично»га укучылар бар, бигрәк тә Мөхәммәт һәм Миргасыйм Гаскәров (Миргасыйм безгә 4 нче курста кушылды, бик сәләтле егет, җитмәсә шагыйрь. Мөхәммәт белән тиз дуслаштылар, партада да янәшә утырдылар). Аның «Күңелем мизгелләре» (Казан, 2016) дигән китабы хәзер дә алдымда. Бергә укыган вакытларны искә алып, ул болай дип язган: «Илдәге үзгәрешләрдән канатланган кичәге авыл малайлары һәм кызлары, бүгенге студентлар, рухи күтәренкелек һәм авылда туып-үскәннәргә генә хас үҗәтлек белән, фәннең яңадан-яңа үрләрен яулый. Җәмгыятьнең үсеш законнарын үзләштергән студентларда илдәге вакыйгаларны үзләренчә аңлау һәм анализлау ихтыяҗы туа. Булачак милли кадрларны барыннан да бигрәк Совет империясенең милли мәсьәләдәге җитешсезлекләр борчый».

Мөхәммәт белән Миргасыйм коммунизм фәнен өйрәтергә кергән бичара укытучыны сораулар белән күмә башлады:

– СССРда милләтләр барысы да тигез хокуклы дип әйтәсез бит, алай булгач, ярты миллион халкы булган Казанда ана телендә белем бирүче мәктәпләр ни өчен ике генә?

– Ни өчен татарның үз киносы, яшь тамашачылар театры юк?

– Ни өчен Татарстанга союздаш республикасы статусы бирелмәгән?

– Ни өчен Татарстанда радио татар телендәге тапшыруларны бары ике сәгать кенә алып бара? Һ.б.

Мондый сорауларга музыка белгече ни дип җавап бирсен? Бер дәрескә кергәч, сорау бирү белән, китабын тотып бәрде дә: «Сез миңа мондый сорауны юри бирәсез», – дип чыгып китте. Аннары деканатка керөп: «Бу группада хөкүмәт сәясәтенә каршы милләтчеләр утыра, аларны куарга кирәк» – дигән. Мөхәммәт белән Миргасыймның фамилияләрен дә язып биргән икән. Деканатта татарларны күрә алмаган, безгә СССР тарихының «бер кисәге» буенча семинар «оештыргалап» йөргән Иван Чернов булган. Ул Өлкә комитетына, Дәүләт куркынычсызлыгы органнарына барып сөйләгән. 30 нчы елларда өйрәнеп калган гадәтләре онытылмаган, каһәр!

Менә шулай группабызда тынычлык бетте. Әле беребезне, әле икенчебезне чакырып сорау алулар башланды. Дәресләр юньләп үткәрелми, күңел гел борчуда. Мөхәммәт белән Миргасыйм хакында сораулар бигрәк куркыныч. Имеш, алар «Теплоконтроль» заводында татар яшьләре оештырган яшерен оешмага йөри. Алар кайсыларыгызны үзләре белән иярттә? Анда кемнәр, нинди сүзләр сөйли? Без борчылабыз, елыйбыз, кемнән ярдәм сорарга да белмибез.

Хәзер дә язарга кул бармый. Бер көн аудиториягә И.Чернов килеп керде. Безгә, усал күзләре белән карап, нидер әйтте. Мөхәммәт хакында иде сүзе. Куркудан аңламадым да төсле. Һәм шунда, бу сорау алулардан, нахак бәлаләрдән туйган Мөхәммәт сикереп торды да Черновка таба бара башлады. Мин ничек өлгергәнмендер: «Мөхәммәт, нишлисең, бер сүз дә әйтә күрмә, беләсең ич аны, тагын әллә нинди нахак бәла тагар», – дип группадашымны тотып алдым. Ул миңа карады да кире урынына барып утырды. Миргасыйм да аны тынычландыра башлады. Мин безне күрә алмаган Черновка: «Уходите из группы», – дидем. Бүтәнчә булдыра алмагандыр, безнең нәфрәтне тоеп чыгып китте. Бу адәм актыгы педагогика институтында да укытып йөрде әле.

Шуннан соң чакырып сөйләшүләр деканат яки группада гына булгалады. Дәресләргә йөрдек, әмма хәзер безгә берни дә кызык түгел иде инде. Көч-хәл белән имтиханнарны бирдек, билгеләр кызыксындырудан туктады, ничек тә институтны тәмамлап, диплом алып китү генә борчыды. Группабызның мактанычы, белем, фикерләү сәләтләре белән үрнәк булып торган Мөхәммәт Садыйков белән Миргасыйм Гаскәровка белгечлекләре буенча Казанда калырга рөхсәт булмады. Аларга Пермь өлкәсенә юллама бирелде. Алар белән бик озак күрешә алмадык.

Мөхәммәтне Пермь өлкәсе Березов районындагы Копчик авылында бердәнбер исән калган татар мәктәбенә билгеләгәннәр. Казан хәтле Казаннан татар теле укытучысы килгәнен ишеткән ата-аналар балаларын шушы авылга китерә башлаган. Андый укучылар күбәйгән. Ул вакытта ата-аналарда телебезгә хөрмәт зур булган әле, шөкер.

Ике елдан Мөхәммәтнең китүен алар зур бәхетсезлеккә тиң итеп кабул иткән. Бу сүздә генә түгел, чөнки укучылар яраткан укытучыларының адресын Мәскәү телевидениесе алып барган «Жди меня» тапшыруы аша табып, очрашып, хәбәрләшеп тора икән.

Мөхәммәткә тиң ярны да язмыш шушы якларда үстергән. Пермь өлкәсендә үскән кыз шушы мәктәпкә рус телен укытырга килгән. Исеме Илиза булган да, Татарстанга кайткач, халкыбызның үз кызы Мәрьям исемен алган. Барыбызның да олы рәхмәте аңа. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлап, хәзер Шәледә дин белемен укыту да бәһаләп бетергесез бит.

Пермь якларында «баш җиллләтеп» кайткач, Мөхәммәт – Питрәч, ә Миргасыйм Сарман районы мәктәпләрендә ана теле, әдәбият, тарих фәннәрен укыткан.

Бик озак күрешми торгач группабыз белән бергә җыелдык. «Хатының гына түгел, бәхетең дә икән Мәрьямең» – дидем Мөхәммәткә. Аллага шөкер, Мөхәммәт гаиләсендә бик бәхетле булды. Булды, дим, менә дигән өч егет үстереп, укытучы булып эшләп, ижат эшеннән дә рәхәт табып яшәгән бу ир белән хатын. Мәрьямгә багышланган шигыре генә дә ни тора:

Син һәрвакыт җанны җылытучым,
Хезмәттәшем, дустым, сердәшем,
Сөйгән ярым, бердәнберем, димме?
Белмим, кем дип сиңа эндәшим?

Мөхәммәт хакында бәйрәм көннәр якынлашса, сабакташларым сораша. Телефонны Мәрьям ала, җылы итеп сөйләшә, «мине үзегезнеке итеп санагыз», – ди. Рәхмәт, Мөхәммәт, рәхмәт, Мәрьям. Сез икегез дә үзебезнеке. Без Сезнең белән бәхетле.

Тәминә БИКТИМИРОВА,
тарих фәннәре кандидаты.

БАКЫЙНЫ БАКЫЙ

Быел татар профессиональ рәсем сәнгатенә нигез салган Бакый Урманченың 125 еллыгы билгеләп үтелә. Бу уңайдан ел дәвамында төрле чаралар уздыру каралган. Мәсәлән, туган ягында Буа шәһәрендә музеен ачу, август аенда шунда ук Россия күләмендә фәнни конференция уздыру ниятләнә. Рәссам Марат Мингалиевнең Урманче графикасына багышланган китабы нәкъ менә юбилейга өлгерүе куанычлы хәл. Әлеге хезмәт Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Тасвирый һәм гамәли бизәү сәнгатьләре бүлегендә әзерләнде, фәнни редакторы – бүлекнең җитәкчесе сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанова.

●Автопортрет. 1922 ел.

●Марат Мингалиев.

Маратның графика белән кызыксынуы очраклы түгел. Үзе дә ул – график рәссам. Чаллы галереясында эшли. 2015 елда Татарстан Мәдәният министрлыгының грантына графика станоклары алып, галереяга килгән һәркемне бу сәнгатьнең серләренә өйрәтә. Шунда ук график рәссамнарның иҗат әсәрләреннән халыкара күргәзмәләр оештыра.

Моңа кадәр сәнгать сөючеләр рәссам Б.Урманченың картина һәм скульптураларын гына яхшы белсә, Марат үзенең хезмәтендә Бакый аганың график сәнгате дә зур кыйммәткә ия булуын дәлилләгән. Тикшерү барышында рәссамның меңнән артык рәсеме барлыгы ачыкланган. Беренче график эшләре 1919 елга карый. Нәкъ шул елда Б.Урманче Казан рәсем сәнгате остаханәләренә укырга керә. (1913 елда аның «Закон Божий»дан имтихан бирә алмавы аркасында укырга керә алмаганы билгеле). 1920 еллар башында ук Б.Урманче Тукайның «Шүрәле» поэмасы буенча беренче рәсемнәрен иҗат итә, «Безнең юл» журналына рәсемнәр ясый, гарәп язуына нигезләнгән шрифтны камилләштерү комиссиясендә катнаша һәм «Безнең юл»ның берничә номеры яңа камилләштерелгән шрифт белән басыла. Бу эш тә графика сәнгатенә карый. Шушы ук елларда Казан сәнгать техникумында графика үссен өчен литография остаханәсен оештыра әле.

Ни кызганыч, рәссамның бу чор рәсемнәренең бик азы гына сакланган. 1929 елда «Солтангалиевчелек»тә гаепләнеп кулга алынгач, аны биш елга төрмәгә хөкем итеп Соловкига җибәрәләр. Аннан кайтканда рәсемнәре дә югалган, литография остаханәсе дә тар-мар китерелгән була. Үч иткәндәй биш ел буе Соловкида ясаган рәсемнәрен дә юлда урлыйлар. Әмма рәссам өчен аннан да авыры Казандагы элеккеге танышларының караңгы чырай күрсәтүләре була, шуңа күрә ул Мәскәүгә күчеп китүдән бүтән чара тапмый. Анда Бакый ага татар газета-журналларына рәсемнәр ясый, кабат «Шүрәле» поэмасына әйләнеп кайта. Донбасс шахталарына, Урал тауларына, Башкортстан колхозларына, Ишембайдагы нефтьчеләр янына барып сурәт төшерә.

●«Пар ат» шигыренә иллюстрация.

●«Кәҗә белән сарык» әкиятенә иллюстрация.

1937-1941 елларда Мәскәүдәге Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсе өчен эскизлар иҗат итә. Ни кызганыч, бу рәсемнәрнең кайда икәне билгесез булып кала. Анда исә 33 бит рәсем кергән!

Урманченың график эшләрендә аның тормыш хәлләре, картина, скульптураларга караганда да яхшырак чагыла. Чөнки рәсемнәр тизрәк иҗат ителә. Китапның авторы М.Мингалиев, кечкенә генә рәсемнәрдә дә виртуозлык ярылып ята һәм фикер, мантыйк тоемлана, дигән нәтиҗә чыгарган. 1941 елда Абай Кунанбаевның юбилеена әзерлек максатында Казахстанга чакыру алгач, рәссам юбиляр иҗаты белән генә чикләнми, сугыш темасына үткен рәсемнәр иҗат итә, Казахстан авылларын каләм очына элә, Коркыт турында дастанны рәсемли, «Аршин мал алан» операсына декорация эскизлары ясый. Уйгур телендә Б.Урманче рәсемнәре белән бизәп бастырылган Хуҗа Насретдин турындагы китапны да сәнгать белгече М.Мингалиев графика дөньясында күзгә күренерлек вакыйга дип атаган.

Гомумән, без Бакый аганың эшен яртысын да белмибез икән! Балхашта мәдәният йорты һәм бакыр эретү заводының бизәлешләре, Ташкенттагы Әбугалисина һәйкәле эскизы, Алма-Атада Абай монументы эскизы турында, йә кайсыбыз белә? 1956-1958 елларда Үзбәкстанда яшәгәндә иҗат иткән рәсемнәре шулай ук безгә нәмәгълүм. Алар арасында исә «Мең дә бер кичә» китабының иллюстрацияләре кебек саллы иҗат эшләре бар.

Шулай да иң саллы иҗат әсәрләрен Б.Урманче 1958 елда Казанга кайткач иҗат итә. Туган-үскән якны сагынып, ул кабат Тукаебыз иҗатына, аерым алганда «Шүрәле» поэмасына йөз тота. Аның өчен туган җиргә кайту – Тукайга кайту белән бер дисәң дә була. Зур виртуозлык белән иҗат ителгән 150 рәсем кылкаләм остасының шагыйрь иҗатын ни дәрәҗәдә нечкә тоемлавын күрсәтә. Китап авторы Бакый аганың стиле үзгәрүенә игътибар иткән. Бу юлы ул Шүрәлене бөтенләй бүтәнчә сурәтли, урман шигъриятен тасвирлый, дип искәрткән. Чыннан да, бу чор рәсемнәрендә Шүрәләнең урман, табигать белән аерылгысыз береккәнен күрәбез. Биредә автор, әйтерсең тарихыбызның мәҗүсилек чорына кайткан. Рәсемнәрдәге Шүрәле бер дә усал түгел, киресенчә, аны күргәч, үзең дә сизмәстән елмаеп куясың.

1980 елларда Б.Урманче кабат «Шүрәле»не рәсемли. М.Мингалиев фикеренчә, бу чор рәсемнәре Урманче иҗатында иң камиле. Биредә сызымнардан орнаментлар барлыкка килгән сыман, алар татарның гамәли бизәү сәнгатенә охшаган. Нәтиҗә буларак, М.Мингалиев Урманченың «Шүрәле» поэмасына ясаган рәсемнәрен зур бәяләп, югары сәнгати теленә, шигъри яңгырашына, виртуозларча эшләнешенә игътибарны юнәткән. Бу рәсемнәр XX гасыр татар рәсем сәнгатенең иң яхшы үрнәкләре, дип нәтиҗә ясаган.

Бакый аганың бер «Шүрәле»гә генә никадәр иллюстрация ясаганын күрдек. Әле аның «Печән базары, яхут Яңа Кисекбаш» китабына багышланган рәсемнәре ничаклы! Рәссам бу әсәргә дүрт тапкыр кайта. Бер кайтуында гына да 36 рәсем ясый! Бөтенесенә композиция ачыклыгы, экспрессия, көчле хәрәкәт, шигырьнең ритмына туры китереп элементларны кабатлау хас.

М.Мингалиев үзенең хезмәтендә тагын бер мөһим фикер әйтә, Урманче – иллюстратор гына түгел, интерпретатор, ди. Бу җәһәттән күңелдә ризасызлык туа – ни өчен Б.Урманченың иҗатын Тукайныкы кебек күтәрмибез соң? Олуг шагыйребезнең юбилейлары уңаеннан төрледән-төрле китаплар нәшер ителеп тора. «Шүрәле»

●«Лампа ташучы татар кызы».

●«Татар кызы Шәрифә» .

●Татар милли костюмының эскизы.

●«Шахтёр Сәйфетдинов».

ИТКӘН СУРӘТЛӘР

дә, «Су анасы» да, «Кисекбаш» та төрле рәссамнар бизәлешендә чыкты. Ник Б.Урманче бизәгән «Шүрәле» китаплары юк? Кая Бакый ага рәсемләгән «Кисекбаш» китабы? Рәссам Фәйзрахман Әминов юбилее уңаеннан бу мәсьәләне бер күтәргән идек инде, кабат шуңа әйләнеп кайтырга туры килә. Бакый Урманче, Фәйзрахман Әминов Тукайның иҗатын иң камил рәсемләүчеләр булса да, башыннан ахырына кадәр аларның рәсемнәре белән бизәлгән балалар китапларыбыз юк. Ф.Әминов, үләсен сизенгәндәй, рәсемнәрен Татарстан сынлы сәнгать музеена тапшыра, Бакый аганың да «Шүрәле», «Кисекбаш»лары нигездә шул ук музей тупланмасында. Рәссамнарның бәһасез иҗатын яшереп яту килешә торган эшме? Бу мәсьәләдә Татарстан Китап нәшриятының сәнгать белгечләре һәм музей хезмәткәрләре белән бергәләп эш итүе җитенкерәми.

●Шәмаил. «Аллаһ матур һәм матурлыкны ярата».

Б.Урманченең графикалары шуның белән генә чикләнми, әле Дәрдемәнд иҗаты, төрек фольклорына ясалган рәсемнәре бар. Бер «Хәят» шигыренә генә рәссам утызлап рәсем ясавы билгеле.

Урманченең портретлар галереясы да әйтеп бетергесез бай. Язучылар Әмирхан Еники, Гомәр Бәширов, Мирсәй Әмир, Нәби Дәүли, артист Габдулла Шәмуков, рәссам Абрек Абзгильдин, җырчылар Галина Казанцева, Мөнирә Булатова, Ания Туишева, Гали Ильясов, академик Альфред Халиков һ.б. югары дәрәҗәдә зур осталык белән иҗат ителгән. Портретларны гына аерым альбомга туплап нәшер итсәң, сәнгать уку йортларына бер дигән ярдәмлек булыр иде. Күргәзмәләр оештырылганда күбрәк Урманченең картиналарын күрәбез. Укучы яшьләребез рәссамның график эшләреннән бихәбәр булып кала.

Әле Урманченең каллиграфиясе бар. Рәссам Урта Азияне урап Казанга кайткач дәүләт университетында әдәбиятчы галим Хатыйп Госманов белән бергә каллиграфия курслары ачып җибәрә. Күренекле хәттат, шәмаил остасы Нәҗип Нәккаш та – шул курсларда белем алган Урманче шәкертләренең берсе. Бакый ага исә Коръән аятьләрен, халык мәкальләрен, Тукай шигырьләреннән юлларны бик матур язып калдырган.

Татар милли костюм эскизлары да зур кыйммәткә ия. Бакый ага аларны 1939 елдан башлап 1975 елга кадәр иҗат итә. Бүген 150 ләп татар костюмы эскизы барлыгы билгеле. 1985 елда Урманченың бу эскизларын альбомга туплап нәшер итү тәкъдиме дә була. Әмма эш ахырына җиткерелми кала. 1939 елда иҗат ителгәннәре бигрәк тә аяныч. 16 рәсемнең берсенең дә кая икәне билгеле түгел. Урманче бит аларны Соловкидан кайтып Мәскәүгә күчеп китәргә мәҗбүр булгач, 1941 елгы сәнгать-мәдәният декадасына әзерләнгән татар дәүләт филармониясе өчен иҗат итә. Милләттәшләремнең миңа карашлары үзгәрмәсме, күңелләре йомшармасмы, дип рәсемнәргә бик зур өмет баглый. Әмма безнең үз рәссамнарыбыз бар, дип рәсемнәрне кире боралар. Бу сүзләр Урманченың йөрәгенә ук сыман кадала. Ул рәсемнәрне алырга да онытып тизрәк чыгып китә. Соңыннан бу рәсемнәрне үзенеке дип кемдер файдаланган, диләр...

Китап ахырында кулланылган әдәбият исемлегенә караганда, М.Мингалиев графиканы бик озак өйрәнгән. Урманченең үзенең мәкаләләре исемлеге, катнашкан күргәзмәләре, шул күргәзмәләр нигезендә нәшер ителгән каталоглар, тормыш мизгелләре хронологиясе, хезмәттә очраган шәхесләр турында белешмә үзе аерым китап калынлыгында һәм хезмәтнең кыйммәтен арттыра.

Урманченың шәхесенә тиң зур, җитди хезмәт бу! Һәм байтак еллар сәнгать белемендәге катлаулы, четерекле мәсьәләләр хатын-кыз галимәләребез җилкәсенә төшкәннән соң, сәнгать белемендә яшь, мәсьәләне төбеннән, тамырыннан белүче, эшчән, заман сулышын тоеп яшәүче ир-атның пәйда булуы үзе куандыра.

Миләүшә
ГАЛИУЛЛИНА.

●«Печән базары, яхут Яңа Кисекбаш» поэмасына иллюстрация.

●«Печән базары, яхут Яңа Кисекбаш» поэмасына фриз эскизы. Фрагмент.

ТИТАН ГОМӘР

(Дәвамы. Башы 10 нчы санда).

Рәис булып эшләгәндә

1953-1958 елларда Г.Бәширов Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең рәисе булып эшли. Бер үк вакытта РСФСР Язучылар союзының рәисе Л.С.Соболевның урынбасары да санала (1953-1958). ТАССРның Югары Советы депутаты (1951-1955). СССР Верховный Советына ике тапкыр депутат итеп сайлана (1954-1962). Искәртергә кирәк, Татарстан Язучылар берлеге тарихында Г.Бәширов дәрәҗәсендәге рәисләр тагын икәү генә булды: СССР Верховный Советы депутатлары Гариф Ахунов һәм Туфан Миңнуллин иде.

Бәшировның көндәлекләрен укыганда, коммунистик идеологиянең кешедән зомби ясавына инанасың. «Чит илләрдә, барыннан да бигрәк Америкада, сугышка хәзерләнәләр, – дип язган Г.Бәширов 1955 елның 26 мартында. – Нигә? Нигә балаларны – ятим, яшь хатыннарны үзенең сөекле иреннән мәхрүм итәргә, нигә күкрәп чәчәк атып торган бакчаларны, иген кырларын хәрабәгә әйләндерергә? – дигән сорау куйган язучы. – Әнә аларга нәкъ шул кирәк! Кызганычка каршы, аларга шулай кирәк!»

Социалистик һәм капиталистик системалар арасында үлем сугышы бара, ди автор. «Ул кешеләрнең дә үләсе килми, алар үзләренең хакимиятләрен саклап калу өчен бөтен дөньяны хәрабәгә әйләндерергә хәзер тора. ... Ике система, дөньяга ике төрле караш. Бу ике дошман системаның берсе югалмыйча торып, безнең балаларыбызның бишеге өстендә бомба асылынып торудан котыла алмаячакбыз. Шунысы бик ачык: без җиңәргә тиеш. Чөнки хаклык безнең якта! Гаделлеккә корылган тормыш җиңәргә тиеш!»

Фикерен әле тагын бер тапкыр кабатлап, Американы җиңүгә зур ышанычын мөһерләп куя Бәширов, эзоп теле белән дә яза сыман: «Дөрес, безнең кимчелекләр бик күп әле (Бу очракта ерак арага оча торган бомбардировщикларыбыз булса да, АКШка кадәр атом бомбасын алып бара торган безнең баллистик ракеталарның булмавын күздә тотмаганмы ул? 1959 елда гына андый ракета ясала бездә, Әстерхан өлкәсендәге Капустин Ярдан Камчаткага кадәр 9 мең км очып, тиешле объектны юк итә.– **И.Ф.**). – Ләкин шуңа карамастан без җиңәргә тиешбез. Шулай булмаса, киләчәк буын безне гафу итмәс» (131 б.), – дип өстәп тә куя.

Бүгенге заман кешесе өчен әнә шундый куркыныч тасвирлама. Ләкин 1955 елдагы чынбарлыктан чыгып фикер йөрткәндә, реаль дөньяны күзаллаганда, әдипнең болай язуы дөрес иде. Шул чор өчен гадәти манзара иде бу. Гитлер Германиясе сугышны игълан итмичә генә башлагач, тормышка ачык күз белән карау, авызыбыз бер пешкәч, өреп кабарга өйрәнү иде.

Г.Бәширов Язучылар берлегенең рәисе булып торганда, хезмәттәшләре белән мөнәсәбәтләр шома гына, җиңел генә бармый, ләкин язучыларны кайгыртып, шактый файдалы эшләр башкара, мәсәлән: Аккош күлендә унбиш язучы өчен 400 меңгә төшертеп, дачалар төзеттерә, Бауман урамындагы Матбугат йортында урнашкан Тукай клубына дүрт йөз мең сумлык капремонт ясаттыра, иҗатташларына 1958 елның ахырында Маяковский урамында 23А номерлы йортны салдырып бетерә. Ул рәислек иткән чакта кызганыч, фаҗигале хәлләр дә була, әйтик, җиде өлкән язучы үлә: Таҗи Гыйззәт, Халикъ Садри, «Лобачевский» романы авторы Иван Петрович Заботин, Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә сәхнә артында инфаркттан Бари Рәхмәт вафат була, 1957 елның язында Кави Нәҗми китеп бара. Г.Бәширов вафат иҗатташ дусларын соңгы юлга озатуны оештыра һәм күмүдә катнаша.

Карт гвардиянең тузып килүенә, ә яшь язучыларның бик акрын үсүенә эче нык пошкан рәиснең. Үз гомерендә күп нәрсәне башыннан кичергән Бәширов, халык һәм җитәкчеләр белән еш аралашкан, югары даирәдә исеме дә билгеле, дәрәҗәсе дә зур булган. Союз рәисе буларак, аңа күп җирләрдә булырга туры килгән, шул исәптән Финляндиядә дә. Күрше илдән совет кешесе өчен гаҗәпләнерлек хәлләр күреп кайта ул. 1955 елда ук финнарда хезмәткәрләр 6 сәгать кенә, эшчеләр 8 сәгать эшли, дип язган.

«Халыклар атасы»үлгәч

Автор 1956 елның май аенда Александр Фадеевның, Владимир Маяковский шикелле, үзен-үзе атып үтерү фаҗигасе киң җәмәгатьчелекне, шул исәптән каләм ияләрен дә нык тетрәндерүе хакында үз фикерен белдерә. «Максим Горькийдан соң ул совет әдәбиятын алга җибәрү, төрле милләт язучыларын зур әдәбият дөньясына чыгару өчен бик күп нәрсә эшләгән иде. Ни булган? Бәлки, съездда Шолоховның, аңа кадәр башкаларның аны нахакка рәнҗетүләре башына җиткәндер? ... Ниндидер, аны бик тирәнтен рәнҗеткән берәр хәл булган, күрәсең. Аның башка юл таба алмавы бик аяныч хәл. Бик, бик! Ул бит бик көчле кеше иде» (137-138 б.).

КПССның ХХ съездында Сталинның шәхес культын Хрущёв фаш иткәч, илебездә иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр башлана, әйтерсең лә боз кузгала. И.Сталин үлеп, өч ел ярым вакыт узгач, совет җәмгыятендә аның исемен пычрату, дәрәҗәсен төшерү, һәйкәлләрен алу кампаниясе, шул исәптән Сталин премиясе лауреатларына да кырын карау күзәтелә. Югарыда искәрткәнчә, Илья Эренбург, Константин Симонов, Борис Полевойлар замандашы, 1946-1954 елларда СССР Язучылар союзы идарәсенең генераль секретаре һәм председателе, 1946 елда I дәрәҗәдәге Сталин премиясенә лаек булган А.Фадеев Мәскәүдә атылып үлгән. Казанда исә үз татарларыбыз Г.Бәшировка теш кайраган икән.

● Хәсән Туфан белән Сәйфи Кудаш Гомәр Бәширов бакчасында кунакта.

Г.Бәширов, җәмәгате Кәримә белән, өч айлык иҗат командировкасында Ютазы, Уфа, Сочи, Мәскәүдә йөреп кайтканчы, 1956 елның ноябрь азагында Татарстан Язучылар берлеге партия оешмасының ябык җыелышы була, шунда шәхес культы турында доклад тыңланыла, анда Бәшировны күпме кирәк «илиләр», чыгыш ясаучылар аны «бюрократ» дип атый. Җыелыш беркетмәсен укыгач, Кави Нәҗми чыгышы Бәшировны бик гаҗәпләндергән, иптәшләре әйтүенчә, ике арада зур дошманлык бар, имеш.

К.Нәҗми элекке квартирасыннан яхшы квартирага күчкәч, аның өстеннән самолётлар очып йөргәнне яратмыйча, тынычрак урынга күчәргә теләгән. Ул вакытта да аңа Бәшировның ярдәме тигән. Берлек рәисе, СССР Верховный Советы депутаты буларак, Г.Бәширов югарыдагы җитәкчедән К.Нәҗмине әйбәтрәк квартирага күчерүне үтенгән. Нәтиҗәдә Гомәрнең сүзе ансат үтү сәбәпле, Кавины бер ай узуга ук иң әйбәт квартирага күчергәннәр.

Беркетмәдә: «Төрле республика җыелышларында чыгышлары аз», – дигән Кави Гомәр турында. «Нигә мәгънәсезгә сөйләнеп йөрергә? Мин мәгънәле чыгышларны гына яратам, –дип язган Бәширов. – Кави гомумән сөйләргә, декларатив чыгышлар ясарга ярата, ә мин андыйны яратмыйм, мин, күп сөйләшмичә генә, язучыларга яхшы клуб, унбиш кешелек дача эшләткәнмен икән, бу начармыни? Аз сөйлә, күп эшлә!»» (142-143 б.)

Кеше һәм язучы буларак та, Гомәр Кавидән беркайчан көнләшмәгән. Киресенчә, Нәҗминең әсәрләрен укып үстем, аңардан азмы-күпме язарга өйрәндем, 1932 елда Кави миңа әдәби әсәр язу буенча киңәшләр дә бирде дигән. Бәширов аңа бик үпкәләмәсә дә, аралары бераз вакытка суынып тора. Әмма К.Нәҗми үләсе 1957 елда алар күрешеп, үзара аңлаша, якын дуслар булып аерылыша. Бәширов үзен лирик язучы, ә Нәҗмине – публицист дип атый.

Бәшировның Гариф Гобәй белән дә аралары нык бозылып ала. Декададан соң партиянең өлкә комитетына баргач, Г.Бәшировның күзе шакмак була, җитәкче иптәш кабинетында Г.Гобәй утыра. Ул: «Менә мин как раз Г.Бәширов өстеннән жалоба белән килдем. Гомәр Бәширов – минем дошманым. Мин хәтта ул кергән бәдрәфкә дә кермәячәкмен».

Кешеләрнең күзе шар булды. Ничек инде ул, әллә кайчаннан дус кешеләр, ничек болай кинәт дошман булып китте? Менә шуннан китте инде: «Ул мине батырырга йөри, ул татар балалар әдәбиятын бөтенләй юкка чыгарды, фәлән дә фәсмәтән...»

Йа Аллаһ, нигә мин Гариф Гобәйгә дошман булыйм икән? Нинди сәбәп? Аның минем юлыма аркылы төшкәне, йә анамны, йә атамны үтергәне юк. Нигә дошман булыйм? Менә шул турыда бәхәсләшеп әллә бер, әллә ике сәгать вакыт узды» (150 б.).

Мөгаен, Мәскәүдә декада көннәрендә күренекле балалар шагыйре Бари Рәхмәт җан тәслим кылгач, Гариф Гобәй үзен татар балалар әдәбиятының классигы итеп хис итә башлаган. Әле дә исемдә, без мәктәптә аның «Маякчы кызы» повестен яратып укыдык. Ләкин дәһрилек елларында, алласызлык чәчәк аткан заманда, партиянең өлкә комитеты заказы буенча, Г.Гобәйнең «Коръән серләре» исемле начар әсәр дә язганын туксанынчы елларда гына белдем.

Хрущёв «җепшеклеге» совет илендә булган милли проблемаларны ачып күрсәтте, аерым алганда, Г.Бәширов татар халкының аяныч хәле, туган телебезнең көнкүрештә кулланылыш даирәсе кимүе, СССР шәһәрләрендә татар мәктәпләренең ябылуы турында борчылып язган. 60 нчы еллар башында әйткән аның күп фикерләре бүген дә актуаль яңгырый:

«Әйе, татар халкында мескенлек, «шәкертлек» һаман да дәвам итеп килә. Моны бик күп мисаллар белән расларга мөмкин. Бу нәрсәне башка халыкларның вәкилләре белән очрашканда аермачык күрергә була. Мәсәлән, бездә гыйлемгә, фәнгә омтылышта салкын караш, «барыбергелек» дәвам итеп килә. Революциядән соң гына язмалары башланып киткән милләтләр, мәсәлән, гыйльми исем алуда бездән бик күп алга китте. Кыргызда, хәтта Төрекмәндә, мәсәлән, филология фәннәре докторлары безгә караганда күбрәк. Мин монда Союз республикаларда Фәнни академиясе булуны, ә бездә хәтта филиалны җитәкләрлек татар галимнәре дә булмауны гына күз алдында тоттым. Юк! Татар галимнәре күп кенә булса да, аларның бары бере генә (Мөхәммәт Гайнуллин гына) доктор исемен алуы бик аяныч хәл. Хатип Госман докторлык диссертациясе яклаганда, аны, мәсәлән, төрекмән, башкорт килеп яклый. 700-800 еллык әдәбияты булган татарның хәтта докторлык якларлык галимнәре генә дә юк. Ә аны татар әдәбиятыннан өйрәнеп бөтен дөньяга танылган бүтән әдәбиятларның вәкилләре яклап чыга. Үзбәктә һ.б. халык-

ларда теләсә нинди фәнне алга җибәрүче галимнәр хәзер бетәсе түгел. Мәсәлән, аларда фәлсәфә докторы, тагын әллә кемнәр бар, ә бездә ул юк. Һәм булмас та. Чөнки бездә әдәбиятка һәм фәнгә ачылып килә торган чишмәләр корыды (татар мәктәпләре бетеп бара бит), моннан соң алар терелмәячәк тә. 1962, 5 ноябрь» (178-179 б.).

Хатип Госманның докторлык диссертациясен Мәскәүдә бер елдан соң гына раслаганнар. Кияве Мөхәммәт Мәһдиевнең кандидат-

алмады. Шул ук тынычлык һәм милли хөррият турында бөтен дөньяга сөйләнеп йөрүче подхалим һәм икейөзле Корнейчук һәм аның фикердәшләре татар зиратына тракторлар, бульдозерлар җибәреп, андагы тарихи каберләрне сөреп җир белән тигезләде. Ташларны урамга җәйделәр. Тарихта моның кебек кыргыйлык һәм кабахәтлек бүтән милләтләрдә беркайчан да диярлек булганы юк иде әле. Ул бары безнең социализм илендә генә мөмкин булды. 1965, 1 август»

җөмһүриятләрдәге татарлар турында язу сезнең эшегез түгел, диләр. Анда да совет власте.Ул кешеләрне андагы совет власте кайгырта. Сез анда кысылмагыз, диләр. Анда безнең әсәрләребезне бик кыенлык белән генә чыгаралар, анда журналларга язылу ифрат кыен. Чит өлкәләрдәге татар мәктәпләре һәммәсе дә диярлек ябылды инде.Анда укучы балаларны көчләп рус мәктәпләренә күчерделәр. Болар һәммәсе дә бик зарури мәсьәлә итеп эшләнә. 1965, 1 август» (198 б.).

АГАБЫЗ

лык диссертациясе яклавына чын күңелдән сөендек, тәбрик иттек дигән Г.Бәширов.

Алга китеп әйтсәм, Горбачёвның «үзгәртеп коруы», Ельцинның «демократиясе» нәтиҗәсендә, егерме ел чамасы булса да, татар гуманитар фәненә үсәргә яшел ут кабынган иде. 1990-2000 елларда татар теле һәм әдәбияты, тюркология һәм диалектология буенча Хатыйп Миңнегулов, Резеда Ганиева, Фәһимә Хисамова, Әхәт Нигъмәтуллин, Фирдәүс Гарипова, Хәлиф Курбатов, Марсель Әхмәтҗанов, Илдар Низамов, Рифкать Әхмәтьянов, Марсель Бакиров, Әнвәр Шәрипов, Васил Гарифуллин, Әхмәт Сәхапов, Фәрит Яхин, Рәдиф Җамалетдинов, Дания Заһидуллина, Илида Бәширова, Фәрит Бәшир, Назыйм Ханзафаров, Рәмил Исламов, Дөррия Рамазанова, Фәнүзә һәм Габдерәүф Нуриевлар, Әлфия Гыйләҗева һ.б. филология фәннәре докторы гыйльми дәрәҗәсенә ирешә.

Тугандаш Кырым татарларының ачы язмышына да бик игътибарлы булган, аларны аерып, читтә калдырмаган әдип. «Бакчасарайда татар зираты бар иде (Кырымда). Кырым җөмһүриятен тегә ахмак Хрущёв Украинага бүләк итеп биргәннән соң, Украина шовинистлары андагы тарихи урыннарны харап итеп бетерде. Биналарны әйткән дә юк, хәтта үлекләр дә тыныч кына кала (199 б.).

Яктылыкка өмет аз

Титаныбыз Г.Бәшировның әлеге фикерләре дә бик гыйбрәтле: «Үз вакытында Галимҗанны күтәрә алмадык. Менә хәзер ул башка, кыргыз шикелле яңа әдәбиятларда күтәрелеп чыгуга, Европада яңа булып яңгырый... Ихтимал, монда берникадәр дөреслек тә бар.

Әмма Галимҗан үз хокукын, үз кешелеген нәкъ Айтматовтагы кебек сугышып, яулап алган хатын-кыз образын бирмәде. Аның вакыты да башка иде. Ул изелгән хатын-кыз образын бирде. Бездә бармы Айтматов күтәргән батыр хатын-кыз образы? Ихтимал, юктыр. Әгәр чагыштыра башласаң, аңа охшаганнарны сугыштан соңгы әсәрләрдә табарга мөмкин булыр иде (мәсәлән, Миңлекамал, Нәфисә), ләкин Айтматов хатын-кызы үзенең чорына туры килде һәм ул Шәрык хатын-кызлары арасында (син моны телисеңме, әллә инкяр итәсеңме) беренче урында тора. Безгә менә шуннан үзебезгә нәтиҗә чыгарырга кирәк. Без реалист кешеләр. Тормышта ни күрсәң, шуны язасың. Безнең тормыш мохитебез бик чикле. Безнең «автономиябез» никадәр кысыла барса, безнең мохитебез дә шуның белән бергә кысыла бара. Безне Казан татарлары турында гына кайгыртырга өндиләр. Казаннан тыш башка

Татар әдәбияты тарихында 1956 елда тәүге мәртәбә «Татар поэзиясе антологиясе» дөнья күрә. Гомәр ага шушы китапны бик зур шатлык дип атый. Авылдан килгән әдәбият укытучы сеңлесенә әлеге антологиядән Гыйффәт туташ, Дәрдмәнд, Нәҗип Думави шигырьләрен укый, ә сеңлесе чәй эчүен дәвам иттерә, артык кызыксынмый да. «Безгә аларны укытмадылар!» – дип утыра. Укытмасалар, менә хәзер укырга була бит инде!» (146 б.)

Моның белән нәрсә әйтергә теләгән Бәширов? Әдип фикеренчә, сеңлесе әдәбият программасына кергәннәрен генә балалар белән үтә, ә программага язылмаганнарында аның эше юк. Татарга хас тарлык, йомыклык, белем алуда чикләнгәнлек бу, ди автор, ачуы килеп.

Шуңа күрә бүген безнең проза өлкәсенә Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Кави Нәҗми, Гомәр Бәширов, Афзал Шамов, Мирсәй Әмир, Габдрахман Әпсәләмов, Ибраһим Гази, Фатих Хөсни кебек киң карашлы, киң колачлы язучылар килми. Талантлы шәхесләребез Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Җәмит Рәхимов, Флүс Латыйфидан соң, тарихи повесть-романнарны хәзерге заманда сәләтле әдипләребез Рабит Батулла, Солтан Шәмси, Марат Әмирханов, Вахит Имамов, Ркаил Зәйдулла иҗат итә.

Индус Таһиров, Рәмзи Вәлиев, Дамир Исхаков, Фәйзелхак Ислаев, Искәндәр Гыйләҗев, Фәүзия Бәйрәмова, Тәэминә Биктимерова, Илдус Заһидуллин, Раил Фәхретдинов, Альберт Борһанов, Радик Салихов, Рамил Хәйретдинов сыман тирән гыйлемле тарихчыларны киләчәктә алыштырырлык безнең яшь белгечләр үсәме?

Шулай итеп, язучының шушы көндәлекләре аша Г.Бәширов шәхесенең зурлыгын, иҗатының колачлыгын күрәбез, аның катлаулы һәм актив иҗат юлы үткәнен аңлыйбыз. Гомәр Бәширов иҗатын яңадан күтәрергә кирәк безгә!

Илһам ФӘТТАХОВ,
филология фәннәре кандидаты.

МӘК тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

25 март – «Санаулы кичләр» (А. Володин).
26 март – 11.00, 14.00 - «Малай, бүре һәм Акбай» (Ф.Җиһанша).
18.00 – «Тормышмы бу?» (Г.Исхакый).
27 март – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).
29 март – «Томан» (Г.Сәгыйтова).
30 март – «Сәфәр» (А.Шакиров).
31 март – «Миркәй белән Айсылу» (Н.Исәнбәт).
1 апрель – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

26, 27 март – «Ромео һәм Джульетта» (С.Прокофьев).
30, 31 март – «Искатели жемчуга» (Дж.Бизе).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

25 март – «Өч аршын җир» (А.Гыйләҗев).
26 март – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
27 март – «Асылкош» (Р.Мөхәммәтшин).
28 март – «Нәзер» (Т.Миңнуллин).
29 март – «Кияүләр» (Х.Вахит).
30 март – «Төш» (Т.Миңнуллин).
31 март – «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин).
1 апрель – «Беренче мәхәббәт» (И.Гали).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

25 март – «Яратып туялмадым» (А.Әхмәтгалиева).
26 март – 13.00 - «Сәлам, Актәпи!» (А.Сальникова). 18.00 - «Кичер мине, әнкәй» (Р.Батулла).
27 март – «Ак чәчәкләр кебек...» (Р.Мухина).
29 март – «Шәй-бу! Шай-бу!» (К.Кәримов).
31 март – «Хикмәт әкиятләре» (Н.Хикмәт, В.Тулякова).
1 апрель – 13.00 - «Бәхетле көнем» (Е.Гороховская). 18.30 - «Супер кияү» (Т.Миңнуллин).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

25 март – 11.00, 13.00 - «Волшебник Изумрудного города» (А.Волков). 19.00 - «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).
26 март – 11.00, 13.00, 15.00 - «Волшебник Изумрудного города» (А.Волков).14.00 - «Бүре җиләге» (Р.Зәйдулла).
27 март – 10.00 - «Тыпырдык» (И.Зәйниев). 11.00, 13.00 - «Идет коза рогатая» (М.Протасова). 12.00, 14.00 - «Цветик-семицветик» (В.Катаев).
29 март – «Буратино» (А.Толстой).
30 март – «Приключени Барона Мюнхгаузена» (Р.Э.Распе).
31 март – «Али-баба и сорок разбойников» (В.Смехов).
1 апрель – 11.00, 13.00 - «Приключения Чебурашки» (Э.Успенский). 19.00 - «Самовары» (Р.Таһиров).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

25 март – «Лебединое озеро» балеты (П.Чайковский).
25 март – Ульяновск халык музыка уен кораллары дәүләт оркестры концерты.
27 март – Татарстанның А.Шутиков җитәкчелегендәге халык музыка уен кораллары дәүләт оркестры башкаруында төрле илләрнең композиторлары музыкалары яңгыраячак.
29 март – Филармония әдәби-музыкаль лекторие концерты.
30 март – «Квинтет четырех» музыкаль төркеме концерты.
31 март – «Минуэттан алып тангога кадәр жанрлар тарихы» дип исемләнгән лекция.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

27 март – «Четыре времени года в Буэнос-Айресе» дип исемләнгән концерт. Кичәдә ком анимациясе күрергә мөмкин.

Мәдәни җомга
25 март
№11, 2022

Атнаның сәяси мизгелләре

ЧИКЛӘҮЛӘР ДӘВАМ ИТӘ

Вашингтон Мәскәүнең, Көнбатыш илләре Украина өчен керткән санкцияләрен әйләнеп үтеп, үз икътисадын коткарып калу омтылышын чикләргә җыена икән. Узган атнада АКШ һәм Кытай лидерларының видеоэлемтә аша ике сәгать дәвам иткән сөйләшүләрен дә шул җөмләдә карарга кирәктер. Дөрес, Байден анда Си Цзиньпинга АКШның Украина буенча карашын гына бәян иткән һәм берминди дә таләпләр куймаган. Кытай лидеры исә АКШ һәм НАТОны Украинадагы хәлләр хакында Мәскәү белән аңлашырга чакырган. Аның әйтүенчә, Украина мәсьәләсен озак вакытлы исәп белән хәл итү һәм Европада да шундый ук тәртип вә тотрыклылык урнаштыру өчен, “салкын сугыш” менталитетыннан һәм блоклы каршы торулардан баш тартырга, шулай ук тебәк иминлегенең тотрыклы һәм нәтиҗәле архитектурасын булдырырга кирәк. Си фикеренчә, Кытай һәрчак бөтен дөньяда тынычлыкны яклый торган көч булып калачак. Вашингтон исә Украина мәсьәләсендә Пекинның үз карашларын ачыграк итеп тә әйтүен теләр.

Узган атнада Мәскәү БМО Куркынычсызлык Шурасына АКШның Украинадагы биологик лабораторияләрен тикшерү буенча гадәттән тыш утырыш үткәрү үтенече белән мөрәҗәгать иткән иде. Ә анда бу мәсьәләне биологик һәм агулы коралны тыю турында Конвенция кысаларында хәл кылырга киңәш иткәннәр. БМО Халыкара суды исә Россияне Украинада үткәрә торган хәрби операциясен кичекмәстән туктатырга чакырган. Атнаның башка вакыйгалары турында да рәсми хәбәрләргә күчик. Франция Россия Үзәк банкының 22 миллиард евролык активын “туңдырган”. Яңа чикләүләрне башка илләр дә кертте. Молдова президенты Россиядән үз гаскәрләрен Приднестровьедан чыгаруын таләп итте. Россия тышкы эшләр министры С.Лавров Украинадагы бүгенге хәлләрне: “Это совсем не про Украину. Вернее, не столько про Украину, сколько про мировой правопорядок”, - дип аңлатты. МВФ башлыгы К.Георгиева исә: “Вероятность наступления дефолта зависит от продолжительности военной спецоперации и действий международных санкций”, - дип белдерде. НАТОның чираттагы саммитында Украинага тынычлык урнаштыру миссиясен кертү мәсьәләсе каралачагы да мәгълүм булды. АКШ президенты Джо Байден Россия лидеры В.Путинны төрле сүзләр белән мыскыллады. Кремльдә моны “ярамаган” һәм “кичереп булмый торган” гамәл диделәр, Вашингтонга протест нотасы тапшырылды. Россия белән Украина арасында сөйләшүләр һәм солых турында килешүнең текстын әзерләү эше дәвам итә.

Фоат УРАЗАЙ.

Шигъри җанлы

Әдәбият галиме, шагыйрь Нурмөхәммәт Хисамовка 85 яшь

Татарстанның бер читенә урнашкан гап-гади ишле татар гаиләсендә дөньяга килгән Нурмөхәммәт, тумыштан шигъри җанлы булуы өстенә, рәсем ясауга маһирлыгы, белем бирердәй мәдрәсә эзләп берсеннән икенчесенә күченеп йөргән элеккеге зыялыларыбыз кебек, төрле мәктәпләрдә укуы (әүвәл туган авылы Мунчәли, аннан Яшел Үзән, ниһаять, Чүпрәле мәктәпләре) белән аерылып торгандыр. Һәр адәми затка теге яки бу юнәлештә үсү өчен табигатьтән орлык салына. Табигый талант ачылып китсен өчен дөрес юнәлешеңне, күңеленә, рухыңа якын өлкәне табу кебек алшартлар булу лязим.



● Улы - рәссам Нияз Хисамов эше.

Урта мәктәпне уңышлы тәмамлаганнан соң, шагыйрьлек хыялы Нурмөхәммәтне шөһрәтле Казан дәүләт дәрелфөнүненең татар теле һәм әдәбияты бүлегенә алып килә. Студент эскәмиясенә утыргач, өметләренә Пегас канатлары куелгандай була, җитмәсә яткашы лирик шигырьләр, поэма, сонетлар остасы Ш.Мөдәррис аны иҗатка дәртләндереп тора. «Дуслык» күмәк җыентыгында, хасиятенә өмет нуры индереп, бер төркем шигырьләре басылып чыга. Тәнкыйть өлкәсендә үзен сынау нияте эзләнүчән егетне тәнкыйтьче Фарваз Миннуллин җитәкләгән әдәби түгәрәккә алып килә, аудиторияләрдән тулай торак бүлмәләренә күчкән, кан басымы күтәрелгәнче дәвам иткән бәхәсләр аның рухани һәм гамәли язмышын билгеләүдә хәлиткеч булып китә.

Шул ук чорда киләчәк яшәешенең мәгънәсенә әвереләчәк олы мәхәббәте туа. Шигъри йөрәкле Нурмөхәммәт гомерлек юлдашы, турылыклы хатыны булып китәчәк шомырттай кара күзле, озын кара толымлы, Таиланд кызларыдай чибәр Фәһимә туташка гашыйк була (танылган тел белеме галиме). Сөюе тулышып, Туфан артыннан «Вулканнарга керер идем, шундадыр ул... дисәләр», җөмләсен кабатлар дәрәҗәгә җиткәч, Нурмөхәммәт яраткан кешесенә гаилә кору тәкъдимен ясый. Гөрләтеп студент туе ясап җибәрәләр. Тормышның үз язылмаган кануннары бар шул, шагыйрьлек хыялы, югары уку йортын уңышлы тәмамлау таныклыгы тамак туйдырмый, яшәү өчен каядыр эшлисе, өйгә хезмәт хакын алып кайтасы була.

Абыстаен һәм тәпиенә атлый башлаган улы Айвазны ияртеп, Нурмөхәммәт туган вилаяте Чүпрәле тарафларына юл тота, шунда нәшер ителгән «Коммунар» газетасында ике елга якын хатлар бүлеге мөдире булып эшли. Туган якның җиле дә җылы, йолдызлары да биек дип, тормышын рәтләп кенә җибәрдем дигәндә, профессор Хатип Госман егетне үзенә аспирантурага чакыртып ала. Алсу хыяллары артыннан Хисамовлар гаиләсе киләчәккә өметләреннән башка берәү дә көтмәгән Казанга юл тота. XX гасыр башы сүз сәнгате буенча белгеч әзерләү нияте белән Нурмөхәммәтне дәшкән Х.Госман шәкертенең шагыйрьлек хыялы белән шашынып йөрүен сизенгәч (шул чорда «Яз миңа чәчәкләр китерә» исемле беренче һәм соңгы шигырь китабын әзерли), аспирантын кафедрада эштә калдыру хәстәрен күрми.

Тиздән аның шигырьләр мәҗмугасы басылып чыга, вакытлы матбугатта да Хисамов имзасы еш күренә башлый. Кыска лирик шигырьләрдән, дүртьюллык парчалардан торган әсәрләрендә яшь шагыйрь замандашының дөньядагы урыны, әдәпәхлак кагыйдәләре, кешеләрне якынайткан дуслык җепләре турында ихластан уйлана. Чын шигырь исә ихласлылык чишмәсеннән генә ургылып чыга ала.

Әдәбият фәне белгеченә ихтыяҗ табылмагач, янәдән журналист тәҗрибәсе ярдәмгә килә. 1965-1969 санәләрдә Н.Хисамов – Казанда «Җиңү байрагы» исемле күп тиражлы завод газетасы мөхәррире. 1969 елда аны искә төшерәләр һәм Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына эшкә чакыралар. Яшь галимнең бөтен барлыгын, рухи куәсен, дәртен татар-болгар шигъриятенең безгә килеп җиткән тәүге үрләреннән берсе, татар халкының фал китабы, изге дәфтәр дәрәҗәсендә йөргән Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы били. Бу даһи әсәр аның «икенче» мәхәббәте, юлдашы, күңел юанычы, шатлыгы-кайгысы булып китә. Галимнең XIII гасыр дастанына тугрылыгы, сабитлыгы, хыянәтсезлеге, Кол Галинең шигъри ачышларына мөкиббәнлеге соңрак башка шагыйрьләр иҗатын бәяләүдә дә бизмән, ачкыч була.

XX гасырның соңгы чирегендә – XXI йөз башында җәмгыятебез тормышында, халык язмышында барлыкка килгән үзгәрешләр, демократия җилләре исү иҗтимагый-әдәби тарихыбызны, рухи мирасыбызны яңача бәяләү таләп итте. Элек тыелган темаларны өйрәнү, «ак һәм кара таплар»ны хакыйкать ноктасы үзәгенә алып бәяләү мөмкинлеге туды. Шул нисбәттән әдәбиятыбызның борынгы дәвере совет чорында дин сөреме, мистика йоккан әсәрләр кебек тискәре мөһерләр сугылып, берьюлы бәяләнә килүен дә онытырга ярамый. Шулар арасында ислам дине мотив-сюжетына, фәлсәфәсенә нигезләнеп иҗат ителгән, халык телендә «Йосыф китабы» буларак яшәгән Кол Гали әсәре дә бар иде. Катлаулы структуралы, үз чоры телендә иҗат ителгән бу әсәрне ясалма киртәләр алып ташлангач та тикшерү, аңа фәнни-текстологик бәя бирү җиңел түгел. Ул чор сүз сәнгате әсәрен өйрәнүгә алынган кеше динне, фәнне, эзотериканы берләштергән уртак ноктаны табарга, гарәп имласын үзләштерергә, телләрен үк белмәсә дә, гарәп-фарсы терминологиясен яхшы ук өйрәнергә тиеш була. Мәҗүсидән уртак дингә күчкән чор кешесе галәм кануннарын күңеле белән тойган, мәңгелек алдында сәҗдә кылып, яшәешен шулар нигезендә корган. Кол Гали дастаны каһарманнары да төрле могҗизаларны башларыннан кичереп, рухани үлемсезлеккә юл ала. Гали үзен тикмәгә генә Аллаһ колы дип атамый.

Иҗади гомерләрен бер автор мирасын өйрәнүгә багышлаган ике фән докторын гына беләм. Нурмөхәммәт Хисамов шуларның берсе.

Хәзерге фән дөньясында Хисамов дигәч, Кол Галинең даһи әсәре күз алдына килә, «Кыйссаи Йосыф» поэмасын телгә алуга, Нурмөхәммәтнең олпат гәүдәсе шәйләнә. Зиһенләп карагыз: 1979 елда Мәскәүнең абруйлы «Наука» нәшриятында аның «Кыйссаи Йусуф» Кул Али: «Анализ источников сюжета и авторского творчества» исемле күләмле (254 б.) монографиясе дөнья күрә һәм ул гомумсоюз матбугатында уңай бәя ала. Хезмәт турында «Советская тюркология», «Общественные науки в СССР. Литературоведение», «Вопросы литературы», «Казан утлары» журналларында Э.Нәҗип, А.Кичиков, Н.Шкарлат, И.Нуруллин, М.Госманов кебек олы галимнәрнең куанып, беришесенең исләре китеп язылган мәкаләләре урын ала.

1980 елның апрелендә Мәскәүдә, Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институты каршындагы гыйльми советта Н.Хисамов Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәренә багышланган хезмәте нигезендә кандидатлык диссертациясе яклый. Таләпчән башкала галимнәренең фәнни эшне хуплавының вәкаләтле нигезләмәсе элегрәк дөнья күргән китабы була.

Фәннәр кандидаты булып, өлкән фәнни хезмәткәр дәрәҗәләрен алгач та, Н.Хи-

Нурмөхәммәт

● **Нурмөхәммәт Хисамов (сулдан), Тәлгат Галиуллин, Фоат Галимуллин һәм Мостай Кәрим.**

самов Кол Гали ядкяренә игътибарын киметми. 2001 елда галимнең «Сюжет Йусуфа и Зулейхи в тюрко-татарской поэзии XIII–XV вв. (Проблема версий)» исемле монографиясе дөнья күрә. Н.Хисамовның бу юнәлештәге фәнни эзләнүләренә язучы Г.Ахунов, профессорлар Х.Миңнегулов, Ф.Галимуллин, фольклорчы галимнәр Х.Мәхмүтов, И.Надиров, шагыйрь Ә.Рәшитовлар уңай бәя бирә. Рәссам Нәккаш-Исмәгыйль үз мәкаләсенә «Галимнең уңышы, укучының куанычы», дип мәгънәле исем бирә.

Н.Хисамов урта гасыр төрки-татар шигърияте үсешенә багышланган докторлык диссертациясен шул ук Дөнья әдәбияты институтында 1996 елда яклый. Иң югары фәнни дәрәҗәгә ирешкәч тә, галим дастанны өйрәнүдән һәм пропагандалаудан туктамый. Кол Гали әсәренең әхлакый-фәлсәфи тирәнлегенә, рухи дөньясына үтеп керү юлларын эзли, ишарә-кинаяләрдә татар халкына хас милли сыйфатларны күреп, шигъри энҗеләрне күтәреп ала. Алдагы елларда Йосыф китабын ул хәзерге әдәби телгә тәрҗемә итә. Аны бик теләп, Татарстан китап нәшрияты да, "Раннур" нәшрияты да берсе – 100 мең, икенчесе 50 мең тираж белән бастырып чыгара. Рухи сусауны канәгатьләндерү ихтыяҗы вакытына туры килгән әсәрне хәзер көндез шәм кабызып эзләсәң дә таба алмассың. Ижади эзләнүләренең яңачарак нәтиҗәсе дә озак көттерми. 1991 елда «Мирас» журналында (№ 6-7) Н.Хисамовның «Йосыф-Зөләйха» исемле драмасы басыла.

Кол Гали поэмасы турында чит ил, Мәскәү, Петербург галимнәре дә күп язды, аның сюжеты буенча шагыйрь Р.Харис иҗат иткән либреттога нигезләнгән балет 2006 елда Россиянең иң олы премиясенә лаек булды. Шул чорда ук китап нәшрияты Н.Хисамовның «Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә» (XIII-XV йөзләр)» исемле бик нәзакәт бизәлешле, милли орнаментлы китабын бастырып чыгарды.

Борынгы һәм урта гасыр әдәбиятыбызда татар халкының хәтер һәм рух чагылышын, һәрберебезгә якын, кадерле бала һәм үсмер дәверләрне күргән Н. Хисамов биредә патриот кына түгел, ун гасырлык татар әдәбиятын фәнни, гамәли өйрәнүнең методологиясен һәм концепциясен тәкъдим итә. «Шигърият иҗтимагый-инсани мәсьәләләрнең куелышы җәһәтеннән дә, сәнгатьчә үсеш ягыннан да Кол Гали ирешкән биеклектән кузгалып китә», – ди автор «XIV йөз татар шигърияте кеше идеалы» мәкаләсендә һәм шул фикерен Котб, Хәрәзми, Кятиб һәм Сәйф Сараи кебек шагыйрьләр иҗатында иҗтимагый-фәлсәфи мотивлар үсешендә раслый.

Кол Галидән соң төрки татар поэзиясе сүз сәнгатенә биргән яңалык, халкыбызның шигъри юлдашы – Г.Тукай булды. Бөек шагыйребез иҗатын өйрәнүгә, сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләрен, рухи бөеклеген ачуга Н.Хисамов дистәгә якын мәкаләсен багышлый. «Тукай – яңа гасыр шигъриятенә нигез салучы», «Некоторые трудности в постижении лирики Тукая», «Тукайның шигъри фикерләвендәге шәркый сурәтләр», «Тукай һәм Аурупа шигърияте», «Тукай шигъриятендә һөҗү», «Тукайга якынаю» кебек шагыйрь даһилеге каршында баш иеп язылган мәкалә-чыгышлары шул хакта сөйли. Галимнең Тукай шигъриятен бәяләүдә үз фәнни платформасы бар. Беренчедән, бөек шагыйребез Кол Галиләр кабызган шигъри ут-эстафетаны кабул итеп, чор таләпләреннән чыгып, поэзиянең иҗтимагый тонусын күтәрә, фәлсәфи-әхлакый нигезен тирәнәйтә. Икенчедән, Тукай татар поэзиясен милли мәнфәгатьләргә, халык яшәешенә, тормышына якынайта. Өченчедән, нәфис аһәңле, нечкә, сизгер тоемлы шагыйрь татар теленең бай һәм сыгылмалы көченә, ритмик байлыгына таянып, шигырь төзелешенә реформа ясый, шәкел калыпларының төрле һәм сыйфатлы булырга тиешлеген раслый. Татар поэзиясе тарихында «иң көчле шигъри-мәктәп һичшиксез, Тукай мәктәбе ул. Дистәләгән һәм йөзләгән яшь шагыйрьләрнең төрле басмаларда дөнья күргән шигырьләренә күз салсак, Тукай ритмнары, аңа хас мотив һәм аһәңнәр ярылып ятканын тоемларга мөмкин», – ди галим «Тукай – яңа гасыр шигърияте нигез салучы» мәкаләсендә һәм бу фикерен Тукай шигъри мәктәбеннән күтәрелгән күп санлы мисаллар белән дәлилли.

Кол Гали «оныклары» Тукай, Дәрдемәнд, Туфан, С.Хәким, Г.Афзал, Ш.Галиев, Ә.Баян, Р.Фәйзуллин белән Р.Харис шигъриятләре турында нечкә зәвыклы, энә күзеннән чыккан күзәтүләргә бай мәкаләләрендә Н.Хисамов мәңгелек хакыйкатьләр һәм кыйммәтләр дәвамлылыгы турында уйлана. Аерым алганда, «Хәтер сагында» дип аталган күләмле, күп еллык иҗади эзләнүләрен эченә алган (2004, 556 б.) җыентыгына да югарыда аталган шагыйрьләр иҗаты турында әтрафлы мәкаләләрен урнаштыра. Аерым алганда, «Тирән хакыйкатьләр дөньясы» мәкаләсендә ул түбәндәгечә яза: «Равил Фәйзуллин... аның бәгърен милләтенең тетелеп, чәрдәкләнеп, чәчелеп бетүе өзгәли. Ул кавемендәге аңлы, намуслы замандашына Морзе әлифбасы аша борчылу хәбәре җиткерә. Гадәттән тыш гомумиләштерелгән серле гыйбарәләр. Мәгәр сорауларның хәвефле куелышында, сыйдырышлы серле төшенчәләрдә ил, милләт язмышы абайлана. Дәрдемәндчә колачлы иңләү, күренеш тәгәллеге һәм тирән борчылу... Тик шулай да, Р.Фәйзуллин – «фәлән мәктәп» шагыйре түгел. Дөресрәге хәзер ул үзе мәктәп».

«Р.Харис исемен телгә алуга, күп гасырлык традицияләргә тоташкан татар шигъриятенең иҗтимагый, әхлакый, рухани йөген иңнәренә нык салган буын күз алдына килеп баса», – дип яза Н.Хисамов «Янам, яктыртам, җылытам» исемле мәкаләсендә.

Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры булып эшләгән дәвердә Н.Хисамов Тукай, Дәрдемәнд, Такташ, Туфан кебек бөекләребезнең юбилейларына багышланган фәнни конференцияләрне оештыруга, уздыруга үз өлешен кертте, әтрафлы сүзләре белән тиешле фәнни дәрәҗәне билгеләде.

Нурмөхәммәт барыннан канәгать булып яши торган киң күңелле кеше, башкаларның уңышы, бәхете өчен шатлана белә. Директор булып эшләгән елларда хезмәткәрләренең китапларын бастыру, яшәү шартларын яхшырту турында кайгыртып, хуҗаларның бусагаларын шомартты. Фольклорчы Хуҗи Мәхмүтовны, буйдак егет З.Мөхәммәтшинне шәһәр үзәгенә, олы түрәләр генә яши торган йортка күчерүгә ирешкәч, балаларча куанып йөргәне хәтердә. Әйтерсең лә үзе яңа фатир алган. Н.Хисамовлар гаиләсен бизи торган янә бер сыйфатка тукталмыйча булдыра алмыйм. Нурмөхәммәт белән инде бакыйлыкка күчкән Фәһимә ханым, фәннәренә, иҗтимагый эшләренә хилафлык китермичә, берсеннән-берсе талантлы өч ир-егет тәрбияләп үстерә (татар язучыларыннан милләт горурлыгы булырлык өчәр малай тәрбияләгән ике язучыны гына беләм: А.Гыйләҗев һәм Н.Хисамов, кызлар үстерү җәһәтеннән Зөлфәт белән Ә.Мәхмүдов «беренчелекне» бирмәде). Күрәсең, ун гасырга якын элегрәк язылган әсәр авторы Кол Гали шәхесе, иҗаты, анда «тәкъдим» ителгән әдәп-әхлак кануннары, яшәеш кагыйдәләре белән «аралашып» яшәү Хисамовлар гаиләсенең дә итагатьле, мәгънәле булуына уңай тәэсир иткәндер. Тулаем алганда, Н.Хисамовның фәнни һәм тәнкыйди хезмәтләре туган халкының мирасын саклау, тарихын дөрес бәяләү, поэзиябезнең эчке җегәрен, матурлыгын, сурәтләү чаралары байлыгын ачуга багышланган. Ул яшь фәнни алмаш әзерләүгә җитди игътибар бирә (аның җитәкчелегендә дистәгә якын фән кандидатлары, докторлары пәйда булды), шул ук вакытта үзе дә яшьләрчә дәрт, илһам белән иҗади һәм гыйльми эзләнүләрен дәвам итә. Ул галимлеге, шагыйрьлеге белән беррәттән кәттә киенеп йөрүче, каударланмыйча һәр адымының кадерен белеп атлавы, һәр җөмләсен "әйе" дип башлап җибәрүе, кар бөртекләре кунуына карамастан, бөдрәләрен югалтмаган чәчләре ян-якка таралмасын дигәндәй гәүдәсен туры тота белүе белән чын татар-мишәр баласы шундый була дип мактанырлык Нурмөхәммәт Хисамов – безнең горурлыгыбыз.

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

26 март (шимбә). ***Шәгъбән аеның 23 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында,3.51 сәгатьтә калка, 9.47 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 12.39 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Ютәлдән дәва

Йокы алдыннан 1 стакан мәк "сөте" эчү файдалы. 2-3 чәй кашыгы мәкне балчык савытта төеп, өстенә 1 стакан кайнар су салалар, тондыралар, сөзеп, эчәләр. Яисә 1 чәй кашыгы балга 2 аш кашыгы әнис орлыгы һәм бер чеметем тоз кушып болгаталар, 250 мл су өстәп, кайнатып чыгаралар, сөзәләр. Өлкәннәр һәр 2 сәгать саен 2 шәр аш кашыгы, балалар һәр 4 сәгать саен 1әр аш кашыгы эчәләр. 1 аш кашыгы шикәрне куе көрән төскә кергәнче ут өстендә тоталар, аннары сөтле чынаякка агызалар. Барлыкка килгән "кәнфит"не авызда тулысынча эреп беткәнче суыралар.

27 март (якшәмбе). ***Шәгъбән аеның 24 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 4.31сәгатьтә калка,11.12 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 12.44 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Колак авыртканда

Бик каты колак авыртуны да антибиотиксыз гына дәвалап була. Даруханәдән прополис төнәтмәсе сатып алып, шуңа манчылган мамык кисәген колакка мөмкин кадәр эчкәрәк кертеп куярга кирәк. Тәүлегенә 1 тапкыр 5-7 көн рәттән дәвалану хәерле. Төнәтмәне өйдә дә ясап була: борчак кадәр прополисны кечкенә шешәгә салып, өстенә спирт агызалар, эреп беткәч, марля аша сөзәләр һәм кулланалар.

28 март (дүшәмбе). ***Шәгъбән аеның 25 нче көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 4.57 сәгатьтә калка, 12.43 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 12.48 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Кәефне күтәрәбез

Уникаль методика авторы Алина Рейзельман тәкъдим иткән ризыклар белән тукланганда, депрессиягә бирешми калып була, шулай ук алар көч өсти, баш мие эшен яхшырта, нерв системасын да ныгыта. Беренчесе – балык мае. Омега-3, А, В, Е витаминнары кытлыгы апатия, сәбәпсез сагышлану китереп чыгара, эшләү сәләтен киметә, нерв системасын какшата. Сельдь, шамбы, җәен, скумбрия, палтус, сөләйман балыгын атнасына кимендә ике тапкыр

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга карама

ашарга киңәш ителә, андый мөмкинлек юк икән, биоөстәмәләр – балык мае, омега-комплекслар, D витамины куллану зарур. Сөт һәм әчегән сөт ризыклары – аксым, кальций һәм витаминнар чыганагы. Сыр, кефир, йогуртларны организм җиңел үзләштерә, алар серотонин эшләнүгә булыша.

29 март (сишәмбе). ***Шәгъбән аеның 26 нчы көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында,5.14 сәгатьтә калка,14.14 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 12.53 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

30 март (чәршәмбе). ***Шәгъбән аеның 27 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 5.26 сәгатьтә калка, 15.42 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 12.57 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

31 март (пәнҗешәмбе). ***Шәгъбән аеның 28 нче көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 5.35 сәгатьтә калка,17.07 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 13.02 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

Укроп сихәте

Колак шаулаганда, киптерелгән укроп орлыгын киледә төяләр дә, шуның бер учын термоска салып, өстенә ярты литр кайнар су коялар, ярты сәгать тәнәтәләр. Көненә 3 тапкыр ярты шар стакан эчәләр.

1 апрель (җомга). ***Шәгъбән аеның 29 нчы көне. 30 нчы, 1 нче Ай тәүлекләре. Ай Кучкар йолдызлыгында,5.44 сәгатьтә калка,18.29 сәгатьтә бата. 9 сәгать 24 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 13.07 сәгать.***

Тәүбә итү, гармониягә ирешү көне. Ижат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Әйләнә-тирәне дә, үз хисләреңне дә кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Баш һәм йөрәк зәгыйфь. Арып-талганчы эшләргә, артык кайнар ризык ашарга ярамый. Төрле исләргә аллергия килеп чыгарга мөмкин.

Эремчекле кекс

300 г майлы эремчек, 150 г атланмай, 250 г шикәр, 3 йомырка, 1 г ванилин, 100 г йөзем, 10 г камыркөпшәкләндергеч, 300 г он, бизәү өчен шикәр оны (пудра) кирәк. Йомшартылган атланмайны шикәр һәм ванилин кушып туглыйлар, эремчекне өстәп, миксер белән болгаталар. Аннары 3 йомырканы сытып, тагын туглыйлар. Көпшәкләндергеч кушылган онны әз-әзләп өстәп, миксер белән болгаталар, иң соңыннан йөзем кушалар. Кекс формаларын майлап, өчтән икесенә кадәр камыр салалар, 170 градуска кадәр җылытылган газ мичендә сәгатькә якын пешерәләр. Бераз суынгач, формасыннан алып, шикәр оны сибәләр.

Уразай тарихын барлаучылар

Бөтендөнья татар конгрессында Татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясе җитәкчесе Фәрит Уразаевның архивыннан алынган мәгълүматлар буенча, аның җиде буын бабасы Уразмөхәммәт бәк 1553-1558 елларда нигезләгән Уразай авылы (Әгерҗе районы) бишенче гасырын яши.

Элекке заманнарда бу урыннарда зур күл, куе урман булган. Иген игү өчен җир кирәккәч, урманны кисеп, төпләп, чәчүлек булдырганнар, агачларын елга буендагы базларда күмер, сумала, дегет алу ниятеннән күпләп яндырганнар. Әле хәзер дә бу урыннарда баз урыннары, күмер калдыкларын күрергә мөмкин. Урманнарның нык киселүе сулыкларның юкка чыгуына китергән. Шул сәбәпле авыл ул вакытта Әҗәү елгасы (кайсыбер язмаларда Чаж дип атала) дип йөртелгән елга буенарак күчеп утырган. Ул Иж елгасына кушылып, Чулманга барып тоташа.

Бу елларда Уразай авылы Вятка губернасы, Алабуга өязе, Салагыш волостена кергән. Авыл халкына биш гасыр дәвере҆ндә патша хөкүмәтенең җәбер-золымнарын, фетнә-баш күтәрү сугышларын, халыкларны буйсындыруларны, көчләп чукындыру кебек авыр хәлләрне кичерергә туры килә. Байларга бил бөгеп, ясак түләп яшәгән халыкның да тормышы да җиңел булмаган.

Бүген авыл халкы үзенең бай тарихын барлап яши. Әле быел гына “Чал тарихлы Уразаем” дигән китап дөнья күрде. Басмада авылның һәр нәселе урын алган. Китапның авторы Тәнзилә Ибраһимова хезмәтнең авылдашлары белән бергәләп язылуын әйтә. Ә халык язган тарих – иң дөрес тарих, аны гавам хәтере дип тә атыйлар.

1897 елгы халык санын алу кенәгәләрендәге мәгълүматлар буенча ул елларда Уразайда 80 нигез теркәлгән, 241 кеше исәпләнгән һәм аларның барысы да сословие буенча (ясактан котылу өченде́р инде) башкорт дип язылган. Хәзерге авылда 161 шәхси хуҗалык исәпләнә. Югалган нигезләр дә яисә буш торучы йортлар да хәтсез, ягъни яртысына якыны. Димәк ки, авыл гөрләп яши, бирешми, дип әйтеп булмый. Ләкин Уразайны яшәтү өчен көчен кызганмаучы, кулыннан килгәнне эшләүче гаиләләр дә шактый.

●Тәнзилә һәм Бибел Ибраһимовлар.

Тәнзилә Кәшбетдин кызы, лаеклы ялда булса да, тыныч кына яши торганнардан түгел. Ул бу елларда Уразай авылы тарихын яхшылап өйрәнеп, материаллар туплап, аларны тәртипкә китереп, мәкаләләр язып, аларны китап итеп бастыру мәшәкате яшәде. “Чал тарихлы Уразаем” аның тырышлык нәтиҗәсе.

Гаилә башлыгы Бибел гомере буе авылның ихтирамга ия кешесе булды. Механизатор, тимерче, бригадир вазыйфаларын башкарды. Ә лаеклы ялга чыккач, улы Инсаф белән киңәшкәннән соң, ул авылда

Шуларның берсе – авыл халкының зур ихтирамын казанган, һәр сүзләренә авылдашлар тарафыннан колак салына торган Тәнзилә һәм Бибел Ибраһимовлар. 1968 елда гаилә корган бу пар, 53 ел дәвамында авылның һәр кешесенә үрнәк булып, дус-тату гомер кичерә. Аларның кызлары Әлфия - укытучы, ул ире белән Түбән Кама шәһәрендә яши. Уллары Инсаф исә газ хезмәте белгече, гаиләсе белән авылда гомер итә. Киленнәре Венера, Тәнзилә апаның (лаеклы ялга чыкканчы 36 ел шушы вазифаны башкара) хезмәт юлын дәвам итеп, клуб мөдире булып эшли. Ибраһимовларның 4 оныгы, 4 туруны үсеп килә. Бары да гади генә кебек.

мәчет төзергә карар кыла. Бу изге эшкә фатиха бирүче шушы авыл кызы Наилә Фатыйх кызы Нурмиеваның матди ярдәме белән бурасын бурап, мәчетне күтәрәләр һәм җиткезәләр. Бибел Гайсә улы Аллаһ йортында имам вазифаларын башкарырга алына.

Бу дөньяда бернәрсә дә юктан бар булмый. Бибел абыйның да дингә тартылуы – әби-бабаларыннан мирас булып тапшырылган рухи халәте. Аның бабасы Мөфтәхетдин Нәҗметдинов данлыклы Иж-Бубый мәдрәсәсендә белем алган, аннары үзенең туган авылы Уразайда мәәзин булып торган. Аны Иж-Бубый мәхәлләсенә дә хезмәткә чакырганнар, ләкин ул баш тарткан. Күрәсең, аны бер яктан тамырлары, икенче яктан авылның киләчәге турындагы уйлар тартып кайтаргандыр. Аның бу хезмәткә билгеләнүе турындагы документ бүген музейда саклана. Мөфтәхетдинның сеңелесе Бибел хәзрәтнең бүгенге көндә, бабасының эшен дәвам итеп, авыл мәчетендә имам вазифасын башкаруы гадәти хәл итеп кабул ителде. Җан тартмаса да, кан тарта, диләр бит. Буыннар чылбыры өзелми. Авылдагы һәр эш, һәр чара Бибел Ибраһимов белән киңәшләшеп башкарыла.

Бибел хәзрәтнең бабасы Йосыф та, этисе Гайсә дә Бөек Ватан сугышының авырлыкларын үз җилкәләрендә татыган кешеләр иде, сугыш яралары этисен иртә алып китте. Әнисенә дә, сеңлесенә дә терәк булып, “тормыш йөген” иртә тартып бару, бәлки, Бибелгә чыныгу алырга ярдәм иткәндер, сабый акылын зурларныкына әйләндергәндер. Балаларның, үгез җигеп урманнан утын-печән ташулары, әниләре колхоз эшендә чакта хуҗалык эшләрен башкарулары бүгенгедәй күз алдымда. Шуңадыр, бүген дә төп нигездә урнашкан йортларында да, хуҗалыкта да тәртип. Бакчаларында гөрләп яшелчә-җимеш үссә, бераз гына читтәрәк умарталар тезелеп киткән. Бал кортларының да акыллы кешене генә хөрмәт итүләрен, аңа гына буйсынуларын беләм. Теләсә кем эшли алмый бу эшне. Ибраһимовлар буш вакытларында оныклары белән бергәләп каен пиннекләре бәйли. Мәңгелек йорт – авыл зираты да караулы, ямьле, тәртиптә. 1891 елда төзелеп, 1926 елда янып юкка чыккан Аллаһ йорты урынына яңасы төзелгәч, авыл тагын да нурланды, җәмәгать намазлары укырлык урын булды, дин дәресләре укытырлык мөмкинлек туды. Уразайда татар телендә белем бирүче башлангыч мәктәп – бакча да бар.

Милләтебез бишеге булган авылга хөкүмәтебез дә йөз белән борылып, аны тагын да үстерү, яшь гаиләләргә күбрәк мөмкинлекләр тудыру һәм эш урыннары белән тәэмин итү буенча шартлар тудырса, биш гасыр яшәгән Уразай әле тагын да яшәр һәм чәчәк атар дигән өмет бар.

Вәсилә ХӘКИМОВА.

Әгерҗе районы.

Казанда өч көн дәвамында X Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыены барды. Аның эшендә катнашу өчен Казанга Россиянең 41 төбәгеннән һәм Татарстаннан 530 кече бизнес вәкилләре һәм фермер хуҗалыклары җитәкчеләре җыелды. Җыенның ачылу тантанасы Татарстан Фәннәр академиясендә узды. Аннары делегатлар «Татар халкының традицион тәрбия системасын торгызу һәм укучы яшьләрне базар шартларында эшмәкәрлек идеяләрендә тәрбияләү», «Инновацион технологияләр нигезендә җиләк-җимешне бүгенге шартларда күпләп җитештерү», «Татар авылларында милли тормыш һәм рухи тәрбия», «Авыл эшмәкәрләре җитештергән продукцияне эшкәртү һәм сату» кебек мәсьәләләрне фикер алышу мәйданчыкларында уртага салып сөйләште. Икенче көнне кунаклар Буа районына барып, авыл эшмәкәрләренең эшчәнлеге һәм татар авылларының комплекслы үсеше белән танышты.

Язмышлар китап язарлык

Мәдәният министрлыгының конференцияләр залында үткән «Татар авылларында милли тормыш һәм рухи тәрбия мәсьәләләре» дигән дискуссия мәйданчыгында балаларыбызны тәрбияләү мәсьәләләренә аеруча игътибар бирелде. Утырышны «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Кадрия Идрисова алып барды. Бурятиянең татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Саҗидә Баталова ул төбәктә нибары 7000 гә якын милләттәшебез яшәвен искәртеп, аларны ассимиляциядән саклау кебек максат куюлары турында сөйләде. Бурятиядә катнаш никахлар күп. Татарлар исә бурятлар, руслар белән гаилә кора һәм нәтиҗәдә милләттәшләребезнең исәбе кими бара. Автономия җитәкчеләре төбәктә яшьләрнең игътибарын халкыбызның милли гореф-гадәтләре аша татарларга юнәлтергә тырыша. Моннан тыш Бурятиядәге татарлар туган телләрен онытып бара. 50 яшьтән өлкәнрәкләр сөйләшергә мөмкин, яшь буын телебезне белми. Балалар татарчаны өйрәнергә дә әзер, әмма өйрәтүче юк. Шунлыктан яшьләр өчен махсус комплексы эш алып барырга булганнар. С.Баталова Россия төбәкләрендә яшәүче татарлар өчен «Татар этникасы» белем бирү комплексы турында сөйләде. Проект Россия төбәкләрендәге балалар бакчалары, мәдәният үзәкләре, якшәмбе мәктәпләре һ.б. белем бирү учреждениеләре өчен эшләнгән. Ул – дүрт әсбаптан тора. Татар теле кабинетларын да комплекс үрнәгендә эшләргә мөмкин. Моннан тыш мәкаль-әйтемнәр, рәсемнәр белән «Татар этникасы» дигән мобиль кушымта да ясаганнар. Проект Татарстаннан еракта яшәүче татарларга аеруча файдалы булыр, дип уйланыла. Әсбаплар Россия төбәкләрендәге автономияләргә бушлай таратыла. Татар федераль милли-мәдәни автономиясенең башкарма директоры белдерүенчә, әлеге китапларга ихтыяҗ зур.

Тәтеш районы эшмәкәре – «Колос» предприятиесенең финанс директоры һәм крестьян-фермер хуҗалыгы җитәкчесе Римма Сафиуллова балаларга халкыбызның гореф-гадәтләрен белгертеп, авылда яшәүнең матурлыгын, сагадәтләрен күрсәтеп үстерергә кирәклеген искәртте, ул-кызларыбызның хезмәтнең тәмен кечкенәдән белеп, эшләп үсәргә тиешлекләрен әйтте. Ул җитәкләгән хуҗалыкта бу мәсьәләләргә аеруча игътибар бирелә. Мәскәү өлкәсе татар милли-мәдәни мохтарияте җитәкчесе Фәрит Мохтасоров исә татар балалары өчен милли лагерьлар оештырылуы бик әйбәт икәнлеген искәртте. Әмма балалар берничә атна дәвамында бирелгән тел гыйлемен тиз оныта, шуңа да мохтарият җитәкчесе лагерьларга ул-кызларыбызның әти-әниләре белән килүен оештырганда, нәтиҗәләрәк булырын әйтте.

Җыенның пленар утырышына Россия төбәкләрендә җитештерелгән продукция һәм халык кәсебе товарларыннан «Татар базар» күргәзмә-ярминкәсе дә оештырылган иде.

Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли шурасы рәисе Васил Шәйхразиев залдагыларның игътибарын иң әүвәл яшьләрнең авылдан китүе мәсьәләсенә юнәлтте һәм егет-кызларыбызны туган җирләрендә тормыш кору, шунда эшчәнлек алып барырга җәлеп итү кирәклеген белдерде. Соңгы елларда авыллар картая. Яшьләрне авылда төпләндерергә телибез икән, заманча яшәү мөмкинлекләрен тудыру сорала. Эшмәкәрлек исә – ул авылны саклау чарасы. Милли шура рәисе аларның яшьләрне дә үз эшчәнлекләре белән кызыксындыра алуларына ышаныч белдерде. В.Шәйхразиев авылда мәктәп балаларының бер өлеше эшмәкәрләр ярдәме белән кәсеплек юлына кереп китүе игелекле гамәл булачагын әйтте. Үз көче белән аякка баскан һәм уңышлы эшләүче эшмәкәрләр – яшьләр өчен матур үрнәк. Шул ук вакытта һәр авылда эш урыннары булдыру – җирле хакимиятләрнең дә бурычы. Милли шура рәисе авылларда яшьләрне төпләндерү программасын булдыру бик мөһим икәнлеген, аның комплекслы проект булырга тиешлеген дә билгеләп узды.

Быел Бөтенроссия авыл сабан туе Мордовиянең Ләмбрә районы Аксюн авылындагы «Юлдаш» фермер хуҗалыгы биләмәсендә узачак. Мордовия эшмәкәре Рафыйк Фәтхуллов үзе салдырган зур мәчетне Сабан туе көнне рәсми ачарга ниятләвен искәртте. Ул үзе 2700 гектар җирдә авыл хуҗалыгы культуралары үстерә, 500 баш ат асрый, аның кече предприятиеләрендә 25 төрле хәләл казылык, тутырмалар җитештерелә. Моннан тыш «Юлдаш» кунакханә комплексы да эшләп тора.

Р.Фәтхуллов 2017 елда татар эшмәкәрләре клубын оештырган, анда 40 тан артык якташы әгъза булып кергән. Бу якларда гомер итүче милләттәшләребез халкыбызның гореф-гадәтләрен, телебезне, динебезне, мәдәниятебезне сакларга тырышып яши. Алар Татар мәдәнияте үзәге оештырырга дә ниятли. Якташ язучылары Һади Такташ, Шәриф Камал, Габдрахман Әпсәләмовның музейларын булдырырга да планлаштыралар, татар мәдәниятенең туристик маршрутын төзергә дә исәп итәләр. Ул татар мәдәнияте үзәгеннән башланып, милләттәшләребез яшәгән зур авыллар аша узып, Казанның Кол Шәриф мәчетенә кадәр килергә тиеш.

Пенза өлкәсенең Урта Әләзән авылы Россиядәге иң төзек, җитеш тормышлы татар авылы булуы белән аерылып тора. Билгеле ки, барысы да кешеләренең тырыш, эшчән булуыннан килә. Урта Әләзән турында хәтта «йокламый торган авыл» дигән имеш-мимешләр дә йөри. Хәзерге вакытта Урта Әләзәндә 417 эшмәкәр эшчәнлек алып баруы да авыл кешеләренең булдыклылыгы турында сөйли. Авылның «Агродилер» хуҗалыгы җитәкчесе Йосыф Бухминов та авыл турында бик тә горурланып сөйләде. Бүгенге көндә биредә 2660 шәхси хуҗалыкта 9000 нән артык кеше яши, авылны 12 мәчеттән ишетелгән азан тавышлары ямьләндерә. Урта Әләзәннән яшьләр дә китәргә омтылмый.

Томск өлкәсендә татарның бай мирасы саклана. Томск шәһәрендә татар бистәсе дә бар, анда милләтебезнең агач архитектура үрнәкләре саклана. Әлбәттә, бу йортлар инде тузып бара. Тарихи бистәне алга таба да саклау ниятеннән Томск шәһәре җитәкчелеге андагы йортларны 49 елга арендага бирергә карар кылган. Томск өлкәсенең Абытай авылындагы «Чишмә» җәмгыяте директоры, Себер җирендә беренче булып татар ризыклары кафесы ачучы Фәүзия Зөлбохарова Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән Татар бистәсендәге бер борынгы матур бинаны ремонтларга алырга теләге булуын җиткерде. Ул киләчәктә бу йортның тарихыбызны, милләтебезне күтәрердәй, милли ашлар осталыгын саклау буенча татар дөньясына өлге булырдай үзәк итәргә ниятли.

Мәктәп бетсә, авыл да юкка чыга, дигән сүзләр йөри. Сарман районы имам-мөхтәсибе, эшкуар Сәет хәзрәт Хаков үзенең ул-кызларын, Әлмәт авылы мәктәбендә балалар саны кимүе сизелә башлагач, район үзәгеннән шушы уку йортына йөртеп укыта. Шулай итеп, мәктәптә 116 бала җыела. Авылга 7-8 гаилә күченеп тә кайткан. Бу авылда балаларда атларга мәхәббәт уяталар. Укучылар атлар карап, авыл мохитендә яшәргә өйрәнә.

Оренбург өлкәсе «Төйлегән кошчылык комплексы» директоры Рөстәм Әбдерәхимов кошчылык юнәлешендә гаилә фермасы белән инде дистә елдан артык вакыт шөгыльләнә, аңа бу эшкә «маңгай бәреп» өйрәнергә туры килгән, шактый тәҗрибә туплаган. Ул чыгышында үз башыннан үткән хәлләр белән таныштырды. Хәзер ул өлкәнең татар авылларында 22 ферма сатып алган, аларда өч токымлы 8 мең ана каз тота, бу санны арттырырга да исәбе бар.

Польша татары Мансур Адамович Кама Тамагында Россия гражданины паспортын алган. Ул берничә ел элек кура җиләге үсентеләре үрчетү белән шөгыльләнә башлаган. 2014 елда Татарстанга кайтып, мөмкинлекләрне күреп киткән һәм шуннан соң күченеп кайту уе белән яшәгән. Хатыны белән Ләйсән һәм Айзилә исемле ике кыз үстерәләр.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Россия эшмәкәрләренең, кемнәндер ярдәм көтмичә, үзләре үрнәк күрсәтеп эшләүләрен, мөстәкыйль, җаваплы булуларын билгеләп узды, аларның үз төбәкләрендә җитәкчеләргә терәк булуын ассызыклады. Шул ук вакытта эшмәкәрләрнең балаларны дөрес тәрбияләүгә, аларга гореф-гадәтләребезне, телебезне, динебезне яраттыруда күп эшләр башкаруларын да искәртте. Әлбәттә, Татарстанда милләтебезне, телебезне саклауга юнәлдерелгән программалар кабул ителә, авылларга ярдәм күрсәтелә. Россия өлкәләрендәге җитәкчеләр исә бу мәсьәләләргә алай ук игътибар итми. «Мәчетләр, мәктәпләр, мәдәният бинаглары – барысы да сезнең хезмәт, сезнең кебек эшмәкәрләр ярдәме белән күтәрелә. Һәр чыгыш үзе бер китап язарлык. Шундый милләттәшләребез булганда, динебез, милләтебез өчен борчылмыйбыз», – диде ул.

Сөембикә КАШАПОВА.

Киви

Киви – гаҗәеп файдалы җимеш. Анда A, B, B1, B2, B3, B6, C, E витаминнары, магний, калий, каротин, ферментлар, минераль тозлар, натрий, клетчатка, никотин кислотасы бар. Ул кан тамырларының тышчасын ныгыта, башка кан саву ихтималын киметә, артериаль кан басымын җайга сала. Калий күп булганга, организмдагы су-тоз балансын көйли һәм шешенүдән саклый. Көненә бер киви ашау С витаминына булган тәүлеклек ихтыяҗны канәгатьләндерә һәм шул рәвешле иммунитетны ныгыта, савыгуны тизләтә. Бу җимештәге пектинлы матдәләр эчәклектәге файдалы микрофлораны сәламәтләндерә һәм матдәләр алмашының зыянлы продуктларын үзенә сеңдерә. Аз калорияле булганга, киви ябыктыра торган диеталарда уңышлы кулланыла. Ул шулай ук бөердә таш булганда, анемия, атеросклероз, ревматизмнан интеккәндә бик файдалы.

(“Batona.net”).

Яшел чәй сихәте

Кытайның Нанкин шәһәрендәге педиатрия институты галимнәре дәлилләгәнчә, даими яшел чәй эчү артык авырлыктан котылырга булыша. Яшел чәйнең кайбер сортларында полифенол дигән химик матдә бар, ул май тукымасын бик шәп тарката. Шулай итеп, көненә берничә чынаяк хуш исле чәй эчеп кенә дә, аена берничә килограммга ябыгырга була. Билгеле инде, ашауда барыбер чама хисен югалтмаска кирәк. Яшел чәй антиоксидантларга бай, шунлыктан ул яшәртә, гомерне озайта. Япон галимнәре, 12 ел буена тикшеренү үткәреп, яшел чәйнең яман шештән саклавын дәлилләгән, тик нәтиҗәсе булсын өчен, көненә 1,5 литр чәй эчәргә кирәк икән, бу исә башка әгъзаларга зыян китерергә мөмкин. Яшел чәй иммунитетны ныгыта; организмнан шлакларны чыгара; йөрәккә булыша (инфаркт булу куркынычын ике тапкырга киметә); матдәләр алмашын яхшырта; “начар” холестеринны куа; кандагы шикәр микъдарын көйли; кан тамырларын ныгыта; баш мие эшчәнлеген активлаштыра; бавырны – алкогольнең җимергеч тәэсиреннән, тешләрне – кариестан, уртны – ялкынсынудан саклый; күз күремен яхшырта; эшкә сәләтлелекне арттыра; компьютер мониторы тараткан нурланышның тискәре тәэсирен киметә; сусауны судан яхшырак баса.

(“Синьхуа”).

Барбиның “әнисе”

Планетада иң популяр курчакны уйлап табучы Рут Москович яһүд гаиләсендә унынчы бала булып дөньяга килгән. Польшадан АКШ ка килеп урнашкан эти-әнисе кызларының бай кеше белән гаилә коруын теләгән, шунлыктан аның сәнәгать дизайны колледжына керүен бер дә өнәмәгән. 1938 елда Рут картиналар өчен декоратив рамнар ясау остасы Эллиот Хэндлерга кияүгә чыккан, бербер артлы кызлары Барбара, уллары Кеннет туган. Бервакыт кызының әтисеннән калган агач шакмаклардан курчакларына карават ясап уйнавын күзәткән Рут иренә уенчык җиһазлар ясап карарга тәкъдим иткән. Көтмәгәндә бу уенчык җиһазлар рам сатудан күбрәк табыш китерә башлаган. Бизнесны үстерү өчен акча кирәккәч, Хэндлер дусты Харольд Матсон белән капиталын берләштергән һәм “Mattel” компаниясенә нигез салган. 1956 елда Швейцариядә ял иткәндә Рут озын аяклы, калку күкрәкле сәер курчак күреп алган. Немец комикслары мотивлары буенча Р.Хойзер ясаган Лилли исемле сувенир курчак өлкәннәргә тәгаенләнгән булган. Рут ирен Лилли курчагы образына хокукны сатып алуга күндергән. 1957 елдан “Mattel” компаниясе курчакны җитештерә дә башлаган. Рут яңа курчакны ул елларда гаять популяр Джейн Мэнсфилд сынына охшатып ясаган, әлеге актриса үзенең өен гел ал төстәге җиһазлар куелган курчак йортына әйләндергән. Рут Хэндлер да курчаклары өчен шундый йортлар ясаткан. 1958 елда ул үз уенчыгына патент алган һәм аңа Барби дип кызының исемен кушкан. Тик ата-аналар курчакның тышкы кыяфәтен бик вульгар дип тапкан һәм аны сатып алудан баш тарткан. Рут исә аптырап калмаган, телевидениедә реклама биргән. Берничә йөз мең курчак тиз арада сатылып беткән. Беренче ун елда Барбиның “әнисе” ярты миллиард доллар акча эшләгән, ул Американың иң танылган эшкуар хатын-кызына әйләнгән. 1970 елда Рут Хэндлерның күкрәгендә яман шеш табылган, операциядән соң ул инде кәгазьдә генә компания президенты булып саналган. 1978 елда исә аны, кыйммәтле кәгазьләр белән махинацияләрдә гаепләп, 5 елга шартлы рәвештә ирегеннән мәхрүм иткәннәр һәм бик зур штраф түләткәннәр. Гаммәви мәгълүмат чараларында аңа каршы кампания башланган. Әмма Рут Хэндлер төшенкелеккә бирелмәгән: мастоэктомиядән соң күкрәксез калучылар өчен протез җитештерүне җайга салган. 1991 елда үз компаниясен медицина корпорациясенә саткан. Шул елда улы Кеннет вафат булган, ә кызы әнисен үзенә тиешле игътибар бирмәүдә гаепләп чыккан. Рут Хэндлер 2002 елда 85 яшендә бакыйлыкка күчкән. 1993 елда Барби курчагы гаиләгә миллиард доллар, 1994 елда инде ике миллиард доллар акча китергән. Хәзер ул дөньяның 150 илендә 25-70 долларга сатыла һәм җиһанда иң күп сатыла торган егерме товар исемлегенә керә.

(“Bloomberg”).

Ахырзаман галәмәтеме?

Мең еллар буе Согыд Гарәбстаны чүлләрендә авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнү мөмкин түгел, дип саналган. Әмма бүген, яңа ирригация технологияләреннән файдаланып, илдә әлеге тармак уңышлы үсә. Әс-Сирхан үзәнендә урнашкан яшел кырлар таң калдыра – диаметры 1 әр чакрымлы әлеге түгәрәкләр һавадан караганда бик ачык күренә. Гарәбстан чүлендә су бар ул, әмма бер чакрым тирәнлектә – бик борынгы бозлык калдыклары ята анда. Кыр уртасындагы скважинадан су күп тишекле махсус торбага менә, ул, чәчүлек җирләрне сугарып, түгәрәк буйлап бертуктаусыз хәрәкәт итә, шуңа су сибелә торган мәйдан, үсемлекләр үскәндә, яшел төстәге зур түгәрәккә әйләнә. Торба электр энергиясеннән башка, чишмә басымы белән хәрәкәткә китерелә. Бер сүз белән әйткәндә, бу – фермерлар хыялы. Американы Фрэнк Зибах уйлап тапкан Center Pivot түгәрәкле ирригация системасы планетаның корылыклы төбәкләрендә күп кулланыла, Әс-Сирхан үзәнендә дә җиләк-җимеш, яшелчә, бөртекле культуралар шулай игелә. Су запасы 50 елга җитәргә тиеш. Әмма кайбер ислам галимнәре бу галәмәтне ахырзаманның бер билгесенә саный, чөнки Әбү Һурайра тапшырган хәдистә: “Гарәп чүлләре кабат елгалар аккан көтүлекләргә әйләнмичә, Гарәбстан кабат яшеллеккә күмелмичә торып, Кыямәт көне җитмәс”, – диелгән. Хәзер исә ярымутрау ямь-яшел. Без ахырзаман якынлашу галәмәтләреннән берсенең шаһите түгелме икән?

(“Nation Geographic”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

28 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР». 6+
10.00, 23.30 «БЕСЦЕННАЯ ЛЮБОВЬ». 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.40 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Уймак» һәм «Сәйлән».
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Мин». 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Реальная экономика». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә.. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ТАНКИ ГРЯЗИ НЕ БОЯТСЯ». 12+
10.30, 21.00 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ВОЙНА БОГОВ: БЕССМЕРТНЫЕ». 16+
15.00 «Еда. Правильное питание». 12+
15.30 «Мечтатели». 12+
16.20 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.25, 12.15, 15.15, 18.20, 0.55 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «ЯНЫЧАР». 16+
22.55 «Большая игра». 16+
23.55 Документальное расследование «Большая игра». 18+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.15, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Александра Коллонтай.
7.35 «Мария Пахоменко. Объяснение в любви».
8.20 «Екатеринбург. Особняк Тупиковых».
8.50 «ЮРКИНЫ РАССВЕТЫ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Сеанс гипнотизера». По рассказам Леонида Ленча.
12.25 Линия жизни. Нина Мозер.
13.25 «Тагефон, или Смерть «великого немого».
14.05 «Забытое ремесло».
14.20 «Мстислав Ростропович».
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
16.25 Острова. Александр Митта.
17.05 «Первые в мире».
17.20 Марафон «Звёзды XXI века». Андрей Гугнин.
18.40 «Тайны небес Иоганна Кеплера».
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Анна Виленская. «Как тик-ток-культура влияет на форму песни».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 «Дягилев и Стравинский. Поединок гениев».
21.45 «Сати. Нескучная классика...»
22.25 «БЕРЕЗКА».
23.20 «Фотосферы».

«НТВ»

4.50 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ». 16+
13.20 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АНОНИМНЫЙ ДЕТЕКТИВ». 16+
23.45 «ПЁС». 16+

Сишәмбе

29 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР». 6+
10.00, 23.00 «БЕСЦЕННАЯ ЛЮБОВЬ». 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Уймак» һәм «Сәйлән».
16.00, 21.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә.. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ТАНКИ ГРЯЗИ НЕ БОЯТСЯ». 12+
10.30, 21.00 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ПОМНИ МЕНЯ». 16+
15.00 «Инвиво». 12+
15.30 «Погоня за вкусом». 16+
16.20 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.25, 12.15, 15.15, 18.20, 0.55 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «ЯНЫЧАР». 16+
22.55 «Большая игра». 16+
23.55 Документальное расследование «Большая игра». 18+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.40, 18.40 «Тайны небес Иоганна Кеплера».
8.35 «Первые в мире».
8.50, 16.35 «ЮРКИНЫ РАССВЕТЫ».
9.50 Цвет времени. Марк Шагал.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Творческий вечер Валерия Золотухина».
12.30, 22.25 «БЕРЕЗКА».
13.25 «Игра в бисер» «Джером К. Джером. «Трое в одной лодке...»
14.05 Цвет времени. Карандаш.
14.15 Больше, чем любовь.
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Эрмитаж».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
17.45 Марафон «Звёзды XXI века». Дмитрий Маслеев, Павел Милюков, Александр Рамм.
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Вера Мильчина. «Шоппинг в Париже в XIX веке».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Искусственный отбор.
21.45 «Белая студия».
23.20 «Фотосферы».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ». 16+
13.20 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АНОНИМНЫЙ ДЕТЕКТИВ». 16+
23.45 «ПЁС». 16+

Чәршәмбе

30 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР». 6+
10.00, 23.00 «Большой скачок». 12+
11.00, 0.15 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00, 0.40 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Шома бас» һәм «Сәйлән».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Ватандашлар». 12+
23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
9.40 «Йөрәктән - йөрәккә». Рәдиф Гаташ турында телеочерк. 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә.. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Юлчы». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ТАНКИ ГРЯЗИ НЕ БОЯТСЯ». 12+
10.30, 21.00 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 12+
11.30 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «БОЛЬШАЯ СВАДЬБА». 16+
14.30 «Люди РФ». 12+
15.00 «Без химии». 12+
15.30 «Кавказский пленник». 12+
16.20 «Фиксики».
17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.25, 12.15, 15.15, 18.20, 0.55 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «ЯНЫЧАР». 16+
22.55 «Большая игра». 16+
23.55 Документальное расследование «Большая игра». 18+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Тайны небес Иоганна Кеплера».
8.35, 12.10 «Первые в мире».
8.50, 16.35 «ЮРКИНЫ РАССВЕТЫ».
9.50 Дороги старых мастеров. «Лесной дух».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Паша + Ира =. Сцены из жизни молодожёнов».
12.30, 22.25 «БЕРЕЗКА».
13.25 Искусственный отбор.
14.05 «Забытое ремесло».
14.20 К 95-летию со дня рождения Владимира Ильюшина. «Цитаты из жизни».
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
17.35 Марафон «Звёзды XXI века». Александр Рамм, Димитрис Ботинис и Академический симфонический оркестр Московской филармонии.
18.35 «Почему исчезли неандертальцы?»
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Константин Северинов. «Коронавирус - двигатель развития общества».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Абсолютный слух.
21.45 Власть факта. «Франко-русский союз».
23.20 «Фотосферы».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ». 16+
13.20 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АНОНИМНЫЙ ДЕТЕКТИВ». 16+
23.45 «ПЁС». 16+

Пәнҗешәмбе

31 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР». 6+
10.00, 0.00 «Большой скачок». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник» һәм «Сәйлән».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Соотечественники». 12+
22.10 «Наша Республика - наше дело». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә.. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Калеб». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ТАНКИ ГРЯЗИ НЕ БОЯТСЯ». 12+
10.30, 21.00 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «МЭРАЙА МУНДИ И ШКАТУЛКА МИДАСА». 16+
14.40 «Люди РФ». 12+
15.10 «Еда. Правильное питание». 12+
15.40 «Верю не верю». 16+
16.30 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «МОСКОВСКАЯ ПЛЕННИЦА». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.25, 12.15, 15.15, 18.20, 0.55 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «ЯНЫЧАР». 16+
22.55 «Большая игра». 16+
23.55 Документальное расследование «Большая игра». 18+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Почему исчезли неандертальцы?»
8.35 «Первые в мире».
8.50, 16.40 «ЮРКИНЫ РАССВЕТЫ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Старинные романсы, цыганские песни в исполнении Аллы Баяновой».
12.15 «Забытое ремесло».
12.30, 22.25 «БЕРЕЗКА».
13.25 Абсолютный слух.
14.05 Цвет времени. Ар-деко.
14.20 Острова. Корней Чуковский.
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Моя любовь - Россия! «Дом - лицо хозяина».
15.50 «2 Верник 2».
17.45 Марафон «Звёзды XXI века». Лукас Генюшас, Михаил Татарников и Академический симфонический оркестр Московской филармонии.
18.35 «Воительница из Бирки».
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга.
20.30 Цвет времени. Эль Греко.
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 «Вихри века».
21.45 «Энигма. Аида Гарифуллина».
23.20 «Фотосферы».

«НТВ»
4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ». 16+
13.20 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АНОНИМНЫЙ ДЕТЕКТИВ». 16+
23.45 «ЧП. Расследование». 16+

Җомга

1 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30, 16.30, 21.00 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Рыцари вечности». 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Төймә» һәм «Сәйлән».
16.00 «Мин». 12+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә.. 6+
19.10 «Туган җир». 12+
20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «МОСКОВСКАЯ ПЛЕННИЦА». 12+
10.30, 21.00 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «МЕНЯЮЩИЕ РЕАЛЬНОСТЬ». 16+
15.00 «Инвиво». 12+
15.30 «Еда, я люблю тебя». 16+
16.30 «Четверо в кубе».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.25, 12.15, 15.15, 18.20 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «Голос. Дети».
23.35 «ОДИССЕЯ». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Воительница из Бирки».
8.35 «МИЧУРИН».
10.20 «АРШИН МАЛ АЛАН».
12.00 Открытая книга.
12.30 «БЕРЕЗКА».
13.25 Власть факта. «Франко-русский союз».
14.10 «Александра Коллонтай. Вихри века».
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Аида Гарифуллина».
16.20 «ЮРКИНЫ РАССВЕТЫ».
17.25 «Библиотека Рудомино».
18.20 «Царская ложа».
19.00 «Смехоностальгия».
19.45 Искатели. «Сокровища шведской короны».
20.30 К 75-летию Михаила Мишина. Линия жизни.
21.25 «ВЛЮБЛЕН ПО СОБСТВЕННОМУ ЖЕЛАНИЮ».
22.50 «2 Верник 2».

«НТВ»
4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
11.00 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ». 16+
13.20 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
20.00 «Жди меня». 12+
21.00 «Страна талантов». 12+
23.20 «Своя правда». 16+

Шимбә

2 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Мин». 12+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «Созвездие - Йолдызлык-2022». 6+
14.30 «Әсхәт Хисмәтовның 70 яшьлек юбилей кичәсе». 6+
16.00 «Әйдә, шаяРТ!» 12+
17.00 «СТЕНДАПханә». 16+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБиТ- шоу». 12+
23.30 «ВЕРСАЛЬСКИЙ РОМАН». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Ләис Зөлкарнәй турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.10 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.05 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Ишеттем мин кичә берәү җырлый». 6+
14.05 «Кояшларың белән кил син миңа». 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.40 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 Марат Мухин хитлары. 6+
22.40 Спектакль «Гайфи бабай, өйлән давай!» 12+

«ЭФИР»
5.00 «Еда. Правильное питание». 12+
5.30 «Дорога в космос». 12+
6.30 «Опыты дилетанта». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Джингликки».
8.00 «Прокуроры 2». 16+
8.45 «КАССИРШИ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ГОНКА ВЕКА». 16+
14.50 «Все, кроме обычного». 16+
16.00 «УЛЕТНЫЙ ЭКИПАЖ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «НЕВЕРОЯТНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ФАКИРА». 16+
22.40 «Человек - невидимка». 16+
23.35 «ГОЛГОФА». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
10.15 «АнтиФейк». 16+
11.05, 12.15, 15.15 «О ЧЕМ ОНА МОЛЧИТ». 16+
15.40 «Кто хочет стать миллионером?»
17.00 «Человек и закон». 16+
18.20, 22.00 «Шифр». 16+
21.00 «Время».
23.25 «СОЛЯРИС». 16+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00, 21.05 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.50, 14.50 «НЕВЕСТА КОМДИВА». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.20 «ЧУЖАЯ СЕСТРА». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.20 «АНОНИМКА».
9.30 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
10.00 Неизвестные маршруты России. «Дагестан. От Каспийска до Кегера».
10.40 «ВЛЮБЛЕН ПО СОБСТВЕННОМУ ЖЕЛАНИЮ».
12.05 «Эрмитаж».
12.35 «Брачные игры».
13.25 «Владимир Котляков. Время открытий».
14.10 «Рассказы из русской истории. XVIII век». Владимир Мединский.
15.55 «Его назвали Гением».
16.35 «ТАЙНА ЗОЛОТОЙ ГОРЫ».
17.50 «Любовь и голуби». Что характерно! Любили друг друга!»
18.30 «Дягилев и Стравинский. Поединок гениев».
19.15 «ПЕРВАЯ ЛЮБОВЬ».
21.10 Спектакль «Один».
22.00 «Агора».
23.00 «Тулуз-Лотрек. Наперегонки со временем».
23.55 «СЫН».

«НТВ»
5.20 «ЧП. Расследование». 16+
5.40 «Я СЧИТАЮ. РАЗ, ДВА, ТРИ, ЧЕТЫРЕ, ПЯТЬ...» 16+
7.25 Смотр.
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «Готовим с Алексеем Зиминым».
8.45 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «По следу монстра». 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.15 «Ты не поверишь!» 16+
21.15 «Секрет на миллион». 16+
23.10 «Международная пилорама». 16+

Якшәмбе

3 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Гомер китабы». Лилия Муллагалиева концерты. 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Полосатая зебра».
9.00 «Син һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Әйләнә дөнья». Ришат Фазлыйәхмәтов концерты. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент.Общество». 12+
13.30 «Созвездие - Йолдызлык-2022». 6+
14.30 «Әсхәт Хисмәтовның 70 яшьлек юбилей кичәсе». 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Соотечественники». 12+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «БОБЁР». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35, 23.20 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.35 «Нәсыйхәт». 6+
6.00, 13.00, 0.40 «Татарлар». 12+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00, 16.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
8.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
9.00 «Галиҗәнап шагыйрь» циклыннан. Илдар Юзеев. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы». 12+
14.05 «Казанның кадерле кичләре». Зөһрә Сәхәбиева концерты. 6+
15.35 «Шаян хәлләр». 12+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «СТЕНДАПханә». 16+
21.40 «Бер сулышта». Артур Исламов һәм Эльза Заяри концерты. 6+

«ЭФИР»
5.00 «Инвиво». 12+
5.30 «Дорога в космос». 12+
6.30 «Опыты дилетанта». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Джингликки».
8.00 «Прокуроры 2». 16+
8.45, 14.45 «Наша марка 2». 12+
9.00 «УЛЕТНЫЙ ЭКИПАЖ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «НЕВЕРОЯТНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ФАКИРА». 16+
15.00 «Кавказский пленник». 12+
15.45 «КАССИРШИ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ГОНКА ВЕКА». 16+
22.50 «Человек - НЕВИДИМКА». 16+
23.45 «НЕВИДИМКА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.35, 6.10 «ХИРОМАНТ». 16+
6.00, 10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
8.25 «Часовой». 12+
8.55 «Здоровье». 16+
10.15 Чемпионат России по лыжным гонкам.
12.15, 15.15, 18.20 «МОСГАЗ». 16+
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?».
23.45 «ЗЕРКАЛО». 12+

«РОССИЯ»
5.20 «ЖИЛА-БЫЛА ЛЮБОВЬ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00, 17.00 Вести.
11.50, 14.50 «НЕВЕСТА КОМДИВА». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.40 «ТАЙНА ЗОЛОТОЙ ГОРЫ».
8.50 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
9.20 «Мы - грамотеи!»
10.05 «СЫН».
11.30 Письма из провинции.
12.00 Цвет времени. Леонид Пастернак.
12.15 Диалоги о животных.
12.55 Невский ковчег. Теория невозможного. Владимир Малышев.
13.25 «Игра в бисер» «Лев Толстой. «Холстомер».
14.10 «Рассказы из русской истории. XVIII век». Владимир Мединский.
15.15 Спектакль «Новая Россия».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Пешком...»
17.40 85 лет Марку Розовскому. Линия жизни.
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «АНДРЕЙ РУБЛЕВ».
23.20 Из «Света». Телеверсия оперного цикла К.Штокхаузена.

«НТВ»
5.00 «ПОГОНЯ ЗА ШЕДЕВРОМ». 16+
6.40 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.40 «Маска». 12+
23.25 «Звезды сошлись». 16+

Халкыбызның үткәннәренә күз салсак, тарих сәхифәләрендә әһәмиятле роль уйнаган, үз эзен калдырган хатын-кызларыбызның шактый булуын да күрербез. Дөрестән дә, башка төрки һәм ислам мәдәнияте халыклары белән чагыштырганда, татар хатын-кызларының роле милләтнең сәяси тормышында да зур булган.

МИЛЛӘТЕБЕЗНЕҢ МӘШҺҮР КЫЗЛАРЫ

Бу яктан караганда, милләтебездә Европага хас күренешләр дә тоемлана. Галимнәребез ханбикәләрнең тәхеттә хан белән бергә утыруын Атилла чорында ук теркәлеп калуы турында әйтә. Татар хатын-кызлары, сәясәттә әһәмиятле роль уйнау белән бергә, мәктәпләр ачканнар, үз хокуклары өчен көрәшкәннәр, хәтта аларны казыя итеп тә сайлаганнар. Милләтебезнең гүзәл затлары иң авыр хәлләрдә дә югалып калмаган. Балигъ булмаган улы Үтәмешгәрәй хан вакытында дәүләт башлыгы вазифасын башкарган Сөембикә-ханбикә, халкыбыз хәтерендә биш гасыр вакыт узганнан соң да, каһарманлык, ватанпәрвәрлек, иманга тугрылык сыйфатларын чагылдыручы символ итеп кабул ителә.

Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында «Татар тарихында хатын-кызлар» дигән темага түгәрәк өстәл утырышында да гүзәл затларыбызның тарихыбызда аерым урын алып торуы ассызыкланды. Әлбәттә, тарихта, халык хәтерендә эз калдырган татар хатын-кызлары әдипләребез әсәрләрендә чагылыш тапкан, аларның тормышы һәм эшчәнлеге галимнәребез тарафыннан өйрәнелгән һәм бу эш әле дә дәвам итә. Институтның өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Эльмира Сәлахова бу уңайдан утырышта катнашучыларны тарихчы, педагог, Казанда Шәрык клубын оештыручыларның берсе булган Гайнетдин Әхмәровның «Казан ханнары» дигән хезмәтеннән тарих сәхифәләренә кереп калган берничә хатын-кыз белән таныштырды.

Г.Әхмәровның Казан ханнарына багышланган хезмәтләрендә аерым бүлек – Нугай морзасы Йосыф бәк кызы Сөембикә-ханбикә турында. Тарихчының Сөембикәбезгә багышланган зуррак бер хезмәте дә булган. Әмма ул кулъязма килеш юкка чыккан. Бу хакта, Г.Әхмәровның вафатыннан соң, Галиәсгар Камал язып калдырган. Әмма әлегә хезмәт шәхси архивларда да табылмаган. Чөнки тарихчының бердәнбер исән калган улы 1939 елда кулга алына, аның булган милке талап алына, үзе сөргенгә сөрелә. Кульязманы шул вакытта югалган булу ихтималын фаразлыйлар.

Г.Әхмәров Казан ханлыгы тарихында әһәмияткә ия тагын Хөршидәбикә дигән ханымны искә ала, аның сәяси ролен, бигрәк тә Казан ханлыгының соңгы елларында, зур булганлыгын күрсәтә. Чөнки төрле сәяси төркемнәр хакимияттә, бигрәк тә Казан ханлыгының соңгы елларында, үзара урын бүлешкәндә, Хөршидәбикә шактый хәлиткеч роль уйнаган.

Тарихчы шулай ук милләтебез үткәннәрендә әһәмияткә ия тагын берничә хатын-кыз исемен атый. Әйтик, Нурсолтан ханбикә тарихта исемнәре калган өч ханның бер-бер артлы хатыны, ике ханның анасы булган. Аның йогынтысы Казан, Кырым ханлыгы тарихларында чагылган, хәтта Россиянең дәүләт сәясәтендә дә сизелгән.

Институтның өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Эльмира Сәйфетдинова Алтын Урдада Чыңгыз нәселеннән хан кызы Тулунбай (Толымбай) турында сөйләде. Алтын Урда чорында Мисыр белән бәйләнешләр бик тыгыз булуы мәгълүм. Үзара мөнәсәбәтләрне ныгытуда Тулунбайның да роле зур. Алтын Урда әмирләре, аерым алганда Тимер Кутлуг, дәүләтләр арасындагы сәяси элемтәләрне тагын да ныгыту өчен никах элемтәләре урнаштыруга тәкъдим итә. Калым мәсьәләләре хәл ителеп беткәч, 1319 елның көзендә кузгалган 400 кеше составындагы туй тантанасы Мисыр җирләрендәге Александрия шәһәренә май аенда гына барып житә. Тулунбайны корабльдән алтынланган чаршаулы арбага утыртып Каһирәдәге солтан сараена алып киләләр. Шул ук көнне никах килешүе төзелә, бүләкләр таратыла. Әмма Тулунбайның язмышы авыр булып чыга. Мәмлүк солтаны ән-Насир Солтан аны ошатмый һәм Мисырның көньягындагы Сәидкә җибәрә. Алар сигез елдан аерылышалар. Тулунбай әмир Салахдар Сәйфеддингә кияүгә бирелә, әмма ул өч елдан вафат була. Бу елларда хатын-кызга ирсез торырга ярамаган. Тулунбай әмир Сусунга кияүгә бирелә. Ул өч елдан якты дөнья белән хушлаша. Аның вафатыннан соң хатынны җирле идарә башлыгы Аргунның улы Гомәргә никахлыйлар. Ул Тулунбайның соңгы ире була. Тулунбай үзе 1364 елда гүр иясе була. Мәрмәрдән эшләнгән кабере Мисырда аерым бер бина эчендә саклана.

XX гасыр башында татар җәмгыятендә тормышка яңача караш формалаша. Татар хатын-кызлары мәктәпләр ача, укыту эшләре белән шөгыльләнә. Әйтик, Фатыйха Аитова хатын-кызларның белем системасын булдырырга өлеш керткән ханымнарның берсе. Ул беренчеләрдән булып ярлы гаиләдә туган кыз балалар өчен башлангыч мәктәп ачкан, соңрак аны татар кызлары өчен гимназиягә әверелдерә.

Ш.Мәрҗани институты фәнни хезмәткәре Алсу Зиннәтуллина бу елларда күтәрелгән шундый ханымнарның берсе Багбостан Мөэминова турында сөйләде. Шәехзадә Бабич шигырьләрендә искә алынган Багбостан хәзерге Азнакай районы Мәндәй авылының крестьян гаиләсендә бишенче бала булып дөньяга килә. Кызга өч яшь вакытта әтиләре вафат була, әниләре биш кызын алып Оренбургка күченә. Багбостан, яше җиткәч, Гани бай Хөсәенов тарафыннан ачылган яңа ысуллы мәктәпкә укырга бирелә. Беренче рус революциясе йогынтысында татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә дөньяви фәннәр укытуга нигезләнгән кызлар мәктәпләре ачыла башлый. 1905–1907 елгы революцияләрдән соң мәктәпләрнең саны арта. Шундый мәктәпләрнең берсе булып Оренбург шәһәрендә ачылган «Багбостан мәктәбе» санала. 1908 елда башлангыч мәктәп буларак ачылган әлеге уку йорты 1918 елга гимназия югарылыгына күтәрелә.

Ул 1905 елгы революциядән соң Оренбург шәһәрендә ачылган беренче җәдиди кызлар мәктәбе булып санала. Аның даны тиз халык арасында тарала. Бирегә илнең төрле төбәкләреннән мөселман кызлары килә башлый. Өченче уку елына барлык укучыларның саны йөздән артып китә, ә ун ел эчендә исә әлеге мәктәпне меңнән артык, төгәлрәк әйткәндә, 1212 укучы тәмамлый.

1912 елда Багбостан ханымның ире Гобәйдулла Рәдүди күкрәк авыруыннан вакытсыз вафат була. Багбостан ханым барлык авырлыклар алдында берүзе кала. Кадими муллалар төрле сәбәпләр табып, шул исәптән, Багбостан ханымның мөгаллимәлеккә рәсми шәһадәтнамәсе юклыгын да истә тотып, мәктәпне берничә мәртәбә япмырга тырышалар. Бу хәлләрдән соң, 1913 уку елы тәмамлангач, Багбостан ханым Уфага бара. Монда ул күп кенә кыенлыклар аша узып, хатын кызлардан тарихта беренче кеше буларак, Диния нәзарәтендә имтихан тапшырып, укытуга хокук бирүче рәсми документ ала. Рәсми кәгазь алу нәтиҗәсе буларак, көздән мәктәп уку программасы киңәйтелә. Багбостан ханым 1915–1916 уку елына 20 кешелек пансион ачарга җөрьәт итә. 1918 елдан мәктәп хөкүмәт карамагына күчә һәм 1925 елда ябыла. Багбостан 1938-1956 елларда - шәхес культы корбаны. Себер сөргененнән кайткач, үзенең тормыш иптәше Гобәйдулла Рәдүдинең язган китапларын барлый. Багбостан ханым 1963 елның 9 мартында вафат була.

Татар мәгърифәтчеләре Галимәтелбәнат Биктимерия һәм Фәхрелбәнат Сөләймания үз заманында алдынгы карашлы мөгаллимәләр булган. Әйтик, Г.Биктимерия 1895 елда Касыйм шәһәренә якын Яубаш авылында кыз балалар өчен мәктәп ачып укыта. Алар хатын-кызның гаиләдәге урыны, гаилә һәм бала тәрбиясенең үзенчәлекләренә багышланган хезмәтләр язып калдырган. Тарих фәннәре кандидатлары Ләлә Мортазина һәм Алсу Зиннәтуллина, бу хезмәтләрнең текстларын хәзерге татар әдәби теленә якынайтып, иске кулланыштагы сүзләргә, гарәп-фарсы алынмаларына аңлатмалар белән китап итеп әзерләп чыгарган.

Тарих фәннәре кандидаты Тәэминә Биктимерова хирург-табибә Зөләйха Тальковская турында бәян итте. Ул Польша-Литва татарларыннан чыккан атаклы армия генералы Искәндәр Тальковскийның кызы була. Октябрь революциясенә Гражданнар сугышы ялгана. Совет хөкүмәте, курслар ачып, укый-яза белгән хатын-кызларны санитарка, фельдшер итеп хезмәт итәргә алган. Андыйларның исәбе 11 меңгә җитә язган. Шушы кызлар арасында Зөләйха Тальковская да була. Санкт-Петербургның медицина институтының 5 нче курсында укыганда, әтисе янында хезмәт иткән Якуп Апанаевка кияүгә чыга һәм Казанга күчеп килергә тели, белем алуын Казан медицина институтында дәвам итә. Зөләйха 1925 елда аны тәмамлагач, хирург булып эшли башлый. Октябрь революциясеннән соң Тальковскийларның язмышлары кискен үзгәрә. 1937 елда Зөләйханың әтисе И.Тальковский кулга алына, ире Якуп атып үтерелә. Табибәгә бик катлаулы операцияләрне үзе генә башкарып чыгарга туры килә. 1941 елда ул берүзе алты сәгать дәвамында операция ясый. Озак басып торганлыктан, аягындагы тромблары шартлый, табибә шунда ук вафат була. Аны соңгы юлга озатырга килгән кешеләр белән хәзерге Мәскәү урамындагы зур бакча тула. Халык Зөләйхага ихтирамын шулай белдерә. «Совет хөкүмәтенең үзенә игелек күрсәткән кешеләргә дә хөрмәте булмавы мине тетрәндерде. Аның юньле-рәтле фатиры да булмаган. Югыйсә, Апанаевларның Казанда 17 йортлары калган», – диде Т.Биктимерова.

Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре Халидә Баһаветдинованың күренекле мәгариф ветераны, рус теле һәм урта гасыр татар әдәбияты буенча фәнни хезмәтләр авторы Зәйнәп Максудованың сеңлесе Нәҗия Габделҗәмил кызының авыр язмышы турындагы чыгышы да мәгълүматлы иде. Кулына корал алып акларга каршы көрәшкән, колчакларга әсир төшкән һәм бик каты кыйналган Нәҗия коммунистлар партия сафларына керә һәм төрле комитетларда, ширкәтләрдә оештыру эшләре белән шөгыльләнә, җитәкче вазифаларын башкара. Нәҗиягә улының вафатын да кичерергә туры килә. Гомеренең соңгы елларында Нәҗия бик еш авырый. Үпкә туберкулезы өстенә тамак һәм эчәк туберкулезы өстәлә. 1949 елның 9 маенда бары 46 яшендә ул вафат була. Казанда Яңа бистә зиратында җирләнә.

Сөембикә КАШАПОВА.

Гүзәлләр тудырган гүзәллек

Кол Шәриф мәчетенең Ислам сәнгате музеенда нурлы күргәзмә ачылды. Экспозициягә куелган шәмаилләрнең авторлары – икесе дә гүзәл хатын-кызлар.

Моннан утыз ел элек кенә әле гарәп язуы киң галереяларда күренми иде, чөнки җитмеш ел буена татар халкын изге язудан аерырга омтылдылар. Әмма гарәп язуы онытылмады – һәр татар кешесе үзенең татарлыгын, мөселман булуын раслау өчен өендә пыялада язылган шәмаил тотты. Үзгәреш җилләре искәч, дини, әдәби кульязма мираска юл ачылды. Университетта гарәп язуын өйрәнергә теләүчеләр өчен курслар ачылды. Язуны беренчеләрдән өйрәнүчеләргә бөек рәссамыбыз Бакый ага Урманчедан дәресләр алу бәхете эләкте. Бу бәхетлеләр арасында күренекле каллиграфыбыз Нәҗип Нәккаш та бар. 1990 елларда «Мирас», «Идел» журналлары ачылгач, аларны милли әслүбтә бизәү ихтыяҗы туа. Рәссамнарыбыз җиң сызганып иҗат эшенә керешә. Шулай итеп журналларның тууы дини, әдәби мирасыбызның кайтуын тизләтеп җибәрә. 1990 еллар ахырында Татар дәүләт гуманитар институт ачылу яшь каллиграфлар тәрбияләүгә этәргеч була. Күренекле хаттат Н.Нәккаш биредә беренче курстан алып матур язу һәм бигрәк тә гарәп каллиграфиясе серләренә өйрәтә. Өйләрендәге пыяла шәмаилләрдән башканы күрмәгән авыл балалары, ашкынып, гарәпчә укый, яза башлый. Шулай өч дистә ел эчендә байтак яшьләр шәмаилләр иҗат итүгә керешә. Алар арасыннан егермеләбе бу эшнең осталары булып таныла. Әлфия Исхакова һәм Чулпан Шәрифуллина да шулар рәтендә.

Ә.Исхакова сәнгать техникумын тәмамлаганда, диплом эше буларак татар шәмаиле темасын сайлый. Аннары шәмаил сәнгате белән кызыксынуы аны гуманитар институтка Н.Нәккаш укыткан каллиграфия дәресләренә китерә. Тырыш кызны биредә тюрколог галимәбез Фәнүзә Шәкүр кызы Нуриева күреп ала һәм фән юлына керергә чакыра. Нәтиҗәдә, Ә.Исхакова кандидатлык диссертациясе яклый. Ул гарәп язуын кайтаруга шәмаил сәнгате аша һәм борынгы кульязма мирасны өйрәнү аша үзеннән саллы өлеш кертә. Үзе белем-күнекмә туплагач, Әлфия дәүләт университетында гарәп язуы укыта башлый, гарәп язуын укытуга ярдәм иткән методик кулланмалар нәшер итә.

Чулпан Шәрифуллина исә гарәп язуына ислам дине аша килә. Хәер, Чулпан да – профессиональ рәссам, Чаллы педагогика университетының графика факультетын тәмамлаган. Гарәп каллиграфиясе белән исә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыганда шөгыльләнә башлый. Башта гарәп ыргакларын челтәр сыман үреп гади генә шәмаилләр иҗат итә. Әмма Чулпанның рәссам буларак дөньяны нечкә тоемлавы шәмаилләрдә дә чагылыш табып, тора-бара гарәп хәрефләре тирәсендә гаҗәеп матур пейзаж, натюрмортлар барлыкка килә. Ч.Шәрифуллина үзе белгәннәрне балалар рәсем студиясендә өйрәтә, анда батик, гобелен, киез һ.б. сәнгатьләр арасында, әлбәттә, каллиграфия дә бар.

Ә.Исхакова академик, монументаль әслүбтә иҗат итсә, Ч.Шәрифуллина чәчкә бәйләмнәрен, архитектура корылмаларын катнаштырып нечкә төсле нәфис композицияләр тудыра. Күргәзмә ачылышында чыгыш ясаган каллиграф Н.Нәккаш рәссамнарның үз йөзен табулары, гарәпне-фәләнне кабатламаулары җәһәтеннән сөенечен белдерде. Гүзәл кызларыбыз мөстәкыйль рәссам булып җитлеккән икән, остазлары Н.Нәккашның сүзе йөрәкләренә барып җиткән, димәк. Шәкертнең күңеле – буш савыт түгел, кабынмаган шәм, диләр.

Гүзәл ханымнар икесе дә шәмаилләр иҗат итеп кенә калмый, балалар үстерә. Корьән сүзе, нәфис сәнгать ярдәмендә тәрбияләнгән балалар да акыллы, инсафлы булыр, иншаллаһ.

Гүзәл затларыбызның картина, шәмаилләр иҗат итүе үзе олы мәгънәгә ия. Сәнгать белгече Рауза Солтанованың әйтүенә караганда, моннан йөз ел элек бер татар хатын-кыз рәссамы булмаган. Тәүге булып Хәдичә Акчурина Мәскәүдә Строганов сәнгать-сәнәгать училищесында рәсем юнәлеше буенча махсус белем ала. Әмма безгә Х.Акчуринаның гүзәл картиналарын күрү язмаган, Бөтендөнья сугышы башлангач ул шәфкать туташы сыйфатында фронтка китә... Бүген Рәссамнар берлегенең сиксән проценты – хатын-кыз рәссамнар. Алар арасында Ә.Исхакова, Ч.Шәрифуллина кебек зыялы, милләт анасы булырдай гүзәл затларыбыз да байтак.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.



ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 25.03.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2750 данә

Заказ 2745

16+